ФӘРИТ ЯХИН

БОРЫНГЫ
#ҺӘМ
УРТА ГАСЫРЛАР
ТАТАР
ӘДӘБИЯТЫ

ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ
ҺӘМ МӘКТӘПЛӘР ӨЧЕН
ДӘРЕСЛЕК-КУЛЛАНМА

КАЗАН
2011

УДК 821.512.145.0
ББК 83.3 (2Рос=Тат)
Я 89

Яхин Фарит Закизянович

ДРЕВНЯЯ И СРЕДНЕВЕКОВАЯ ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА
(на татарском языке)

Бу китап фәнни бәхәс кузгатучы хезмәт буларак түгел, бәлки угыз-кыпчак (кыпчак, Болгар, Хазар, угыз), Алтын Урда, ханлыкларга таркалыш дәвере татар әдәбияты тарихы буенча уку-укыту ярдәмлеге сыйфатында тәкъдим ителә. Ул мәктәп укытучыларына, югары белем уку йортлары студентларына гына түгел, милли мәдәният нигезләре һәм әдәбият белән кызыксынучыларның һәммәсе өчен дә файдалы булыр.

Яхин Ф.З.
Я 89 Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты: Югары уку йортлары һәм мәктәпләр өчен дәреслек-кулланма. — Казан: Раннур, 2011. — 188 б.

Җыярга тапшырылды 05.02.10. Басарга кул куелды 27.12.10.
Форматы 84x108 1/32. Югары сыйфатлы офсет кәгазе № 1,65 гр. “Таймс”
Гарнитурасы. Нәшер-хисап табагы 5,5. Тираҗы 50000 данә. Заказ № К-4772

“Раннур” нәшрияты. 420066, Казан, а/я 365. Тел.: 523-74-34
Нәшрият эшчәнлегенә лицензия № 191 (19.06.97).

Шәхси эшмәкәр Д.В.Чернега тарафыннан “Чувашия” ДУП полиграфия-нәшрият комбинатында басылды. Чабаксар шәһәре, И.Яковлев пр., 13.

ISBN 5-900049-74-4
© Яхин Ф.З., 2011

К е р е ш.
ДӘВЕРЛӘРГӘ БҮЛЕНЕШ

Татар әдәбиятын өйрәнүчеләр аның мең елдан артык тарихы барлыгына басым ясап үтәргә яраталар. Һәрхәлдә, Идел-Урал буйларында яшәүче, Көнбатыш Себер һәм Казакъстанның көнбатыш һәм төньяк киңлекләрендә үз рәвешләре белән гомер кичерүче татар халкы борынгы төрки кавеменнән булып, бары сигез йөз елга якын гына татарлар дип аталып, белдерелеп киленә. Болгар, Хәзәр, Кыпчак һ.б. дәүләтләр һәм кабилә берләшмәләре татар булып бары тик Алтын Урда дәүләтчелеге чорларында гына үзбилгеләнә башлап, милләт буларак XIX гасырның икенче яртысында тәмам татар исеме астында оешып җитә. Тарихның төрле дәверләрендә халык үзен әле мөселман милләте, әле болгарлар, әле татарлар дип сәяси карашларга һәм икътисадый-дини мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә күңеленә якын булган һәртөрле атаманы алып, әдәбиятында шушыларны чагылдырып килә. Бу мескенлек кенә түгел, бәлки гаҗизлек аркасында да шулай килеп чыккандыр, бәлки? Шуның өчен дә олуг шагыйрь Дәрдемәнд:

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене инкарь итәрме?
Татарлыкта татар углы татармын,
Татар түгел, димә, башың ватармын!—

дип XX йөз башында язып чыгарга мәҗбүр булган.

Идел, Урал, Көнбатыш Себер, Төньяк Казакъстан төбәкләрендә яшәүче татарлар үз тарихларында кемнәр генә дип аталмасыннар, болгармы, хәзәрме, ногаймы, әмма алар үзаңнары үсү, үзбилгеләнүләрен юнәлеше, теле, омтылышы, әдәбияты, фольклоры һ.б. белән шул ук татар халкын, татар милләтен тәшкил итәләр. Кайсы дәүләткә, кайсы сәяси фиркаларга керүләренә карамастан, алар бер үк татар милләте булып яшиләр. Халыкның үз милләтен тоюы, үз милләттәшен аркадаш итеп күрүе, туганы дәрәҗәсендә белүе читләргә киткән саен тагын да арта, тагын да ныгый, милли сиземләү көчәя. Татар милләте үзенең тарихи оешкан, формалашкан җирләрендә гасырлар буе яши һәм чикләрне, ягъни дәүләтләргә бүленүне игътибарга алмыйча гомер итә. Моны аңлау татар әдәбияты тарихын төшенү өчен дә гаять зур әһәмияткә ия. Кайбер галимнәр теге яки бу халыкның әдәбиятын үз атамаларын йөрткән дәүләт кысаларына куеп карарга, шуның эчендә генә тикшерергә яраталар һәм шуның белән тарихи хакыйкатьне ачыклауга шактый зыян да китерәләр. Әдәбият үсешен нindидер бер дәүләт чикләре эчендә генә карарга ярамый. Чөнки милли әдәбиятны дәүләт чикләре эчендә генә аңлатып бетереп булмый. Чөнки милли әдәбият дәүләт эчендә генә түгел, бәлки милләт эчендә оеша һәм үсә. Билгеле бер дәүләт чикләренә кертеп каралган әдәбият махсус рәвештә тарайтылган, кысаланган әдәбият, хәтта, әйтергә кирәк, гарипләндерелгән әдәбият ул. Моны татар халкы тарихын тикшергәндә чиксез күп дәлилләр китереп расларга мөмкин

Татар әдәбиятының үсеш процессын тикшергәндә, дүрт типик дәвергә бүлеп карарга мөмкин:

Беренче дәвер — Борынгы һәм урта гасырлар чоры, төрки чор.
Икенче дәвер — Яңа чор, җәдидчелек чоры.
Өченче дәвер — Совет чоры.
Дүретенче дәвер — XX йөз ахыры – XXI гасыр башы чоры.

Әгәр дә бүгенге көндәге «яңа» әдәбиятыбызга игътибар итсәк, без аны *«Асылга кайтыш чоры»* дип тә атар идек.

Безне бу хезмәттә Беренче дәвер татар әдәбияты кызыксындыра. Фәндә кабул ителгәнчә, аны *Борынгы һәм урта гасырлар чоры* дип йөртәләр. Әмма аның үз исеме бар. Ул — *«Төрки дәвер»*.

Татар әдәбияты тарихында «төрки дәвер» X гасырдан алып XIX йөзнең 80 нче елларынача килә.

Моннан соң «Яңа чор» башланып китә. Ул XIX гасырның беренче чирегендә үк үзенең килүен сиздерә башлый һәм шушы йөзнең икенче яртысында ныклап үсеп китә. Аны башлаучы кеше дип без шагыйрь Габделҗәббар Кандалыйны атыйбыз. Прозада М.Акъегет, драматургиядә Г.Ильяси, шигърияттә аны М.Акмулла иҗатлары нигезли. К.Насыйри аның үсешенең мәдәни тел шартларын тудырган.

Димәк, төрки дәвере татар әдәбиятының нигезен хасил иткән һәм олуг булган чоры. Үзе ул сигез йөз елга сузыла, тагын да төрле этапларга бүленә:

1. Угыз-кыпчак чоры, ягъни X-XII йөзләр.
2. Алтын Урда дәүләтчелеге чоры, XIII-XIV йөзләр.
3. Ханлыкларга бүленеш, таркаулык чоры (икенче төрле аны хаталы рәвештә Казан ханлыгы чоры дип атап йөртәләр), XV-XVI йөзләр.
4. Яңадан тернәкләнү яки «ренесанс» чоры. XVII йөздән башланып китә.
5. Романтизм яки элегик дәвер. XVIII йөз ахырыннан XIX гасырның икенче яртысын үз эченә ала.

Татар әдәбиятының төрки дәвере тәсаувыф, ягъни суфичылык әдәбияты булуы белән аерылып тора. Бу чорда Ислам дине идеологиясе әдәбиятның төп юнәлешен тәшкил итә һәм синкретик характерда, ягъни әдәби әсәр эстетик әһәмияткә генә ия булмыйча, шактый киң кулланылышта йөри. Чәчмә һәм тезмә әсәрләр әдәбият җәүһәрләре булулары белән беррәттән, уку әсбаплары, дини-дөньяви дәреслекләр сыйфатында да кулланыла. «Бакырган китабы», Алтын Урда язучысы Насретдин Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихлары»), Мөслимнең «Тәварихы Болгария»се, Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се, Әхмәт Биҗанның «Әнварел-гашыйкыйн» («Гашыйклар нуры») һ.б., һ.б. әдәби ядкәрләр йөз еллар буена мәдрәсәләрдә шәкертләр өчен дәрес бирүдә файдаланылып киленә. Алар рәтендә Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф»ын, Таҗетдин Ялчыгылның «Рисаләи-Газизә»сен, Әхмәт Яссәвинең «Хикмәтләр» китабын, Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» әсәрен кертеп карамыйча һич мөмкин түгел. Боларның берләре кыз балаларны укытуда файдаланылган булса, икенчеләре ир балаларга дәрес бирүдә алыштыргысыз чыганак саналган. Шул ук вакытта ул китаплар дини кичәләрдә уку, йола башкару өчен дә кесә китапчыклары булганнар. Аларда, бер яктан, әдәбилек көчле, икенче яктан, дини-дөньяви гыйлемне дә үзләренә сыйдырганнар. Фән һәм әдәбият бергә кушылу, синтетик бөтен хасил итү аркасында ул китаплар гасырлар буена практик әһәмиятләрен югалтмаганнар, укучыларда эстетик зәвык белән беррәттән, аларга гыйльми информация дә биреп, аң үсешен тәрбияләү өчен дә хезмәт иткәннәр. (Бүгенге көндә, мөгаен, тарихи романнар гына шундый үзенчәлекне үзләрендә үстерә алганнардыр?)

Борынгы дәвер, төрки чорының икенче бер әһәмияте — шигъриятнең гөрләп чәчәк атуында. Гарузга күчү, бармак үлчәменнән баш тарту, читләшү кискен һәм тизлек белән үсә. Күләмле дастаннар пәйда була. Төрки шигъриятенең беренче этабында суфичылык төп юнәлеш буларак шигърияттә куәтләнсә, икенче этапта, ягъни Алтын Урда чорында мәхәббәт лирикасына, сөю-сәгадәт дастаннарына, җиңел жанрларга кызыксыну арта, аннан соң, өченче этапта исә, яңадан суфичылык үсеш ала, әмма мәхәббәт, гашыйклар тематикасы да үз көчен югалтып бетерми, ә соңгы этабы кабаттан суфичылыкның күтәрелеп китүе белән кызыклы.

Бу чорның өченче бер үзенчәлеге дидактик эчтәлектә булуы белән бәйле. Ул практик эчтәлектә дә көчле. Кешене үгет-нәсыйхәт бирү аша бәхетле итәргә омтылу гына түгел, бәлки, бе-

ренче чиратта, аң-белем бирүгә юнәлеш тоту, икенчедән, кулланылыш сферасын киңәйтү максатыннан чыгып шулай эшләнелгән алар.

Төрки дәверенең тагын да әһәмиятле ягы шунда ки, тарихи әсәрләр әдәбият кануннарына буйсындырылып эшләгәнлектә. Монда без һич тә сюжетка кору хакында сүз алып бармыйбыз, бәлки әдәби уйдырманы, формаларны да авторларның оста файдалануларын күздә тотабыз. Бу да язучыларның синкретик формаларга омтылулары хакында сөйли.

Бишенче үзенчәлек барлык төрки авторларның бер әдәби телдә язарга теләүләрендә чагыла. Харәзм төркисе белән чыгтай төркисе татар әдәбиятында гүяки үзара ярышалар. Әле берсе алга чыга, әле икенчесе. Әмма төрки телнең асылында Харәзм төркисе ятканлыктан һәм аның кыпчак элементын нигез итеп алуы сәбәпле татар әдипләре күп очракта шушы әдәби телдә язуны өстенрәк санаганнар. Гарәпләр өчен ничек Мисыр диалекты әдәби тел булып киткән, төрле гарәп дәүләтләрендә яшәүче язучылар да ничек аңардан әдәби әсәрләрен язганда файдаланганнар һәм кулланганнар, төрки кавеме дә, үзләренең төрле дәүләтләргә таркалып яшәүләренә карамастан, шулай ук уртак бер әдәби телгә, Харәзм төркисенә тартылганнар.

Бу чорның татар укучысы башка төрки әдәбиятлар белән дә нык кызыксынган, аларны халык арасына таратуда укымышлылар зур роль уйнаганнар, теге яки бу гомум билгеле шагыйрьгә ияреп язарга омтылганнар. Моны алтынчы үзенчәлек дип билгеләргә мөмкин. Шуның аркасында татарлар арасына «Алты бармак», «Мөхәммәдия», «Әнварел-гашыйкын» кебек әсәрләр үтеп кергәннәр һәм тиз арада таралыш тапканнар. Бу чор әдәбият үсеше асылда компиляция юлы белән алып барыла. Халык әдәбияты иҗаты әсәрләре шагыйрь һәм язучылар тарафыннан “яңартылган” шикелле, гарәп һәм фарсы әдәби ядкәләре нәзыйрә формасында төркиләштерелә, төрки халыкларга атап языла. Моның Алтын Урда чорында тагын да активлашуын күрәбез. Сәбәбе шунда ки, татар халкы бу дәвердә гомумислам мәдәниятенең төп вәкилләреннән берсенә әверелә. Бу “вәкиллек”не ныгыту өчен Ислам мәдәниятенең үзенчәлеген тәшкил иткән әдәби һәм фәнни әсәрләргә иярү, компиляция алымы белән якын килү, аларны нәзыйрә жанры кысаларында халыкка җиткерү эше киң җәелдерелә. Бу дәвернең әдипләре һәммәсе дә диярлек компиляция алымнарына таянып иҗат итүне әдәби кредолары итеп алалар.

Борынгы әдәбиятыбызның җиденче үзенчәлеге — гарәп-фарсы әдәбиятларына хас жанрлар (кыйсса, дастан, кыйтга, газәл, касыйдә, хикәят, риваять, кысалы кыйсса һ.б.) төрки-татар әдәбиятларының төпжанрларына әверелә. Шәрыклык тәмам өстенлек ала башлый.

Шулай итеп татар әдәбияты Шәрык тибында үсеш алып китә.

Татар әдәбиятының төрки дәверенә менә шушы гомуми үзенчәлекләр хас. Әлбәттә яңа дәвердә бу әһәмиятле яклар арткы планга калалар һәм, татар әдәбияты, милләтнең шәхси үз мәнфәгатьләрен күздә тотып, татар халкына йөз белән борыла һәм милли юнәлештә үсеп китә.

Әдәбиятны төркемләгәндә чит илләрдә өчкә аерып карыйлар: эстетик әдәбият, мифологик әдәбият, психологик әдәбият дип. Совет чорында әдәби тәнкыйть социаль әдәбиятка зур игътибар биреп, мифологик әдәбиятны бөтенләй күрми дә иде. Әмма эстетик әдәбиятның да, социаль әдәбиятның, мифологик һәм психологикның да үз урыны бар, алар һәрберсе тулы канлы милли җирлектә үсәргә тиешләр. Ә менә төрки дәверендә болар барысы да бергә укмашып, бер кыса эчендә бергә үстерелгәннәр, хәтта бер үзенчәлек икенчесенә кереп береккән. Яңа дәвер исә моны тарката һәм һәр юнәлешне аерым үстереп җибәрә.

Фикергә йомгак ясап шуны әйтергә кирәк, һәр әдәбиятның үз үсеш этаплары, этапларның үз үзенчәлекләре бар. Борынгы татар әдәбиятында ул төркичелек һәм суфичылык белән характерлана.

ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАРЫНЫҢ ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕНӘ ТАРТЫЛУЫ

IX-X гасырларда төрки халыкларның күпчелеге диярлек ислам диненә таба авышкан һәм ислам диненә багланышкан иделәр. Исламның керүе, таралуы аларның алга таба үсешен тәэмин итте. Чөнки дин белән бергә халыкларның дөньяны танып белүе үзгәрде, фәлсәфә, фән, мәдәният үсешендә яңа мөмкинлекләр ачылды, дөньяны үзгәртү, аны яңача, шәригать нигезендә кору һәм шуның ярдәмендә дәүләтчелекләрне алга таба үстерү юллары беленде.

Төркиләр арасында Ислам киң колач белән җәелдерелә башлаган гасырларда мөселман дөньясында суфичылык чәчәк ата иде. Шунлыктан безнең халыклар арасына кергән ислам дине дә тәсаувыф, суфичылык фәлсәфәсе белән ныгытылган, әхлак кануннарының өстен куелган булуы белән характерлы.

Ислам дине беренче чиратта төркиләр арасында фән үсешенә юл ачкан булса, суфичылык исә, үз ягыннан, әдәбият, бигрәк тә шигъриятнең чәчәк атуын тәэмин итте; Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуни кебек дөньякүләм әһәмияткә ия булган шагыйрьнең төркиләр арасында үсеп чыгуы моның ачык мисалы булып тора.

ЙОСЫФ ХАС ХАҖИБ БАЛАСАГУНЛЫ

(XI гасыр)

Тормышы. Борынгы шагыйрьләр вә язучылар үзләренең әсәрләрен ханнарга яки халыкка атап, аны «ядкәрем булсын» дия торган булганнар. Тарих аларның үзләре хакында онытса да, әсәрләре сакланып калсын өчен шулай эшләгәннәр алар. Әгәр дә Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуни (Йосыф Баласагунлы) әсәрләрендә үзе хакында мәгълүматлар калдырмаган булса, бүгенге көндә без аның кемлеген азмы-күпме күз алдына китерүдән бәлки мәхрүм калыр идек.

Йосыф Баласагунлының бердәнбер әсәре тарих каршылыкларын үтеп, бүгенге көнгә килеп җиткән. Ул — «Котадгу билиг», ягъни «Белем бәхете» (яисә “Белем куәте”) дастаны.

«Котадгу билиг» әсәреннән күренгәнчә, Йосыф Баласагуни үз чорының олы укымышлыларыннан берсе, ул география, тарих, астрономия, гарәп-фарсы телләре, гаруз гыйльме кебек фәннәр белән яхшы таныш булган. Аның туган җире — Баласагун шәһәре, заманы өчен төрки үзәкләренең берсе булган җир. Монда, аерым алганда, кыпчак кабиләләре башчылык иткән. Әмма ул Караханилар дәүләте эченә кергән.

«Котадгу билиг»тән беленгәнчә, әсәр һиҗри ел исәбе белән 462 елда тәмам булган. Миладигә күчергәндә ул 1069/70 елларга туры килә. Дастаннан шул күренә, авторга ул вакытта инде 50 яшьтән югары булган дигән бәхәсле фикер яши. Димәк, Йосыф Баласагуни моңа кадәр дә әдәби иҗат белән шөгыльләнгән, ә «Котадгу билиг» дастанын дөньяга карашлары тәмам формалашып җиткәч һәм үгет-нәсихәт яшенә ирешкәч иҗат иткән булып аңлашыла. Болардан чыгып, Йосыф Баласагуни 1020 еллар тирәсендә дөньяга килгән дип әйтергә мөмкин. Әмма бу дәлилләнмәгән һәм ышандырып җиткерми.

Йосыф Баласагуни «Котадгу билиг» әсәрен Баласагунда яза башлый һәм аны Кашкарга килгәч тәмамлый. Ул үз чорының бөек әдибе буларак күз алдына килеп баса. Төрки телен гарәп һәм фарсы телләре алдында күтәрүе, шигъри тел булуын раславы белән ул үзенә карата зур хөрмәт уята, әсәре шуның аркасында төркиләр арасында гына түгел, бәлки башка халыкларда да шөһрәт казана, әмма төрле исемнәр белән төрле аталып йөртелә, өйрәнелә һәм соклану тудыра. «Котадгу билик»нең мөкаддимәсендә (сүз башында) язылган: «Мачин галимнәре вә хәкимнәре камуг иттифак булдылар, кем, мәшрик вилаятендә Төркестан илләрендә Буграхан теленчә бу китаптан яхшырак һәргиз кем ирсә тәсниф кылмады. Бу китап падишаһка, йә каю икълимгә тигде ирсә, гаять үзлекындин, ниһаятедин, кача күреклекдин ул илләрнең хөкүмаләре, галимнәре кабул кылып, такма бере-бер төрлег ат ләкап бирделәр: чинлыглар «Әдәбел-Мөлек» ат бирделәр, Мачин малигенең надимнары «Гайинул-Мәмләкәт» дип әйттеләр, иранлыклар «Шахнамәи-төрки» диделәр, бәгъзеләр «Пәнднамә мөлек» димешләр, Туранлыклар «Котадгу билиг» тип әймешләр...» (*Хәзергечә:* “Мачин (Хорасан) галимнәре һәм хаким-фикер ияләре барчасы бер сүздә булдылар, көнчыгыш тарафында Төрек илләрендә Буграхан телендә бу китаптан яхшырак һичкем язмады[1]. Бу китап падишаһка яки кайсы тарафка

[1] Димәк, “Мөкаддимә” өлешендәге бу сүзләр текстка күчерүчеләр тарафыннан соңрак кертелгән булып чыга. Моны өстәп теркәүчеләр Буграхан җирләреннән

ирешсә, гаять үзенчәлекле, бөтен, нинди яхшы булуына күрә ул илләрнең хөкемдарлары, галимнәре аны кабул итеп, һәркайсы үзенчә аңа исем бирделәр: кытайлар “Хөкемдарлар әдәбе” дип атадылар, Хорасан мәлиге хезмәтендәгеләр “Мәмләкәт тәртибе” дип әйттеләр, фарсылар “Төрки шаһнамәсе” диделәр, кайберәүләр “Мәликләргә үгет китабы” дигәннәр, туранлылар “Бәхетле белем” дип әйттеләр...”)

Йосыф Баласагунлы үзенең әсәрен язып тәмам иткәч, аны Карахани дәүләтенең хөкемдарына тапшыра. Ул ханның исеме Таугач Буграхан — Таугач олуг Бугра Карахан әбу Гали Хәсән бине Арысланхан була. Таугач сүзе император мәгънәсендә кулланылган. Аны «кыргызлар»[1] исә табгач дип әйткәннәр һәм бөтен кытай халкы да шул исәптән табгач дип йөрткәннәр. Димәк, бу исем-атаманы караханилар кытайлардан алганнар, таугач дигән сүзе белән титулны белдергәннәр, ханның исемен дә, шуңа күрә, Олуг император Бугра Карахан әбу Гали Хәсән бине Арыслан хан дип белергә кирәк.

Буграханга Йосыф Баласагунлының «Котадгу билиг» дастаны хуш килә һәм шуның аркасында ул шагыйрьгә хас хаҗиб, ягъни витязь, данлыклы каһарман дигән дәрәҗә бирә, аны хезмәткә алдыра. Бу фактка игътибар итсәк, әдипнең бу вакытта ничә яшьләрдә булуын төгәлрәк ачыклый алабыз. Шунысы кызыклы, витязь (каһарман) титулын егет кешегә бирәләр, әгәр шагыйрьгә 50 яшьләр икән, хан аны башка төрле дәрәҗәгә лаеклы күрер иде. Шулай итеп, “Котадгу билик”не Йосыф Баласагунлы 20 яшьләре тирәсендә, 30 яшьләренә кадәр үк язган булып чыга, туган елының да 1050 еллар тирәсендәрәк икәнлеген белдерергә мөмкинлек туа. Аны падишаһның шәхси киңәшчесе дәрәҗәсендә да күзалларга урын кала.

Буграханның дәүләте ул дәвердә төрки ханлыкларның иң зурларыннан булган. Ул Кашгардан алып Әму-дәрья буйларына кадәр җәелгән. Әмма бу ханлык ул чордагы башка дәүләтләр төсле үк аерым ханлыклардан торган. Буграхан үзе олуг хан саналган һәм аның титулы, инде күреп үткәнебезчә, таугач-хан, яки табагач-хан дип аталган, аңа буйсынган халыкларның хөкемдарлары исә илек-хан, яки илхан, ягъни ил эчендәге хан рәвешендә аерылып йөртелгән.

көнбатыштагы илләрнең береннән булганлыклары да шушының белән дәлилләнә ала.

[1] Кыргызлар — Орхун-Енисей төркиләре.

Караханиларның ике олуг ханлыклары үсеш ягыннан алга киткән, аның берсе (үзәге Кашгар) Шәркый Төркестан дип аталып йөртелсә, икенчесе (үзәге Баласагун, яки Җиде-Су) ярым күчмә төркиләр иле, Татарстан дип аталган.

Иҗтимагый үсеш ягыннан Җиде-Су ханлыгы Шәркый Төркестаннан шактый артка калып барган, әмма кызларының чибәрлеге, ирләренең батырлыгы белән дәүләт эчендә генә түгел, шәрык илләрендә дә дан алган. Өченче мәдәни үзәк буларак караханилар дәверендә Үзгәнд шәһәре һәм аның тирәсендәге төркиләр оешып алалар, озак та үтми, бу ханлыкның башкаласы булып Сәмәрканд ныгып китә.

Караханиларда, традиция буларак, ханлыклар белән Буграханның туганнары, малайлары идарә итәләр. Һәркайсына аерым дәүләтчелек кирәк була. Шулай итеп Тираз, Фирганә ханлыклары да оешып ала. Мондый империя белән идарә итү өчен шактый күп көч гаскәр, чыгымнар кирәк була. Табагач-ханга буйсынып яшәгән илек-ханнар, кыскартып атап әйткәндә (тарихта ул шулай атап йөртелә дә) — илханнар үз мәнфәгатьләрен өстенрәк күрәләр, үзара ызгыш-талашларга юл куялар, сәясәтне үз теләкләре белән йөртергә тырышалар. Бу куркынычны Йосыф Баласагуни яхшы аңлаган, моннан котылу юлын акыл белә эш итүдә, бер-береңне аңлауда күргән һәм шунлыктан үгет-нәсихәт бирүне үзенә бурыч итеп куйган. Әсәрнең ул вакыт өчен популяр булуын искә алсак, автор үзалдына куйган бурычына ирешкән дип санарга мөмкин. Әмма аның иҗатының тарихи әһәмияте моның белән генә бетми. Йосыф Баласагуни гаҗәеп зур катлам — суфичылык, тәсаувыф шигъриятенә төрки әдәбиятында нигез салып, аны үстереп җибәргән.

Әсәрдә халык иҗатына таяну, шигъри өлгеләрне тулысынча диярлек аннан алу ачык сизелеп тора. Шагыйрә монда импровизация ысулын оста файдалана. Вакыйгаларны халыкка яхшы таныш булган тарихи үткәннән алып сурәтли, шунлыктан аның каһарманнары да мәҗүси исемнәр белән бирелгәннәр. Бу аңа үз чорына хас булган Ислам идеологиясенә хезмәт итүдә комачаулык тудырмый.

Әсәрдә халыкның данлыклы үткәне киләчәк буыннарга үрнәк алынырга тиешле өлге итеп сурәтләнелгән.

«Котадгу билиг» дастанының кульязмалары хакында. Аның өч кульязма нәсхәсе сакланып калу хакында фәнгә билгеле. Беренчесен Х1Х гсырның 20 елларында Истанбул шәһәрендә галим Хаммер

Пургшталл тапкан һәм Вена китапханәсенә тапшырган. Бу кульязма 1439 елда Һиратта Хәсән Кара Саил Шәмс тарафыннан уйгур язуы белән күчерелгән булган. Ул нөсхәне беренче мәртәбә француз галиме Жауберт Амадес 1823 елда тикшереп, махсус мәкалә белән чыгыш ясаган.

Нәсхәләрдән икенче кульязманы 1896 елда Каһирәдә (Мисыр) табып алганнар. Ул гарәп язуы белән XV гасырда күчерелгән, аны мәмлүк (бәлки Алтын Урда булуы да бар) нөсхәсе[1] диләр. Өченчесен исә 1913 елда Наманганда булган вакытында татар галиме Әхмәд-Зәки Вәлиди табып алган, бүгенге көндә бу нөсхә Үзбәкстанның Фәннәр Академиясе Шәрыкны өйрәнү институтында саклана. Әхмәд-Зәки Вәлиди тапкан кульязма, башкаларыннан камилрәк булып, тулырак сакланган. Ул XIII–XIV гасырларда күчерелгән.

«Котадгу билик»нең кыскача эчтәлеге һәм төзелеше. Әсәрнең тулы нөсхәсе чама белән 6500 бәеттән[2], ягъни 13000 мисрагтан[3] тора. Ул барысы 73 бүлеккә-фасылга бүленгән. Шуларның ике бүлеге мөкаддимә-сүз башын үз эченә ала. Бу өлештә гарәп-фарсы дастаннарына хас рәвештә Аллаһы тәгаләгә, Мөхәммәд пәйгамбәргә, хәлифәләргә традицион мактау укыла, аннан Бүграханга дан җырлана, белем-мәгърифәт мәсьәләләренә багышланган бүлекләр урнаштырылган. Дастанны хасил иткән төп бүлекләр 12 фасылдан тора. Әсәрнең башында ук чәчмә сөйләм белән, кереш рәвешендә мондый хәбәр бирелгән, ул сюжетны аңлау өчен «ачкыч» хезмәтен үти: «Агыр ул үзә бина кылмыш торыр: бере — гадел, икенче — дәүләт, өченче — гакыл, дүртенче — канәгать; янә тикмә береңә төркичә бер ат биреп торыр: гаделлеккә — Көнтугды элек ат биреп, падишаһ урынына тотмыш; дәүләткә — Айтулды ат биреп, вәзир урынына тотмыш; акылга — Угдулмыш ат биреп, вәзиренең углы йирендә тотмыш торар; канәгатькә — Узгурмыш ат биреп, карендәше дип әйтмеш торыр. Тәкый аңлар ара моназзара сөали-җаваби кичәр тик сүзләмеш торыр. Укуглы күңле ачылып, мөсаннифка изге дога берлә яд кылсын!» (*Хәзергечә:* Әсәр дүрт нигезгә корылган: берсе — гаделлек, икенчесе — канәгатьлек, өченчесе — акыл, дүртенчесе — канәгатьлек; тагын да һәркайсына аерым исем бирелгән. Гаделлеккә — Көнтуды ир /Тәңре/ исеме биреп, падишаһ уры-

---

[1] Төркиядә факсимиле басмасы да дөнья күрде.

[2] Бәеттән — шигъри икеюллык, яисә строфа.

[3] Мисраг — шигъри юллык, яисә строка.

нына куйды, дәүләткә Айтулды /Тулган ай/ исеме биреп, вәзир урынына тотты, акылга Укытылмыш /Укытылган, Белем иясе/ исеме биреп, вәзирнең улы урынына тотты, канәгатькә Узгырмыш /Уздыручы, Хезмәт итүче/ исеме биреп, карендәше дип әйтер. Шул рәвешле алар арасында фикер алышу буларак сорау-җавап белән сөйләшү барыр. Укучының күңеле ачылып, язучысын изге дога белән искә алсын!")

Димәк, язучы үзенең әсәрен шушы дүрт фәлсәфи башлангычка нигезләнеп корган икән: 1) гаделлек, 2) дәүләтчелек, 3) акыллылык, 4) канәгатьлек; һәрберсенең, алга таба, кемнәргә хас булырга тиешлеге ачыкланылып үткән. Гаделлек — хөкемдарларның сыйфаты булырга тиеш икән, шуңа күрә дә андый падишаһ Көнтугды, ягъни якты китерүче, таң билгесе, Тәңре икән. Гаделлекне югалтмасын өчен дәүләтдәүләтчелек идарәсен хөкемдар вәзиргә тапшыра һәм аннан бу эшне таләп итүе белән ул өстен тора икән. Акыл белән канәгатьлеккә килсәк, бу сыйфатлар яшьләргә хас булып, алар шуның белән ханлыкны бизәп торалар икән. Сүз башыннан менә шулар аңлашыла һәм дастан тулысы белән шушы формулага буйсындырылган.

Әсәрнең кыскача эчтәлеге моннан гыйбарәт: Көндугды дигән падишаһның даны төрле якларга таралып, ул кояш кебек галәмне нурландырып тора. Бу, аңлашыла булса кирәк, Буграханның үзе белән тәңгәл куела ала. Йосыф Баласагуни аны шушындый итеп күрә дисәк тә була. Айтулды дигән бер акыл иясе, монысын авторның үзе дип белергә кирәк, шушы падишаһка вәзир булып хезмәт итәргә уйлый,дусты Күсәмеш ярдәмендә бу максатына ирешә, Көндугдының вәзире хезмәтендә тора башлый.

Айтулды озак вакытлар вәзир булып, үзенең акыллы киңәшләре белән падишаһка күп ярдәмнәр итә. Әмма туган йорты һәм гаиләсен сагынып, Көнтугдыдан рөхсәт алып, иленә кайта. Шунда үлеп кала. Улы Угдулмышка падишаһ хезмәтенә барырга кирәген киңәш итә. Әтисенең сүзен Угдулмыш тыңлый һәм сарай хезмәтенә килә. Атасының үгет-нәсихәтләрен һәрдаим исендә тотып, падишаһка хезмәтендә даншөһрәт казана. Көнтугды белән Угдулмыш арасында төрле сөйләшүләр була, хөкемдар аннан акыллы сүзләр ишетә. Галим һәм акыл иясе булган Узгурмышны да падишаһ сарайга алдыра. Ул суфичылык юлына басып, дөньясын ташлап, сарайдан чыгып киткән булган. Берничә хат-хәбәргә җавап итеп, Узгурмыш кайтырга ризалык бирә. Үзенең идарә өчен шактый файдасы буласын аңлый, әһлак һәм әдәп принцип-

ларыннан чыгып эш йөртә, шушы яктан Көнтугдыга йогынты ясый, үгет һәм нәсихәтләр бирә. Падишаһ үзара хәбәрләшү-сөйләшүдә акрынлап булса да аның сүзләренә колак сала, киңәшләренең дөрес булуын ачыклый, күп файда итә.

Әсәрнең төп сюжет сызыклары менә шулардан гыйбарәт. Борынгы дидактик әсәрләр үзләренең хикмәтле сүзләргә, афоризмнарга, мәгънәләргә бай булулары белән аерылып торалар. Шунлыктан әсәрне җентекләп анализлаганда шактый кызыклы яклары чылып китә.

«Котадгу билиг» дастаны үз чорының дәүләт төзелеше, даирәләрнең үзара мөнәсәбәтләре, сарай тормышының рәвеше, халыкка карата хөкемдарның карашы кебек төрле-төрле мәсьәләләрне үз эченә алган киң кырлы, мәгълүматларга гаҗәеп бай әсәр. Анда караханилар дәверенең үзенчәлекле яклары гына түгел, бәлки авторның дә фәлсәфи һәм сәяси фикерләре чагылыш тапкан. Ислам идеологиясенә хас булганча, гадел дәүләт төзү омтылышы асылда дастанның төп идеясен тәшкил итә. Йосыф Баласагуни һәр материалын шуның өчен файдалана. Идеал хөкемдар итеп таныту Буграханның үзе өчен дә кирәк булгандыр, шуның өчен дә авторга зур игътибар биргәндер.

Йосыф Баласагуни төрки телнең патриоты гына түгел, бәлки феодал дәүләтчелекнең философ шагыйре дә. Үз халкына, үз теленә, бигрәк тә үз хөкемдарына бирелгәнлеге аркасында ул үз чоры өчен бөек шагыйрь булып китә. Әмма аны тәхеткә мәдхия җырлаучы шагыйрь генә икән дип тә күңелдә калдырырга ярамый. Автор бу рәвештә мактауларны үзенең сүзе хөкемдарлар колагына барып ирешсен өчен дә файдалана, асылда ул үз ватанын чәчәк атучы, алга киткән ил итеп күрергә тели һәм идарәчел даирәләргә үгет-нәсихәт бирү, шуның аша гадел җәмгыять төзү фикерен алга сөрә. Бу яктан «Котадгу билик» тагын да зур практик мәгънәгә ия булып тора.

Акыл бирү, үгет-нәсихәт — борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты өчен хас күренеш. Шул ук вакытта бу сыйфатлар Шәрык шигърияте өчен дә хас. Ислам диненең керүе һәм ныгуы, шәригать гыйлемнәренең өстенлек ала башлавы төрки әдәбиятында да бу күренешне тудырган һәм ныгытып җибәргән.

Шәригать кешенең көнкүрешеннән алып дәүләт төзелешенә кадәр булган барлык мәсьәләләрне дә кочаклап алырга омтыла һәм гадел җәмгыять барлыкка китерүдә практик йогынты ясарга тырыша. Дин, канун буларак кына түгел, бәлки әхлакый кагыйдәләр белән беррәт-

тән, сәяси тормышны да үз эченә буйсындырып тота. Әмма, кешелек тарафыннан тудырылган һәртөрле кануннар кебек үк, шәригатьнең дә үз йомшак яклары бар, шунлыктан ул да гадел җәмгыять турындагы утопияләрнең берсе булып кала.

Йосыф Баласагуни да утопист. Ул да гаделлек, акыл, белем культына нигезләнгән олуг дәүләт төзү, шуның ярдәмендә кешелекне бәхетле итү хакында яза. Әмма ул утрак феодал дәүләт тарафдары. Бу аңлашыла да. Ул вакытларда төркиләр күчмә тормыштан утраклыкка таба авышкан, утрак тормыш белән яши башлаган чаклар. Йосыф Баласагуни шуңа күрә дә утрак тормышлы дәүләтчелек белән яшәүдәге әһәмиятен тиз төшенеп алган һәм күчмә тормышны түгел, бәлки утраклыкны мактап язган.

«Котадгу билик»нең хөкемдарлар өчен аталган булуы эчтәлегеннән үк аңлашылып тора, моңа тукталып узган идек инде. Йосыф Баласагуни аларга акыл биреп кенә калмый, бәлки катгый таләпләр дә куя. Аның фикеренчә, хөкемдар каршында халыкның өч төрле теләге бар. Алардан беренчесе — акчаның үзкыйммәтен падишаһ күтәрү хакында кайгыртырга тиешле һәм моны күзәтеп торырга бурычлы, икенчесе — ышанычлы һәм тугры кануннар чыгаруы һәм аларны үзе дә, башкалар да үтәгәнне белеп, таләп итеп торуы, өченчесе — юлларны караклардан һәм бозучылардан саклауны, юлларны үз кулында тотуны оештыруы. Боларны үтәгән хөкемдарны, автор фикеренчә, халкы да яратыр һәм хөрмәт итәр, падишаһлыгы да чәчәк атар.

Алардан тыш, Йосыф Баласагуни хөкемдарның халыктан нәрсәләрне таләп итәргә тиешлеген белдереп үтә. Алар шулай ук өч нәрсә. Беренчесе — чыгарган кануннарыңны халык берсүзсез үтәсез һәм аларга буйсынсын, икенчесе — дәүләткә тиешле налог вә ясаклар вакытында җыелып, хәзинәгә тапшырылып торсын, өченчесе — бөтен халык падишаһның дустына дус, дошманына дошман кебек карасын. Шулай булган вакытта халык белән хөкемдар арасында үзара җәбер һәм каршылык кебек күренешләр күренмәс.

Йосыф Баласагунлы шушындый гадел җәмгыять итеп Көнтугды дәүләтен өлге рәвешендә күрсәтеп үтә һәм болай ди:

Илен итте, төзеде, баюды бөден,
Бүре куй белә сувлады ул үден.

(Илен итте, төзеде, баеды бөтен, бүре сарык белән сугарды үзен, ягъни бүре белән сарык бергә су эчтеләр).

Йосыф Баласагунлы тудырган образларның берсе — Айтулды. Ул шулай ук гадел җәмгыять тарафдарларыннан. Акыллы, дәүләтнең дөрес идарә ителүе өчен җан ата, илнең төзеклеген, үсешен тәэмин итү өчен үзен дә кызганмый, шәхси мәнфәгатьләренә караганда хөкемдары һәм аның падишаһлыгы хакында кайгыра. Ул шушы уйлар белән Көнтугдының хезмәтенә килә һәм бөтен көчен куеп, иле өчен хезмәт итә башлый. Автор аның хакында болай дип яза:

Хаҗиб күрде, Айтулды килде яңы,
«Әрәнә адинсыг кешедә уңы.
Әюр, күршем юк бу яңлыг кеше,
Билиглек, укышлыг бөдендә башы.
Бу мондаг кешеләр илегкә кәрәк,
Илегкә кәрәк наң, күр, илкә кәрәк...

(Хаҗиб күрде, Айтулды килде яңа, үзгә кеше; арада аның кебек уңай кеше; әйтер, күргәнем юк мондый яхшы кешене; белемле, укымышлы бөтенләй үзе; мондый кешеләр ил өчен кирәк; илгә кирәк нәрсә, күр, илгә кирәк...)

Автор Угдулмыш белән Узгурмышның сыйфатларын да шулай ук гадел һәм акыллы итеп сурәтли, хөкемдарның мондый сарай әһелләрен сайлап алуын олылый һәм мактап чыга, шушылар аркасында илнең дә бәхетле булачагын белдерә. Шул рәвешле ул идеал дәүләт образын тудыра һәм үзенең үгет-нәсихәтләре белән бу юлдан барырга чакыра. Әмма Йосыф Баласагуниның бу омтылышларын һич тә феодаль дәүләтчелекне идеаллаштыру дип аңларга ярамый, бәлки ул гадел җәмгыять төзү тарафдары, халыкны бәхетле итәргә омтылучы шагыйрь-философ кына. «Котадгу билик»нең тарихи һәм әдәби-эстетик әһәмияте менә шунда. Шуның өчен дә автор халыкның үз телендә язарга омтылган һәм уй-хыялларын сурәтләп бирергә тырышкан. Шагыйрьнең батырлыгы да менә шушында. Феодаль хакимият ныгып урнашкан бер вакытта үз халкын яклап яза алуы һәм хөкемдарларга үтемле формада бирә белүе белән ул тарих үсешенә шактый зур этәргеч биргән, үзен кешелекле, гуманист шагыйрь итеп күрсәткән. Ул үзен шигърияте ндә һәм фәлсәфәсендә акыл, гыйлем, әхлак принципларыннан чыгып эш йөртә һәм аларның культын тудыра. Аның фикер-

ләү рәвеше менә шушы өч нигезгә корылга һәм аларга таянып тора. Хәтта үлем хакында сөйләгәндә дә шагыйрь менә шушы өч принцибына нигезләнеп эш йөртә:

Үлемгә кечек юл терек булдачы,
Нәчә ма терелсә, үлем келдәче.
Ни яхшы әйер бу бөден башлар әр,
Белиген, укышын, эшен эшләр әр.
Нә әдге эш ирде, үлем булмаса,
Нә күреглек эш ирде кеше үлмәсә!

(Үлемгә кече юк терек булганда; ничә кат терелсә, үлем — килүче; ничек яхшы булыр барчага яхшы булыр барчага баш булган ир; белемле укымышлы эшен эшләр ир; ничек изге эш иде, үлем булмаса; ничек күркәм эш иде, кеше үлмәсә).

Мисал итеп китерелгән бу юлларда авторың өч принцибы (акыл, гыйлем, әхлак культлары) бар тулылыгы белән чагылыш тапканнар. Шулай да Йосыф Баласагуни бу урында теманы үлем белән чикли, әмма башка суфичылар төсле үлемне Аллаһы тәгаләгә китерүче олуг юл итеп белдерүдән ерак тора. Әгәр дә суфи шагыйрьләр үлемне изгелек һәм Хак тәгаләдән бирелгән игелек итеп күрү дәрәҗәсенә күтәрелгән булсалар, Йосыф Баласагунлы үз фәлсәфәсендә әлегә бу югарылыкка ирешмәгән, һәм, киресенчә, изгелекне үлемсезлектән күргән.

Болардан чыгып шуны әйтергә кирәк, Йосыф Баласагунлы суфи шагыйрьләрдән дини фәлсәфәдә шактый калышса да, мәгърифәт, әхлакый өстенлек принципларын күтәреп чыгып, төрки әдәбиятларында суфичылыкка нигез салучы һәм идеаль утопик җәмгыять тудыру хакында хыялланучы булып тора. Халыктан, илдән, гаиләдән аерылу һәм үзеңне Аллаһы тәгаләгә багышлау XII гасыр шагыйрьләрендә байрак итеп күтәрелсә, XI гасырда, киресенчә, ил эчендә халык бәхете өчен тырышлык кую идеясе өстенлек иткән, бу, мөгаен, яңа төрки дәүләтләренең оешуы һәм үсә баруы сәбәпле шулайдыр.

Йомгак. 1. Йосыф Хас Хаҗиб Баласагунлы — XI гасыр Караханилар дәүләтендә яшәп иҗат иткән иң олуг төрки шагыйрьләрдән берсе. Ул үзенең иҗаты белән төрки теленә һәм төрки дәүләтенә дан җырлаган, аларның патриоты булып формалашкан, халыкны да шуңа чакырган.

2. Йосыф Баласагунлы — утопист шагыйрь, ул гадел җәмгыять төзү принципларын иҗат иткән.

3. Йосыф Баласагунлы — акыл, мәгърифәт, әхлак культын төрки шигъриятьтә үстергән шагыйрь.

ӘХМӘТ ЙӨГНӘКИ
(XII–XIII)

Борынгы төрки әдәбиятыбызның гүзәл ядкарьләреннән берсе — «Һәйбәтел-хакаикъ» (“Хакыйкать көче”) әсәре, үгет-нәсихәткә корылган, шигырь белән язылган, тарихи әһәмияткә ия булган поэма дастан. Ул төрки әдәбиятларында, шул исәптән татар әдәбиятында да аерым урын тота. Аның авторы — Әхмәт Йөгнәки (Югнәки).

Тормышы һәм иҗаты. Әхмәт Йөгнәки хакында тарихи хәбәрләр бик аз сакланып калынган. Аның кайсы елларда һәм кайсы ханлыкта гомер кичерүе, ил эчендә нинди дәрәҗәдә тотуы мәгълүм түгел. Бары тик бердәнбер әсәре — «Һәйбәтел-хакаикъ» кына сакланып калган, моннан башка нинди шигырьләр вә дастаннар язуы фәнгә мәгълүм түгел. «Һәйбәтел-хакаикъ»та авторның үзе хакында аз булса да хәбәр бирелгән, әсәрнең язылган елы, китапның исеме белдерелмәгән. Болардан авторың үзе турында артыгын сөйләргә теләмәгәнлеге генә ачыклана ала. Ул болай ди:

Әдип Әхмәт атым, әдәп-пәнд сүзем;
Сүзем монда калыр, барыр мин үзем.

Монда автор үзен Әдип Әхмәт дип кенә атый һәм үгет-нәсихәт биреп язучы икәнлеген күрсәтә, максатының җирдә сүз калдыру булуын билгеләп үтә. Фәнгә Әхмәт Йөгнәки үз әсәрен XII гасыр ахырларында, XIII йөз башларында иҗат иткәнлеге мәгълүм, башка хәбәрләр әлегә юк. XV гасыр тимурилар чоры шагыйре Арысланхуҗа Тарханнан мондый юлларны укыйбыз:

Әдипнең йире аты Йөгнәк ирер,
Сафлык гаҗәп ир, күңелләр ирер.

Атасы аты Мәхмүт Йөгнәки,
Әдип Әхмәт — углы, юк ул һич шәги.

Китапның аты ирер «Һәйбәтел-
Хакаикъ», гыйбарәт гарәптән ушул.

Тәмамы ирер кашгари тел белә,
Әйтмеш Әдиби рикъкате дил белә.

Аңар булса кашгар телен һәр кеше,
Белер ул әдипнең нә кем әйтмеше.

Кеше телне белсә, белер мәгънәсен,
Белермен дисә, гайб үзе белмәсен.

(*Сүзлекчә:* Йире — җире; сафалык — кәеф-сафалы; шәги — шик; ушул — шул; рикъкате дил белә — назлы, нечкә тел белән; аңар булса — аңласа; гайб үзе белмәсен — белмәвендә үзе гаепле).

Арысланхуҗа Тарханның бу мәгълүматыннан күренгәнчә, Әхмәт Йөгнәки үзе Йөгнәк дип аталган йирдә туган икән, кашкар төрки телендә иҗат белән шөгыльләнгән, үзен Әдип дип атап йөрткән, ә китабы «Һәйбәтел-хакаикъ» исеме белән таралган булган. Ул гына да түгел, Әхмәт Йөгнәки шат күңелле, кәеф-сафа коруны яраткан, шушы сыйфаты белән халык арасында мәгълүм булган. Аның атасы да танылган кешеләрдән, Мәхмүт Йөгнәки исемле булган, аны әдипләрдән, яисә галимнәрдән дип фараз итәргә мөмкин.

Әхмәт Йөгнәкинең заманы өчен танылган шагыйрь булганлыгы һәм аның ирләр башы, ягни шәехләрдән исәпләнүе дә билгеле. Аңа карата язылган бер шигырь юллары бар:

Әдипләр әдибе, фазыйллар башы,
Гәүһәрдин сүз әйтмеш, әйтсен сүз башы,

Уган рәхмәт итсен бу сәгать аңа,
Ярин купса, булсын әйраннар башы.

(*Сүзлекчә:* Әйтен — әйт, әйткән, Уган — Аллаһы тәгалә, Ярин — Таңда, Кыямәт көнендә).

Бу мәгълүматлардан Әхмәт Йөгнәки олуг әдип булып күз алдына килеп баса, ул киң белемле, фикерле кеше, гарәп-фарсыны яхшы белгән һәм халкына хезмәт күрсәтүне үзенә максат итеп куйган. Әдипләр әдибе дип аталуы да шуннан, аның шәкертләре дә җитешкән, танылганнар. Моңа карап без Әхмәт Йөгнәкинең озын гомер яшәгән булуын әйтә алабыз.

«Һәйбәтел-хакаикъ» әсәренең саклануы. XX гасыр башларында, Беренче Бөтендөнья сугышы алдыннан төрек галиме Нәҗип Гасыйм Истанбулдагы Айа-Суфия мәсҗеденең китапханәсендә бер кулъ-

язма таба. Ул фәнгә моңа кадәр билгеле булмаган шагыйрь Әхмәт Йөгнәкинең «Һәйбәтел-хакаикъ» әсәре булып чыга. Аны 1480 ел 21 январендә (884 ел Һиҗри, 7 зөлкагыйдә) Габдеррәзак Бахши дигән кеше Истанбул шәһәрендә күчереп бетергән, уйгур язуы белән булып, кайбер сүзләргә гарәп язмасы белән тәрҗемәләр бирелгән. Моннан соң тагын да бер нөсхәсе, Һиҗри исәптә 848 (М.: 1444/45) елгы күчермәсе табылган.

Нәҗип Гасыйм 1916 (Һ.: 1334) елда «Һәйбәтел-хакаикъ» әсәренең 1480 елгы кулъязмасын эшләп, төрек теленә тәрҗемәсе, сүзлеге һәм гыйльми мәкалә белән бастырып чыгара. Төрек галиме Рәшит Арат Рахман (тумышы белән татар) 1951 елда әсәрнең тәнкыйди текстын эшләп бастыра. Айа нигезләнеп, 1972 елда К.Мәхмүтов Ташкентта Әхмәт Йөгнәки әсәрен бастырып чыгара. Болардан күренгәнчә, Йосыф Баласагунлы белән чагыштырганда, Әхмәт Йөгнәкинең телендә гарәп-фарсы элементлары күбрәк, лексик состав катлаулырак икәнлеге сизелә. Шул ук вакытта суфичылык фәлсәфәсенең соңгысында шактый үскәнлеге күренә.

«Һәйбәтел-хакаикъ» әсәренең төзелеше һәм сюжет-эчтәлеге. Автор үзенең әсәрен ундүрт бабтан (бүлектән) тора дип белдерә:

Туйга күрмәс ирде Әдипнең күзе,
Төзәтте бу ундүрт баб эчрә сүзе.

(*Сүзлекчә:* Туйга — ачык, тулы).

Әмма дә ләкин 1480 елгы борынгы нөсхәсе бары тик унбер бабтан гына гыйбәрәт булып, 235 бәеттән төзелгән. Моның сәбәбе бик үк ачык түгел, бәлки Габдеррәзак Бахши күчермәсе берәр тулы булмаган нөсхәдән алынгандыр, бәлки күчерүчеләр өч бабны башкаларына кушып җибәргәндер? Бу рәвешле хаталанулар әлбәттә иске күчермәләр арасында еш очрый, шунлыктан һәртөрле кулъязмаларын алып тикшергәндә дөрес булыр иде.

«Һибател-хакаикъ» дастанының беренче бабы ун бәетне үз эченә ала һәм традицион рәвештә автор аны Аллаһы тәгаләгә дан җырлау белән башлап җибәрә. Икенче баб Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аны дүрт сәхабәсенә багышланып, унбердән унтугызынчы бәетләрне туплап тора. Өченче өлеш дад-сипаһсаларга багышланган һәм 20 нче бәеттән алып 33 нчегә кадәр дәвам итә. Дад-сипаһса дигәне диннең каһарман

дин ирләре бәкләр булып, автор аларга үзенең әсәрен юллап язган икән. Ул аларны фикерле, яхшылыклы һәм гадел затлар дип атый һәм дүртенче бабата, ягъни 34-39 нчы бәетләрдә «Һәйбәтел-хакаикъ»ны алар өчен бер ядкарь буларак язылды дип күрсәтә:

Дад-сипаһсалар бәк өчен бу китап,
Чакарттым ачында аты калсу тип...

Белек иттем аны шаһымга мәнук,
Һәвадарлыгымны төгәл белсү тип.

(*Сүзлекчә:* Дад-сипаһсалар — ирләрнең-ире, рыцарьлар; чыкарттым — яздым, чыгардым; ачында — чынлыкта, дөньяда; калсу — калсын; тип — дип; белек иттем — белдердем; мәнук — мин үзем; һавадарлыгымны — һавалануымны, горурлыгымны; төгәл белсү — тәмам, ачык белсен.)

Шулай итеп, беренчедән алып дүртенчегә кадәр булган бүлекләр дастанның башлам өлешен алып торалар һәм мөкадимә нисбәтендә карала алалар. Моннан соң килгән бишенче баб исә «Һәйбәтел-хакаикъ»-ның асыл өлеше булган. Бишенче баб 40 нчыдан 62 нче бәеткә кадәр сузыла һәм белемнең мактаулы икәнлегенә, наданлыкның яманлыгына багышлана. Алтынчы баб 63 нчедән 86 нчыга кадәр бара, тел әдәбе мәсьәләсен күтәрә. Җиденче бабка килгәндә, ул 87 нче бәеттән 110 га кадәр булып, дөньяның фанилыгына, гомернең узгынчы булуына багышланган. Сигезенче баб 111 нчедән алып 175 нче бәеткә кадәр килә һәм диндарлык, дөньядан аерылу мәсьәләләрен үз эченә ала. Тугызынчы һәм унынчы баб исә 176 дан 226 нчы бәеткә кадәр килеп, һәртөрле мәсьәләләрне күтәрә. Унберенче баб йомгак өлеше булып килә. Анда мондый юллар бар:

Әдип Әхмәт атым, әдәп-пәнд сүзем,
Сүзем монда калыр, барыр бу үзем,
Калыр көз, кичәр яз, барыр бу гомер,
Тугатты гомерне бу язым-көзем.

Аның уш чыкарттым бу төрекчә китап,
Кәрәккыл тип, и дуст, кәрәккыл хитап,
Бетидем бу тансык тураф сүзләрен,
Кали барса үзем, атым калсу тип.

(*Сүзлекчә*: Әдип-пәнд — әдип үгет; тугатты — тузгытты, бетерде; анын уш — аның өчен; чыкарттым — чыгардым, яздым; кәрәк — кирәк; тип — дип; хитап — үгет, чакыру; бетидем — яздым; тураф — кадерле; кали — кая; калсу тип — калсын дип).

«Һәйбәтел-хакаикъ» аерым бер сюжетка корылмаган, ул акыл бирү, үгет-нәсихәт кылу юнәлешендә эшләнелгән. Шунлыктан әсәрне эчтәлек калыбында тикшерү авыр, аерым темаларга бәйле рәвештә анализларга кирәк.

Әхмәт Йөгнәки, Йосыф Баласагунлы кебек үк, мәгърифәт — әхлак — акыл культын алга сөрә һәм үзенең фикерләрен шушы фәлсәфәгә буйсындырып бирә. Аның белдерүенчә, гыйлемле кеше әхлаксыз һәм акылсыз була алмый, белемле булганда һәркем үзенең исемен җирдә калдыра ала, аны башкалар да белә, хөрмәт итә, ә белемсезләр яшәгән вакытларында ук үлгән исәпләнәләр.

Белекдин аерман сүземга ойма,
Белеклеккә, йә дуст, үзеңне ойла,
Белек берлә беленер сәгадәт юлы,
Белек бел, сәгадәт юлыны буйла.

Бәһалык динар ул белеклек кеше,
Бу җаһил белексез — бәһасез бише,
Белеклек белексез качан тиң булыр?
Белеклек төше — ир, җаһил ир — тише.

Сөнгәккә йилек тәк, иранга белек
Иран күрке — акыл, ул сөнгәкнең — йилек,
Белексез — йилексез сөнгәктәк хали,
Йилексез сөнгәккә сонылмас илек,

Белек белте булты иран билгелек .
Белексез терек лә йитек коргылык,
Белеклек ир үлте, аты үлмәте,
Белексез исән иркән, аты үлек.

(*Сүзлекчә:* Белек — белем; ойма — оема, буйсынма; ойла — оет, буйсындыр; җаһил — надан; тише — балта; сөнгәк — сөяк; тәк — тиешле, хас; иран — диндар ир; сөнгәк — сөяк; хали — буш; сонылмас илек — кул сузылмас; белте — белде; булты — булды; коргылык — корылык; үлте — үлде; үлмәте — үлмәде; иркән — икән).

Әхмәт Йөгнәки белемне сөяк эчендәге җилек белән тиңли һәм шул рәвешле белемле ирнең кадере зур икәнлеген белдерә, кыйммәтле алтын акча кебек, ди.

Шунысы әһәмиятле, Әхмәт Йөгнәкинең “җилекле сөяк”, “җилекле сөяккә кул үрелә” кебек образлы гыйбарәләре Ислам мәдәнияте вәкилләренең күпчелегенең күңелләренә хуш килмәс иде. Чөнки шәригать таләбе буенча, сөяк эчендәге җилекне ашау, ризык итеп куллану хәрам саналган. Бары тик Мисырда мәмлүкләр хөкемдарлыгы урнашкач кына шәригатькә үзгәреш кертелеп, сөяк җилеген ашау мәкруһ дип игълан ителә. Әүвәле кыпчаклар белән бәйле төбәкләрдә, Болгар илендә, ә аннары Алтын Урдада сөяк җилеген ризык буларак куллану, Ислам динендә булуларына карамастан, бервакытта да хәрам дип игълан ителмәгән. Бу фактны искәртү үзе генә дә Әхмәт Йөгнәкинең нәселнәсабе, яшәгән иле кыпчаклар белән бәйле түгелме икән дигән фикер уята. Әмма шагыйрьнең, үзенең үк, әсәрен “кашкар теле белән” язуын искәртүе генә мәсьәләне чишмичә, ачык калдыруга этәрә.

Әхмәт Йөгнәки белемне үзен генә аерып куймый, бәлки аны әхлак вә әдәп белән бәйли, шул вакытта гына кадере артканлыгын сөйли, ә әдәпнең билгесен телдә дип күрсәтә:

Ишеткел, белеклек нәгү тип әюр,
Әдәпләр башы — тел күтәзмәк торыр,
Телең бакта тотгыл, тешең сынмасын,
Кале чыкса, бакта тешеңне сыюр.

Санып сүзләгән ир сүзе сүз сагы,
Үкеш яңшаган теләй улмас ягы,
Сүзең бушлык исмә, йийга тот телең,
Йитәр башка беркөн бу тел бушлыгы.

(*Сүзлекчә:* Нәгү тип әюр — нәрсә дип әйтер; күтәзмәк — күтәрмәк; бакта — бәйле; кале — сүзе; сыюр — сындырыр; санып — сакланып; үкеш яңшаган — күп яңгыраган, сөйләгән; улмас ягы — булмас файдасы; йийга — җыя).

Әхмәт Йөгнәки метафоралар, символар белән сурәтләп язарга яраткан, аның теле образлы һәм үтемле, әсәре дә хикмәт әйтүгә тартым. Аның шигъриятен өйрәнеп, төрки дөньясында суфичылыкның борынгы дәверләрдә үк киң таралган һәм тәсаувыф шигъриятының шактый

үскән булуын әйтә алабыз. Әхмәт Йөгнәки моңа үзенең иҗаты белән зур өлеш керткән һәм үз чорының прогрессив әдибе буларак тархка кереп калган. Аны Галишир Нәваи кебек олуг шагыйрьләр дә укыганнар, канатлы сүзләрен үз әсәрләрендә файдаланганнар. XVIII йөз башы Тобул шагыйре Һәмдәми Шөкер бине Гаувас-бай иҗатына караган күләмле «Нәсыйхәтнамә» әсәрендә дә «Һәйбәтел-хакаикъ»ның традицияләре дәвам иткән һәм үстерелгән. Күзе ярым сукыр булуына карамастан, Әхмәт Йөгнәки алдан күрүчән һәм тирән фикер иясе булган.

Йомгак:1. Әхмәт Йөгнәки — борыгы төрки әдәбиятында Йосыф Баласагунлы кебек әхлак — мәгърифәт — акыл культын алга таба үстергән XII гасыр ахыры XIII йөз башының бөек шагыйре.

2. «Һәйбәтел-хакаикъ» әсәре белән Әхмәт Йөгнәки хикмәт жанры традицияләрен үстереп, төрки әдәбиятларында ныгытып калдырган шагыйрьләрнең берсе, прогрессив фикер иясе.

ӘХМӘТ ЯССӘВИ
(1091–1166)

Дөньякүләм урын тоткан шагыйрьләрнең иң дәрәҗәлеләреннән берсе — Әхмәт Яссәви. Аны «Ак суфи», «Ак мулла» исемнәре белән дә атап йөртәләр. Моның сәбәбе — ул өйрәткән дин юлының төзеклеге һәм камиллеге, тарикатенең сафлыгы һәм турылыгы белән аңлатыла. Татарлар, иман мәсьәләсендә: «Кем силсиләсеннән, ягъни буыннар бәйләнешеннән торырсың?» — дигән сорауга: «Хуҗа Әхмәт Яссәви рәхмәтуллаһ галәйһе силсиләсеннән торырмын!» — дип җавап бирләр. Бу факт исә Әхмәт Яссәвинең татар халкына рухи ата булуын дәлилли, шунлыктан аның әсәрләрен белү, аларны өйрәнү һәрбер татар өчен дә кирәк һәм мөһим. Әхмәт Яссәвине халкыбыз борынгы вакыттан бирле укып-өйрәнеп килгән, мәдрәсәләрдә аның буенча гыйлем алганнар, кичәләрдә хикмәтләрен укыганнар. Китаплары Казанда XIX гасырдан бирле туктаусыз бастырылып килгән. Борынгы татар мәдәниятен Әхмәт Яссәвисез күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Аның хикмәтләре тупланмасын «тифтәр» («дәфтәр») дип атап йөрткәннәр, Әхмәт Яссәви тарикатен тотучы зур бер төркем татарлар, шушы дәфтәрләргә (тифтәрләрләргә) нисбәтле рәвештә, «типтәр» атамасы белән төркемләнгән. Бүгенге көнгә кадәр шагыйрьнең ике дәфтәре сакланып калган.

Аның беренчесе «Дәфтәре-әүвәл» («Беренче дәфтәр») дип, икенчесе исә «Дәфтәре-сани» («Икенче дәфтәр») исеме белән атала.

Әхмәт Яссәвинең тормышы. Шагыйрьнең 1166 елда (Һ.: 562) вафат булуы билгеле. Ул 1091 елда (Һ.: 484), хәзерге Казакъстанның төньяк-көнчыгышдагы Яссы елгасы буендагы Төркестан шәһәрендә туган. 75 ел гомер кичергән. Шул ук вакытта, Әхмәт Яссәви 130 ел гомер кичергән дигән хәбәрләр дә фәнни әдәбиятта һаман да китерелә. Бу мәгълүматлар хакыйкатькә хилаф түгел исә, шагыйрь 1036 елларда дөньяга килгән булып чыга. Әмма дә ләкин моның дөреслегенә ышану бик авыр, галимнәр монда аның әтисе Ибраһим Яссының да яшәү елларын Әхмәт Яссәвигә нисбәт иткәннәр булырга кирәк.

Әхмәт Яссәви 63 яшьтә җиргә керү-үлүне мәслихәт дип исәпли, чөнки ул 63 яшьтә дөньядан күчүне шәригать буенча дөрес дип саный, Мөхәммәд пәйгамбәр дә шул яшендә үлгән.

Җандин кичмәй «һу-һу» дигән бары ялган,
Бу кылдакдин сорман сөаль юлда калган,
Хакны тапкай үзе пинһан, сүзе пәнһан,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йийргә, —

(*Сүзлекчә:* Җандин — җаннан; кылдакдин сорман — кыланучыдан сорама; сөаль — сорау; пәнһан — серле).

дип белдерә шагыйрь.

Әхмәт Яссәви 63 яшендә кабергә кереп ятса да, аңа үлем килми, ул ике ай буена көндез һәм кичләрен бер нәрсә дә ашамыйча-эчмичә ач ята, әмма җанын үлем фәрештәсе барыбер үз кулына алмый, урап кына уза.

Шулай итеп Әхмәт Яссәвигә 63 яшендә Газраилның кулы тимичә үтә һәм ул кабергә кереп яткан җиреннән кире чыгарга мәҗбүр була. Бу хәл аны бик нык тетрәндерә. Наданнар аннан көлә.

Бер яшемдә әрвах миңа өлеш бирде,
Ике яшьтә пәйгамбәрләр килеп күрде,
Өч яшемдә чилтан килеп, хәлем сорды,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йийргә.

Түрт яшемдә хак Мостафа бирде хөрмә,
Юл күрсәттем, юлга керде ничә хөмраһ,
Кайда барсам, Хозер бабам миңа һәмраһ,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йийргә.

Биш яшемдә билем баглап, тагать кылдым,
Татаувугы руза тотып, гадәт кылдым,
Кичә-көндез зикрен әйтеп, гадәт кылдым,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йийргә.

Алты яшьтә тормай качтым халаикъдин,
Күккә чыкып, дәрес үргәндем мәләикдин,
Дамин кисеп һәммә әһле галаикъдин,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йийргә.

(*Сүзлекчә:* Әрвах — рухлар; чилтан — гашыйк, *монда:* Аллаһы тәгаләгә гашыйк Мөхәммәд пәйгамбәр; сорды — сорады; түрт — дүрт; Мостафа — Мөхәммәд пәйгамбәр; хөмраһ — бозык; һәмраһ — юлдаш; баглап — бәйләп, максат итеп; тәгать кылдым — дога — намазда, гыйбәдәттә булдым; татаувугы руза — үз теләк белән ураза тоту; зикрен әйтеп — Аллаһының исемен әйтеп; тормай — тормыйча; халаикъдин — халыклардан; чыкып — чыгып; мәләикдин — фәрештәләрдән; дамин — итәк очын, бәйләнешне; галаикъдин — итәктән тотынып ияручеләрдән).

Әхмәт Яссәви үзенең шушы рәвешле яшь чактан, малайлыктан бирле дин юлында йөрүен, итагатьле бала булуын сөйләп чыга. Моның сәбәбе дә аңлашыла, чөнки аның атасы Төркестанда танылган суфилардан берсе булган һәм шәехлек тоткан. Әмма үзенең улына зур тәэсир ясарга, аны дин юлында тәрбия итәргә өлгерми калган. Әхмәтне дүрт яшеннән укырга-язарга өйрәтсә дә, аңа алты яшь җиткәндә үлеп китә.

Әхмәт Яссәвинең атасының исеме — Ибраһим Яссы, ул Төркестанда һәм аның тирәсендә сәйрамда шәехлек кылган, күп мөридләрне үз янына җыеп, аларны асраган суфи-ишан. Риваятьләргә караганда, шәех Ибраһим Яссының атасы Мәхмүд исемле булып, бабасы Ифтихар атлы икән. Берничә буыннан аларның шәҗәрәсе, ягъни нәселе, Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы Фатимага барып тоташа. Шушы сәбәпле Ибраһим Яссының авторитеты халык арасында мәшһүр икән. Ул үзе дә шагыйрь булган дигән хәбәрләр бар, әмма язган әсәрләре әлегә фән өчен мәгълүм түгел, суфи буларак, ул иң беренче, филисоф, дин галиме рәвешендә күз алдына килеп баса. Нәселе, бер яктан, Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташса, икенче яктан — күчмә кыпчак кабиләләреннән үк килә.

Әнисе — Гаишә-Хатун (халык аны Карасач-Сылу дип атый). Әхмәт Яссәвинең бертуган апасы — Гәүһәр Шаһназ.

Сөләйиан Бакырганига нисбәт ителгән һәм Әхмәт Яссәвинең хикмәтләр тупланмасына да кертелгән бер шигырьдә мондый юллар бар, алар аның шәҗәрәсен күз алдына китерергә ярдәм итәләр:

Аслы ирер ханидан,
Белмәс аны күп надан,
Белер аны Хак Яздан,
Шәйхем — Әхмәт Яссәви.

Исхак баба ярыны,
Шәйх Ибраһим колыны,
Мөшәихләр олугы
Шәйхем — Әхмәт Яссәви.

(*Сүзлекчә:* Аслы — асылы, нәселе; ханидан — ханнардан; Хак Яздан — Изге Аллаһ; ярыны — оныгы, нуры.)

Болардан шул аңлашыла, Әхмәт Яссәви төрки ханнар нәселеннән дә булган икән. Шулай ук монда аның бабаларыннан Исхак баба да телгә алынып үтелә, атасы Ибраһим шәех тә атала. Димәк, Әхмәт Ясәвинең шәех Ибраһим Яссы малае булуы раслана.

Әхмәт Яссәвигә атасының үлеме бик нык тәэсир иткән һәм ул, халыктан аерылып, үз алдына суфи-диндарга әверелә һәм җиде яшеннән Төркестанда Арыслан баба исеме белән дан тоткан икенче бер шәех тәрбиясенә керә.

Йите яшьтә Арслан бабам эзләп тапты,
Һәр сер күреп, пәрдә берлә бөркәп япты,
«Бихәмдулаһ, күрдем», — диде, эзем үпте,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

Кабиз, килеп, Арслан бабам җанын алды,
Хурлар, килеп, хәрир тундин кәфен кылды,
Йитмеш меңе фәрәштәләр йиглып килде,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

(*Сүзлекчә:* Йите — җиде; кабиз — җан алучы; хәрир — ефәк; йигълып — җыелып).

Төркестанлы Арыслан баба шәех Әхмәт Ясәвигә кардәш булганмы, әллә атасының да рухи җитәкчесе икәелеге ачык билгеле, әмма ул да Яссәвигә җиде яшь тулганда үлеп китә һәм булачак шагыйрь-философ тагын ялгызы кала, дин юлын ташламаска тырыша.

Сигеземдә сигез яндин юл ачылды,
«Хикмәт әйт!» — дип башларымга нур сачылды,
Бихәмдуллаһ, пире муган мәй эчерде,
Ул сәбәпдин алтмыш өчтә кердем йиргә.

(*Сүзлекчә:* Яндин — яктан; сачылды — чәчелде; бихәмдуллаһ — Аллаһыга шөкер; пире муган — җаннарны сугаручы Аллаһы тәгаләнең гыйлемен бирүче Мөхәммәд пәйгамбәр, монда, суфичылык термины буларак, Коръәнне аңлый башлау күздә тотыла).

Монда шагыйрь үзенең сигез яшьтән хикмәт әйтә башлавын хәбәр итә һәм «пире муган мәй эчерде» дип белдерә, ягъни җаннарны сугаручы Мөхәммәд пәйгамбәр кулыннан ул Ислам гыйлемен, Аллаһыга гыйбәдәт гыйлемен алуга ирешә. Аннан Әхмәт Яссәви белән Мөхәммәд пәйгамбәр очрашканнар икән дип уйларга кирәкми, бәлки образлы итеп әйтелгән фикер буларак төшенергә тиешбез. Димәк, сигез яшендә Әхмәт Яссәви бөтен җаны-тәне белән Ислам диненә бирелеп китә һәм беренче хикмәтләрен дә шушы яшендә әйтә.

Моннан соң шагыйрьнең авыр тормыш еллары башланган булса кирәк, ул үзен әле Шайтанга иярүче, әле Аллаһыны кабат табучы кеше итеп сурәтли, егерме алты яшенә җитә:

Мин егерме алты яшьтә сәүдә кылдым,
Мансур сыйфат дидар өчен гауга кылдым,
Пирсез йөреп, дәрт вә халәт пәйда кылдым,
Ул сәбәпдин Хакка сыгнып килдем мына.

(*Сүзлекчә:* Дидар өчен — Хак тәгаләнең йөзен күрү өчен; пирсез — шәехсез; сыгнып — сыенып).

Бу бәлаләрнең сәбәбен Әхмәт Яссәви шәехсез, рухи җитәкчесез эш йөртүеннән күрә һәм үзенең хикмәтләрендә юлдан адашмас өчен бербер шәехнең итәгенә ябышып “йөрү кирәклеген”, тәкрарлап уза. Үзенә рухи җитәкче кирәклеген аңлаганнан соң, Әхмәт Яссәви Бухарага килә һәм монда дан тоткан суфи шәехләрдән Йосыф Хәмәдани хәзрәтлә-

реннән тәсаувыф фәлсәфәсе буенча дәресләр ала, аның мөриде була. Ул вакытта Әхмәт Яссәвигә егерме җиде яшь икән.

Мин егерме йийте яшьтә пирне таптым,
Һәр ни күрдем, пәрдә берлә серне яптым,
Астанәсен, ястанибан, эзен үптем,
Ул сәбәпдин сыгнып килдем Хакка мына.

(*Сүзлекчә:* астанәсен — изге туфрагын; ястанибан — гаҗиз булып).

Утыз яшендә шагыйрь кабат үзенең туган — үскән җирләренә юл тота һәм үзе дә мөридләр асрый, тәрбияли башлый, шәех сыйфаты ала. Озакламый ул әүлия булып таныла, аның тарафдарлары арта һәм «Мәдинәдә — Мөхәммәд, Төркестанда — Хуҗа Әхмәт!» дигән әйтем халык арасында таралып, урнашып ала. Әхмәт Яссәвине пәйгамбәр белән тиңләү очраклары да була. Аның нәсыйхәтләрен тыңларга бик күп кешеләр җыела.

Әхмәт Яссәвинең халыкка танылу сәбәпләреннән берсе — ул төрки телдә иҗат итеп кенә калмый, бәлки хикмәтләрен мөмкин кадәр халыкчан яңгыраштa язарга омтыла, гаруз урынына, күп очракта төрки кавемнәренә, аларның иҗатларына хас булган бармак үлчәме белән иҗат итә.Аның әсәрләре динамик һәм көйле, тәэсирле булулары белән халыкның күңеленә бик тиз үтеп керәләр һәм киң таралыш табалар.

Инде билгеләп үтелгәнчә, Әхмәт Яссәви 1166 елда вафт була. Аны Яссы шәһәрендә олылап дәфен кылылар. Атасы шәех Ибраһим Яссы, анасы Гаишә-Хатун (Карасач-Сылу) да шунда җирләнгән. Ул каберләр күптән инде изге урынга әверелгән булса, Әхмәт Яссәви кабере суфи дәрвишләрнең Хак тәгалә серләренә төшенү җире булып китә. Ул гына да түгел, хәтта хөкемдарлар да аның исеме белән үзләренең сәяси эшләрен башлаганнар һәм бәйләгәннәр. Мәсәлән, Аксак Тимер исә, Алтын Урда ханы Туктамышны Әхмәт Яссәви мирасын талаудан гаепләп, аңа каршы гаскәрен күтәргән һәм Алтын Урданы, аның башкаласы Сарайны җимерүен дә шуның белән аңлаткан. Коканд ханы, шагыйрь Әмир Гомәрхан 1819 елда Төркестанга һөҗүм итә, аны басып ала һәм мондагы Яссәви каберендә шәехнең рухына атап 70 баш куй чалдыра, олуг корбаннар китерә. Әмир Гомәрханның Яссәви каберен болай олылавы, Аксак Тимернең Алтын Урданы җимергәннән соң, кайтып, Әхмәт Яссәви кабере өстенә күркәм төрбә-мәдрәсә төзергә

әмер бирүләре — барысы да аларның үз кылган гөнаһларын танулары һәм Аллаһы тәгалә алдында да, халык каршында да,татарлар алдында да гафу-тәүбә үтенергә омтылулары белән аңлатыла. Әгәр дә бу хөкемдарлар ул юлга басмаган булсалар, халык алдында аларның авторитеты какшар иде. Алар моны яхшы сизенгәннәр һәм Әхмәт Яссәви шөһрәте белән яхшы файдаланганнар.

Әхмәт Яссәвинең үз һәм ата-анасының каберләре генә түгел, хәтта нәселеннән булган кешеләрнең дә дәфен кылынган урыннары төрки халыклар тарафыннан изге дип саналганһәм аларга атап дога уку, корбан чалу гадәте таралган. Әхмәт Яссәвине олылап «хуҗа» исеме белән атап йөрткәннәр, һәрбер суфи шагыйрь шушындый мәртәбәле исемне алырга һәм аңа лаеклы булырга омтылган. Игелек ияләрен изгеләштерү — суфичылыкның төпр үзенчәлекләреннән берсе.

Әхмәт Яссәвинең иҗаты. Билгеләп үтелгәнчә, Әхмәт Яссәви тарихта ике әдәби-фәлсәфи «дәфтәрләр» калдырып киткән шагыйрь һәм философ. Ул «яссәвия», икенче төрле — «җахрия» тарикатенә нигез салган әүлия. Беренче “дәфтәр” Әхмәт Яссәвинең шушы тарикатьне өйрәтүгә багышланган трактатыннан гыйбарәт. Аның исеме «Фәкыйрь-намә» дип атала, яки «Дәфтәре- әүвәл». Моннан башка ул төрки шигырь формаларына һәм гарузга нигезләп язылган, бүгенгәчә сакланган 150 дән артык шигъри хикмәт авторы. Болары «Дәфтәре- сани, яки Диваны хикмәт» («Икенче дәфтәр, яки Хикмәтләр тупланмасы») дип аталып йөртелә. Болардан тыш ул мөнәҗәт жанрында да уңышлы эшләгән.

Әхмәт Яссәвинең «Диваны хикмәт» тупланмасы соңыннан җыелып һәм төрле күчермәләрдә йөргән булса кирәк. Чөнки кулъязма нөсхәләреннән сакланып калынган иң борынгырагы XVII гасырда төзелгән дип исәпләнелә. Ул иске тупланмалардан алынганмы, әллә инде электән шулай җыелып килгәнме, әлегә мәгълүм түгел. X1X йөздә һәм XX гасыр башында басылып таратылган «Диваны хикмәт» китапларының төзелеше төрлечә булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Күп очракта хикмәтләрнең урыннары алмаштырылган. Казан, Истанбул, Ташкент басмалары арасында да аерымлыклар бар. Безнең карашка Казан университетында 1904 елдагы бишенче басмасы камилрәк һәм ул башкалардын аерылып та тора. Әмма хикмәрләрнең санында һәм тәртип саннары күрсәтелешендә генә аерымлыклар һәм буталышлар күренеп тора. Бер үк сан икешәр тапкыр кабатланган урыннар бар. Шунлыктан галимнәр

Казан басмаларына 149 хикмәт кертелгән дип баралар, гәрчә аларда, анда кертелгән Сөләйман Бакыргани хикмәтен дә санаганда, 153 аерым әсәрнең хикмәт буларак тупланган булса да. 1905 елда Казанда бертуган Кәримовлар нәширлегендә чыккан Әхмәт Яссәвинең «Диваны хикмәт» китабында (аның текстларын басма өчен Уральски өлкәсе Гурьев өязе Бишенче номерлы татар казаклары авылы Манкышлау Танышлык угылы төзегән) 159 хикмәт кертелгән.

«Фәкыйрь-намә» («Дәфтәре-әүвәл») әсәре. Ислам дине һәм суфичылык хакында, «яссәвия (яки җахрия) тарикате» буенча булган бу трактат традицион эчтәлектә башланып китә, Аллаһы тәгаләгә, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның сәхабәләренә мактау сүзе бер җөмлә белән юлланганнан соң болай язылган: «Рисаләи Котыбыл-актаб вә сәрвәре мәшаих солтаныл-әүлия вә борһаныл әттакыя фәрзандхане Хәзрәте солтаныл-әнбия саллалаһү галәйһи вәс-сәлләм Хәзрәте Солтан Хуҗа Әхмәт Яссәви андаг әйтепдерләр...» (*Тәрҗемәсе:* «Аллаһы тәгалә хозурына лаеклы һәм дәрәҗәләр алган суфи, һәм шәехләрнең шәехе, әүлияләр солтаны, һәм хаксызлардан тыелучы пәйгамбәрләр солтаны (Мөхәммәд) хәзрәтләренә улы, Аллаһы тәгаләнең аңа ярлыкавы ирешсен, Солтан Хәзрәтләре Хуҗа Әхмәт Яссәви китабы шулай дип әйтептерләр...»)

Болардан аңлашылганча, Әхмәт Яссәви үзен Аллаһы тәгаләнең лаегына ирешкән камил суфи итеп белдерә, үзенең кем нәселе икәнлеген искәртеп үтә, шәехләр өчен дә шәех икәнлеген белдерә.

Әхмәт Яссәви сүзне Ахыр заман җитү хакында хәбәрләр бирүдән башлап китә һәм ул вакыт ирешүгә, шәехләр Иблистән үзләренә сабак алуларын, башкаларны да үзләренә ияртеп адаштырачакларын сөйләп китә. Алар, Ахыр заман шәехләре, яманлыкны яхшыдан өстен күрәчәкләр, садака бирмәгән мөридләрен ачуланырлар, үзләре һәм Аллаһы тәгалә мондый кешеләрдән бизәр дип сөйләрләр. Шуннан автор чын шәехләрне, тугыры дин ияләрен бәян итә һәм, киресенчә, мондый олуг затлар садака өчен түгел, бәлки мөридләрен тәрбия кылу, фәкыйрьләргә шәфкатьлелек күрсәтү өчен тырышачаклар һәм бәхетләрен шунда табачаклар, Хак тәгаләнең ярлыкавына ирешәчәкләр, ди. Мондый шәехләрдән дин таләбендә булган ирләр үрнәк алырга һәм аларга иярергә тиешләр, ул вакытта «эшең сәгадәт булгай». Болардан соң Әхмәт Яссәви кырык ел буена шәехнең хезмәтендә булмыйча торып, шәехлек дәгъва кылуны яманлык белән тиңләп күрсәтә, кырык ел мөрид хезмә-

тендә көч куймыйча гына шәех булып китүнең дөрес түгеллеген белдерә. Мөрид өчен төп бурыч — шәригатькә буйсыну, юкса тәмуг газабыннан котыла алмаячак.

Әхмәт Яссәвинең суфичылык фәлсәфәсе буенча, мөрид булырга уйлаган кеше дүрт кәлимәне, ягъни дүрт сүзне исендә тотарга тиеш, аларның беренчесе — «кәлимәи шәригать», ул моннан гыйбарәт: «Лә иләһә Иллаллаһ, Мөхәммәд рәсүлуллаһ!» («Аллаһыдан гайре илаһи зат юк, Мөхәммәд аның илчесе»).

Икенчесе — «кәлимәи тарикать», ягъни суфилык сүзләре, ул моннан гыйбарәт: «Лә Иләһә иллаллаһ, саффан-саффан Мөхәммәд рәсүлуллаһ!» («Аллаһыдан гайре илаһи зат юк, сафтан-саф аның илчесе Мөхәммәд пәйгамбәр!»

Өченчесе — «кәлимәи мәгърифәт», ягъни мәгърифәт, танып-белү, акыл белән төшенү сүзләре, ул моннан гыйбарәт: «Лә Иләһә иллаллаһ ба газәмәтиһи, Мөхәммәд рәсүлуллаһ халкыйһи!» («Аллаһыдан гайре илаһи зат юк, үзенең бөеклеге белән, Мөхәммәд аның пәйгамбәре!»).

Дүртенчесе — «кәлимәи хакыйкать», ягъни хакыйкать, зиһен белән тою сүзләре, ул моннан гыйбарәт: «Лә Иләһә иллаллаһ бикодрәтиһи Мөхәммәд рәсүлуллаһ бирисаләтиһи!» («Аллаһыдан башка илаһи зат юк, үзенең кодрәте белән,Мөхәммәд аның пәйгамбәре, илчелеге белән!»)

Болардан шул аңлашыла, Әхмәт Яссәви чын мәгънәсендә суфи булу өчен, иман китерү белән беррәттән, Мөхәммәд пәйгамбәрнең бөек пәйгамбәр булуын аңлау, Аллаһының кодрәтенә, көченә ышану кирәклеген белдерә. Автор суфиның асыл мәгънәсен фәкыйрьлектә күрә һәм аны иң өстен мәртәбә иясе итеп күрсәтә. Димәк, ул байлыктан йөз чөерә, аңа каршы рухи өстенлекне, гыйлем вә мәгърифәтне куя һәм Хак тәгаләгә, аның пәйгамбәре Мөһәммәд галәйһис-сәлам өйрәтмәләренә буйсыну, алар хакында уйларны күңелдә йөртүне кеше яшәешенең төп шарты сыйфатында төшендерә.

Боларны язып үткәннән соң, Әхмәт Ясәви ун куплетлы хикмәткә күчә һәм үзенең ничә яшьтә кайсы баскычка, ягъни мәкамьгә ирешүен сөйләп чыга, моннан соң фәкыйрьлекне пәйгамбәрләр, диндар галимнәр, гашыйклар мәкаме дип белдерә һәм дәрвишлекнең кырык баскычтан торганлыгын аңлатып үтә. Аларның беренче унысы шәригать мәкаме дип төрләнелә.

Шәригать мәкаменең тәүге баскычы — иман китерү, Аллаһы тәгаләнең берлегенә һәм барлыгына, сыйфатларына һәм затына инану. Моңа ирешкән кеше суфичылыкның беренче басмасына күтәрелә һәм аның алга таба менүе өчен намаз уку, ягъни бишвакыт намазны ташламау кирәк була. Бу — икенче басма. Өченче — ураза тоту, дүртенчесе — зәкәт, ягъни табышның кырыктан бер өлешен өммәтләр файдасына, дин юлына тапшыру, бишенчесе — хаҗга бару, алтынчысы — «мөләем сүзләмәк», җиденчесе — гыйлем өйрәнү, сигезенчесе — диндәшләргә ышаныч-терәк булу, тугызынчысы — мактаулы эшләр башкару, унынчысы — һәртөрле яманлыклардан тыелу. Әгәр дә дәрвиш боларга ирешсә, димәк шәригать гыйлемен үзләштергән һәм ун баскычны үткән санала ала.

Болардан соң ун баскыч тарикать, ягъни суфилык баскычлары килә. Боларны үтәгән кеше диндә адашмый һәм дәрвишлеккә лаек була ала.

Беренчесе — кылган гөнаһларың өчен тәүбәдә булу, икенчесе — шәехкә кул бирү, ягъни аңа ияру, өченчесе — Хак тәгаләнең газабыннан куркып, рәхмәт өметендә булу, дүртенче баскыч — туктаусыз Коръән уку, бишенчесе — һәртөрле рәхәтлекләрне ташлау, ләззәткә бирелмәү, алтынчысы — шәехнең хезмәтендә тору, җиденче басма — шәехнең рөхсәте белән генә сөйләшү, сигезенче — нәсыйхәт ишетү, нәсыйхәткә колак салу, тугызынчы баскыч — ялгызлыкны өстен күрү, унынчысы — үз алдына калып, күңелне Аллаһыга бәйләү.

Шулай итеп, беренче ун баскыч эш-гамәлнең рәвешләрен вә сыйфатларын үзләштерүне таләп итсә һәм күбрәк физик халәт мәсьәләсенә басым ясаса, икенчеләре — ун мәкамь — рухи халәтне үзенә терки һәм рухи үсешне таләп итә. Шуның белән Әхмәт Яссәви камиллеккә ирешү юлын өйрәтә һәм шушы юнәлештә үзеңне тәрбия иткәндә бәхетле булырга мөмкин икәнлеген белдерә. Шәригатьне үтәү, ягъни әхлакый яктан өстенлеккә ирешү һәм рухи дәрәҗәгә күтәрелү аша ул диндарларның җәмгыятьтән читләшүен дә таләп итеп куя.

Өченче дистә баскычлар мәгърифәткә бәйле. Аларның әүвәлге баскычы — фәна булу, ягъни бар нәрсәнең вакытлы гына булуын, җирдәге тормышның чиге барлыгын аңлау, монда бу дөнья белән түгел, бәлки Ахирәт тормышы белән яшәү рәвеше хакында сүз бара. Бу баскыч шуның белән әһәмиятле дә. Диндар, җәмгыять кайгыларын тормыш ваклыкларын читкә куеп, бөтен гомерне Аллаһы тәгаләгә багышлап, шул рәвешле тагын да рухи камиллеккә якынлашу. Икенче баскыч —

дәрвишлекне кабул кылу, ягъни суфи булып калу, кирегә таба чигенмәү. Өченчесе — һәрбер эшкә түземлек күрсәтү, никадәр кыен булса да сабыр итү, дүртенче баскыч — хәләл сафлык мәкаме, ягъни шапшаклыктан арынып, рухи һәм физик чисталык вә сафлыкка ирешү. Бишенчесе — мәгърифәт белән бәйле, һәрдаим аң-белемгә омтылу һәм башкаларны да агарту баскычы, алтынчысы — шәригать белән тарикатьне бер эздә дип белү, шул рәвешле рухи вә физик камиллекне бергә үстерү. Җиденче — дөньяны ташлау, Ахирәт көне белән яшәү. Сигезенчесе — Ахирәтне ихтыяр күрү, ягъни мәңгелекне Ахирәт тормышында күреп, бу тормышның җәбер — золым урыны икәнлеген аңлау, тугызынчы баскыч — Аллаһы тәгаләнең йөз нуры хакында хәбәрдар булу, унынчысы — хакыйкать серләрен төшенү. Ә хакыйкать мәкаме үзе ун баскычтан төзелеп, ул болардан гыйбарәт:

Беренче — туры юлда булу, адашмау, туры бару, икенчесе исә — фәкыйрьлекне өстен күрү. Бу урында Әхмәт Яссәви Гали бине Әбү-Талип сәхабә белән бәйләп хәбәр сөйли һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең мигъраҗы вакытында Аллаһы тәгаләнең фәкыйрьлекне никадәр өстен күргәнлеген бәян итә. Фәкыйрьлекнең төп сыйфаты — канәгатьлек, барча казага вә авырлыкларга түзем вә сабырлык күрсәтү. Бу — чын мәгънәсендә суфилык.

Хәзрәте Галидән алып, Әхмәт Яссәви фәкыйрьлекне тагын да төрле баскычларга бүлә һәм аларны санап чыга: 1) канәгатьлек; 2) бәлагә буйсыну; 3) илдән аерылу; 4) газап чигү; 5) ис китү; 6) гыйбадәт; 7) ачлык; 8) һәлакаттән курыкмау; 9) җан авыруы; 10) Аллаһы тәгалә гыйззәтендә булу.

Моннан тыш өстәмә тагын ун фәкыйрьлек нуры бар: 1) лаеклык нуры; 2) сабырлык нуры; 3) шөкер нуры; 4) фикер нуры; 5) зикер нуры; 6) намаз нуры; 7) ураза нуры; 8) иман нуры; 9) садака нуры; 10) пакь җан нуры.

Шулай ук фәкыйрьлекнең ун юлы бар: 1) тәүбә юлы; 2) гөнаһ вә языктан кайту юлы; 3) яман эшләрдән борчылу юлы; 4) ис китү юлы; 5) хурлык һәм зарлык юлы; 6) Аллаһының яры булырга омтылу, ягъни аның хакында йөрәктә яра йөртү юлы; 7) яман юллардан өркеп, үзеңне хәсрәттә тоту юлы; 8) Аллаһының исемен телдән вә күңелдән төшермәү, чыгармау юлы; 9) Аллаһы тәгалә хакында күңелдә фикер тоту юлы; 10) фәна булу, ягъни җир тормышыннан аерылу юлы.

Болардан тыш автор диндарлыкка тагын да ун урын барлыгын күрсәтә: 1) фәкыйрьлек; 2) хикмәт; 3) гаделлек; 4) акыл; 5) күңел йомшаклыгы; 6) оятлык; 7) гыйззәт; 8) яхшылык; 9) тәкъдиргә буйсыну; 10) әманәт саклау, буйсынучанлык.

Бу кырык мәкамьне күрсәтү белән Әхмәт Яссәви үз суфичылык фәлсәфәсен тарихта яшәп узган данлыкны шәхесләрдән дини хәбәрләрне китереп ныгыта һәм суфи кеше ялгыз чагында Аллаһы тәгаләнең зикре белән, халык арасында йөргәндә шәригать белән коралланган булырга тиешлеген өйрәтә. Болар беләнгенә калмый, автор суфичылыкның һәр ягын да ачыклап үтә һәм ул таләпләрне үтәгәндә Аллаһы тәгалә хозурына ирешәчәген белдерә. Анда тагын да дүрт баскыч булып, аларга болар ярдәмендә ирешелә: җәбрүт баскычы, ягъни Ахирәт урыны — монда шәригать китерә; мәләкүт баскычы, ягъни илаһилык урыны — монда тарикать китерә; лаһут баскычы, ягъни Аллаһы тәгаләгә ирешү, аның йөз нурын күрү — мәгърифәт белән җителә; соңгысы — насут баскычы, ягъни Аллаһы тәгаләнең илаһилыгында эрү, моңа хакыйкать китерә.

Боларны күрсәтеп, Әхмәт Яссәви «Беренче дәфтәрен» тәмам итә һәм үзенең суфичылык карашларын шул рәвешле тулысынча, төзек бер система рәвешендә күрсәтә. Дөрес, автор күп урында схематик рәвештә генә аңлатмалар биреп үтә һәм мәсьәлә бөтен нечкәлеге белән ачыкланып та бетми. Әмма «Икенче дәфтәр» белән танышкач, серләр ачылып киткән төсле була.

«Икенче дәфтәр, яки Диваны хикмәт». Әхмәт Яссәви сүзенең башында ук «Мин «Дәфтәр-сани» сүзен ачтым мына» дип белдерә. Шуны әйтергә кирәк, бу хикмәтләр тупланмасы аныңшәкертләре тарафыннан гына төзелмичә, бәлки үзенең тупланмасы булырга тиеш, чөнки ул турыдан-туры «Дәфтәре-әүвәл, яки Фәкыйрьнамә» белән бәйләнгән һәм аларны һич тә каршы куеп булмый. Шагыйрь шигъри югарылыкта үз фәлсәфәсен хис — тойгы эретмәсендә биреп бара һәм алар аша «яссәвия тарикате»нең серләре ачыла. Шул сәбәпле халык арасында аның хикмәтләре бик популяр булган.

Әхмәт Яссәвине кайбер фәнни хезмәтләрдә реакцион шагыйрь дип бәялиләр. Дөньяга кызыгудан аерылырга чакырганы һәм иҗтимагый тормыштан читләшүне өстен күргәне өчен аны феодаль даирәләрнең сәясәтен алып баручы дип билгелиләр. Әмма мода зур хата ясала. Чөнки Әхмәт Яссәвинең төп идеясы бу бәяләмәләр аркасында читтә кала

һәм ачылып җитми. Ул, иң беренче чиратта, шәхес ирекен бар нәрсәдән өстен куя. Феодаль җәмгыятьтә кешегә мөнәсәбәт кискен үзгәрү аркасында шәхес мәсьәләсе икенчел рольне үти башлый һәм хөкемдарлар үзләрен һәркемнән өстен дип бара, ул гына да түгел, аларның дәрәҗәсе һәртөрле чаралар беләнныгытыла. Әхмәт Яссәви үзенең фәлсәфәсендә вә шигъриятендә моңа каршы чыга һәм һәр мөселманның ирекле булуын, Аллаһы тәгаләгә бирелгәнлеге белән үз ирекен саклап калу юлын халыкка ачып бирә, шуның аркасында ул сөекле шагыйрьгә әверелә, халык тарафыннан әүлия буларак кабул ителә. Хөкемдар даирәләргә буйсыну урынына алардан баш тарту һәм шәхси ирекне саклап, шәхес булу юлын күрсәтүе белән ул үзенә кадәр яшәгән һәм иҗат иткән шагыйрьләрдән өстен чыга. Аның идеяләренең тарихи әһәмияте менә шушында.

Әхмәт Яссәвинең икенче бер үзенчәлеге, ул үз иҗатында классик төрки шигъриятен үстерүгә зур көч куйган шагыйрь. Хикмәтләрендә бармак һәм гаруз үлчәмнәрен оста файдаланып кына калмаган, бәлки аларның рифма үзенчәлекләрен дә үстергән. Хәтта гаруз белән язган хикмәтләре дә бармак үлчәме таләпләренә буйсындырылган. Шуның аркасында алар җырлап тора, төрки халыкларның күңелләренә үтеп керердәй итеп эшләнелгәннәр.

Әхмәт Яссәвинең өченче үзенчәлеге шунда, ул төрки шигърияттә суфичылыкны яңа баскычка күтәреп кенә калмаган, бәлки аны нигездән үзгәртеп корган. Моның өчен аңа фәлсәфи карашлары ярдәм иткән. Шуңа күрә дә тарихка иң олуг суфи шагыйрь буларак кереп калган. Аның укучылары төрки халыклар яшәгән бик күп төбәкләргә таралганнар, Әхмәт Яссәвинең данын үстергәннәр,үзләре дә аңа ияреп язганнар. Әхмәт Яссәви традицияләре XVIII гасыр азакларына кадәр, хәтта XIX йөзнең башларында да татар әдәбиятында яшәп кенә калмаган, бәлки күтәрелеш тә алган. Мәүлә Колый, Утыз Имәни кебек татар шагыйрьләре өчен ул шигъриятнең атасы буларак аңлашылган һәм алар аның традицияләрен үстерә алганнар. Шәмсетдин Зәки иҗатында да Яссәви рухы чагылыш тапкан, ул хәтта үзен дә суфи тәхәллүсе белән йөртә башлаган.

Әхмәт Яссәви укучыларыннан әдәбият тарихында иң зур урын тоткан шагыйрьләрнең берсе — Сөйләйман Бакыргани, бу фактны да искә алмыйча мөмкин түгел.

Йомгак. 1. Әхмәт Яссәви XII гасырда яшәп иҗат иткән, 1091 нче елда Төркестанда туган 1166 елда вафат булган данлыклы тарихи шәхес һәм бөек шагыйрь. Аның иҗаты дөньякүләм әһәмияткә ия.

2. Әхмәт Яссәви феодаль җәмгыятькә каршы күтәрелгән һәм шәхес иреген яклап иҗат иткән, зур әдәби мирас калдырган шагыйрь һәм философ, әүлия.

ӘХМӘТ ЯССӘВИ ШӘКЕРТЛӘРЕ

Төркиләр арасында Әхмәт Яссәвинең туксан тугыз мең мөриде булган диягән риваять бар. Шулар арасында берничәсе тарихларда танылып, исемнәре дә халыкка билгеле. Шулардан берсе — **Әмир Чин Госман**, аны икенче төрле **Шәрифи Госман**, яки ***Колшәрифи*** исеме белән атап йөрткәннәр. Кече Каран дигән авылда гомер кичереп, ислам шәрифе буларак дан тоткан. Шул ук вакытта, аның кабере дә изге саналып, аны Госман баба кабере дип йөрткәннәр. Хәбәрләргә караганда ул урын Кече Азиянең (Рум иле) Илле Бәкләр бәклегенең Йөздә Парә, ягъни Бозавык дип аталган төбәктә икән. Аның юлдашларыннан берсе **Гамидәтел-Мачин** исеме белән йөртелгән.

Әхмәт Яссәвинең укучыларыннан һәм хәлифәләреннән булган данлыклы суфиларның тагын берсе — **Хаҗи Бикташ Вәли**, ул Бәдәхшан җирләрен айкап, дәвишлек кылып, Билсу шәһәрендә үзенә мөридләр җыя һәм аларны тәрбия итеп, хикмәтләре белән 99 мең шәкетрне укытып, үз тарафдарларыннан итә. Карача Әхмәт Солтан, Сәед Нуретдин, Баязид Бөстами, Сары Исмәгыйль исемнәре белән дан тоткан имам һәм шәехләрдән гыйлем эзләп, дәрвишлек кылган, алар белән очрашкан, ислам дөньясында кирамәтләре вә могҗизалары белән хөрмәт казанган. **Киекле Баба, Карача Әхмәт, Ахи Әүран, Садретдин Кәүнәви, Шәмсе Тәбризи, Муса Әбдал, Дуглы Баба, Сәед Әхмәд Кәбир Рәфагый** һ.б. шәехләр — шагыйрьләр, әдипләр — болар барсы да Төркестанга килеп, Әхмәт Яссәви белән очрашканнар, кайсылары аның тәрбиясендә булган, кайсылары аның фәлсәфәсен өйрәнгән, кайсылары аның тарафдарына әверелеп киткән.

Әхмәт Яссәви үзенең хикмәтләрендә аларны, исемнәре белән аерым-аерым атап, исенә ала. Кайбер галимнәр, шагыйрьнең шул исемнәрне телгә алуыннан чыгып, болар — Әхмәт Яссәви псевдонимнары дип хаталаналар.

Әхмәт Яссәви шәкертләреннән халкыбызда дан тотканы — **Сөләйман Бакыргани**.

СӨЛӘЙМАН БАКЫРГАНИ
(1111–1186)

Татар халкы Сөләйман Бакыргани әсәрләрен укып тәрбияләнгән милләтләрнең берсе. Әдәбиятыбыз тарихын аннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел һәм аның иҗатын өйрәмичә үтүебез белән зур хата ясар идек. 1917 ел инкыйлабына кадәр аның әсәрләре Казанда кат-кат бастырылган, халык арасында киң таралыш тапканнар. «Бакырган китабы» Сөләйман Бакырганига нисбәттә шулай аталган. «Мәрьям ана китабы», «Ахыр заман китабы», «Хәким ата китабы» дип халык арасында яратылып укылган китапчыкларның авторы да менә шушы шәхес — Сөләйман Бакыргани. Аны Хәким ата да, Кол Сөләйман да, диләр.

Тормышы. Сөләйман Бакыргани 1111 елда Яссы (Төркестан) шәһәре янында сәйрамда туа. Тагын да шул билгеле, ул кыпчак кабиләләренең берсеннән булып, эти-әнисе Яссы (Төркестан) шәһәрендә яшәгәннәр. Мәктәп яшенә җиткәч, Сөйләманны укырга биргәннәр. Ул гыйлемгә омтылучан һәм акыллы бала булган. Риваятьләрдән күренгәнчә, мәдрәсәгә барган чагында башка балалар Коръәнне букчага салып, култык асларына кыстырып килгәндә, Сөләйман баш очына куеп, баш түбәсе белән күтәреп йөри икән. Башкалар мәдрәсәдән чыкканда йөгерешеп таралсалар, ул остазына йөз белән карап, арты белән чыга һәм арты белән кайта икән. Шушы хәлендә аны Әхмәт Яссәви күреп алган, игътибар күзен ташлап, аңа карата хөрмәте арткан. Сөләйманга: «Син, остазыңнан сорап, миңа күч, мин сиңа Коръән өйрәтермен», — дигән Әхмәт Яссәви.

Аның бу сүзен ишеткәч, остазы да рөхсәт биргән, ата-аналары да тиз ара Сөләйманны Хуҗа Әхмәт Яссәвигә китереп, тәрбиягә тапшырганнар. Малай үзенең зирәклеге белән тиз арада дан тапкан һәм олуг остазының хөрмәтен казанган.

Бу риваятьтән күренгәнчә, Сөләйман Бакыргани, Яссы шәһәрендә бала чагын уздырып, Әхмәт Яссәвидән белем алу бәхетенә ирешкән. Аның ата-анасы да бик диндар кешеләрдән булганнар. Аларның Әхмәт Яссәвигә хөрмәтләре зур икәнлеге дә аңлашылып тора.

Сөләйман Бакыргани 15 яшенә кадәр Әхмәт Яссәвинең шәкерте булып, аннан бик күп гыйлем таба һәм алга таба да дәрвишлек тәрбиясен күрү теләге белән мәдрәсәдә кала һәм шәехе каршында мөридлек хезмәтен тарта башлый. Әмма аңа Әхмәт Яссәви янында озакка булырга туры килми.

Риваятьләрдән беленгәнчә, Әхмәт Яссәви үзенең мөридләрен утынга җибәрә. Болар кайтып килгән вакытта яңгыр башлана. Сөләйман исә, киемнәрен салып, утынын төрә. Башкаларның утыннары юешләнә, шунлыктан, учак тергезгәндә аларныкы янмый, Сөләйманның киемгә төреп китергә утыннары коры булу сәбәпле, башкаларга анықыннан ут тергезелә. Бу бер хикмәт кебек аңлашыла һәм Сөләйман Бакырганига «Хәким ата» («Хикмәт илчесе, могҗиза күрсәтүче») дигән кушамат тагалар.

Бу аңа бик тә тәэсир итә һәм ул шунда беренче тапкыр күңеленә килгән хикмәтне әйтә, моның белән үзен җитлеккән, үзбашына фикерләүче итеп танытып, арада шөһрәт казана. Ул вакыйга аның бала чагында була.

Икенче бер вакыйга Корбан гаете көннәрендә була. Әхмәт Яссәви мөридләренең белем дәрәҗәсен сынау өчен биленә ике кат куй эчәгесе урый. Берсенә су тутыра, икенчесенә тын куа. Шәригать буенча, әгәр дә намазда ничкә җирдән һава чыкса да, әмма иссез генә килсә, яки әгъзадан нәҗесле су килмәсә, әмма башка төрле су төшсә дә, тәһарәт бозылмый. Шулай булгач, намазың да дөрес була. Әйтик, кеше борынавыз белән сулый, алардан тын йөри. Мондый нәҗес булмаган тын ничкә әгъзадан да үтәргә мөмкин. Болар тәһарәтне бозмыйлар. Һәм менә Әхмәт Яссәви сәҗдәнең әүвәлендә биленә уралган беренче эчәгене без белән тишә, аннан тын чыга. Дәрвишләре: «Хәзрәтебезнең тәһарәте бозылды!» — дип, тәһарәтләрен яңартырга китәләр. Сөләйман Бакыргани исә, шәехенә оеган хәлендә, намазында кала. Яннарындагы суфи Мөхәммәд Дәнешмәнд тә кала. Икенче сәҗдәдә Әхмәт Яссәви биленә уралган икенче эчәкне тишә. Су агып чыга. «Хәзрәтебезнең тәһарәте бозылды!» — дип, Мөхәммәд Дәнешмәнд китәргә атлый. Намаздан соң Әхмәт Яссәви, барча мөридләренә, Сөләйман Бакырганиның барча серләрне белүче камил шәех дәрәҗәсенә ирешүен игълан итә.

Сөләйманга Әхмәт Яссәви ирек дөя биреп, аңа шәехлек итәргә боера, аны үзе теләгән җиренә җибәрә. Әмма малының башыннан тотмас-

ка, кая барасы килсә, шунда килеп, чүккән җирендә тупланергә әмер бирә. Дөя Әму-дәрья буйларына таба юнәлә. Монда Караханиларның Бугра хан нәселе җирләре икән, ханның елкылары шушы тирәдә генә көтү булып йөри. Сөләйманның ул урында үзенә торак төзергә ниятен белүгә, көтүчеләр каршы төшәләр һәм аны куып җибәрмәкче булулар. Әмма Сөләйман, кирамәт күрсәтеп, могҗизасы белән аларны җиңә. Бу хәлдән хәбәр ханның үзенә барып ирешә. Әмма Әхмәт Яссәвинең мөриде булганлыгы аңлашылгач, Сөләйманга алачыгын төзергә ризалык кына бирелеп калынмый, бәлки кызы Гамбәрне дә хан аңа кияүгә бирә, үзе һәм сарай таифәсе мөридләре булып китәләр. Шулай итеп Сөләман Төркестаннан Хорасан җирләренә чыга һәм, алачык төзеп, мөридләр җыю эшенә керешә, шөһрәте тиз арада таралып, йорты тирәсенә кешеләр күченеп киләләр, шәһәр барлыкка килә. Бу каланы Бакырган дип атыйлар. Шуңа нисбәтле рәвештә Хәким ата Сөләйман да Бакыргани тәхәллүсен ала.

Бакырган атамасының исә «бакыр» сүзенә бернинди катнаша да юк. Чөнки Бакырган шәһәренең исеме «Кычкырып укып гыйбадәт кылу» тезмәсеннән кыскартылып ясалган, ягъни «Җаһрия» сүзенең төрки телдәгечә әйтелүеннән барлыкка килгән[1]. Сөйләманның дөясе шул таулы урынга килеп туктый да, бакырып чүгәли. Аны күпме кумасыннар, ул кузгалмый, бакыра бирә. Шәехе Әхмәт Яссәвинең фәрманын исендә тотып, Сөләйман нәкъ шушы урында урнашып кала. Язган әсәрләрендә Бакыргани имзасын куллана башлый, чөнки укытучысы һәм шәехе булган Әхмәт Яссәви кебек Яссы тәхәллүсен файдаланса, ул да Яссәви булып китәр иде һәм аларны бутау барлыкка килер иде.

Сөйләйман Бакырганиның Гамбәр анадан өч улы туа. Алар арасында Хөбби Хуҗа исемлесе аеруча сөекле булып, халыкның хөрмәтен казана.

Хөбби Хуҗа яшьтән зирәк бала була, ау һәм сугыш уенына бик маһир икән. Сөләйман Бакыргани аның яу җитәкчесе дәрәҗәсенә үсүен өметләнеп яши, әмма Хөбби Хуҗа кирамәткә ирешә һәм бу мәсьәләдә атасыннан өстенрәк тә чыга. Шул сәбәпле аралары бозылып, Сөләйман Бакыргани аны үз яныннан куа башлый. Хөбби Хуҗа моңа бик каты рәнҗи, анасы белән саубуллашып, күз алларында кәфенгә төренә дә «эреп» югала. Бу хәлдән соң Сөләйман Бакырганига: «Бу Хөбби

---

[1] “Җаһрия”сүзе төрки телдә “бакыру” була. “Сөләйман Бакыргани” дию дә, шулай итеп, “Җаһрияче Сөләйман” булып чыга.

Хуҗа нәселеннән алтмыш әүлия килер иде, хәзер алар һәммәсе дә дөньядан киселделәр, ул гөнаһыңны юар өчен кырык ел буена өстеңнән су агар», — дип белдерелә.

Сөләйман Бакыргани үлгәч, Әму-дәрья елгасы урыныннан күчә һәм шәһәрне ишеп, ярларны юып, кырык ел буена әдипнең кабере өстеннән ага. Сөләйман Бакыргани сөякләре дәрья астында кала. Шуннан соң гына елга үз ярларына кире кайта. Шәһәр дә, әүлиянең изге кабере дә эзсез югала. Баласына күрсәткән җәбере өчен ул шулай җәзалана.

Гамбәр ана язмышы да гыйбрәтле тәмамлана. Ул, хан кызы булурак, үзен Сөләйман Бакырганидан өстен куеп йөри. Хәтта бер вакыт, ире юынганда: «Шушындый ак тәнем белән мондый да ямьсез караңгы тәнле кешегә насыйп булганмын икән?» — дип хәсрәт йота икән. Сөләйман Бакыргани чыннан да кара тут йөзле вә тәнле, кыяфәткә әллә кем саналмаган ир икән. Ә Гамбәр ана исә, киресенчә, йөзгә-биткә бик чибәр булган. Хатынының мөнәсәбәте начарлана барганга күрә Сөләйман Бакыргани аңа бик каты үпкәләгән һәм улларына, үзем үлгәч, әниегезне кара тәнле, аксак һәм күзенең берсе сукыр кешегә иргә бирерсез дип васыять итеп калдыра. Мондый кеше табыла, ул бер зәнки дәрвиш икән. Гамбәр ана гомеренең соңгы көннәрен шундый ир белән үткәрергә мәҗбүр ителә. Халык телендә бу дәрвишне «Зәнки баба» дип йөртәләр. Безнең халыкта адарынган, яки үтенгән вакытларда әйтелә торган догалардагы «Зәнки баба», « Хөбби Хуҗа» дигән исемнәр, димәк, бер дә әллә кайлардан, мәҗүси вакытлардан ук килмәгәннәр, мифик затлар да түгел, бәлки реаль шәхесләр булганнар икән.

Сөләман Бакыргани 1186 елда вафат була. Ул үзенең укытучысы һәм шәехе Әхмәт Яссәвидән соң 20 ел яшәгән, олуг шәех булып танылган, остазы кебек, аның рухына ияреп хикмәтләр һәм поэмалар иҗат иткән борынгы иң мәртәбәле шагыйрьләребездән берсе сыйфатында әдәбият тарихына да кереп калган. Хәтта Габдулла Тукай да аның иҗатына соңланып, аның традицияләрен татар әдәбиятында яшәтүгә шактый өлеш керткән.

Сөләйман Бакыргани иҗаты. Аңа нисбәт ителгән дүрт китапның бүгенге көннәргә кадәр килеп җитүе хакында язып үткән идек инде. Шулардан берсе — «Хәзрәте Мәрьям разаллаһ ганһ» әсәре, икенче төрле әйткәндә, халык теледәгечә — *«Мәрьям ана китабы»*.

Бу әсәр беренче тапкыр Казанда 1878 нче елда дөнья күргән, аңа кадәр кульъязма хәлендә таратылган һәм укылган. Күләме кечкенә фор-

матта 8 бит. Казанда туктаусыз күп мәртәбәләр басылган, мәдрәсәләрдә һәм кичәләрдә уку китабы булып йөргән. Әсәр аерым сюжетка корылган көйле хикәя, яки поэма, 54 куплеттан тора. Һәр куплетның беренче өч мисрагы рифмалашыпкилгән, соңгы дүртенче мисрагы поэманың буеннан буена башка куплетларның ахыргы юллары белән ярәшеп, *бирдия, ирдия, тордия, килдия, булдия, тидия, кылдия* рәвешендә төрлечә алмашынып бара. Шушы рәвештә әсәр баштан ахырына кадәр үзара береккән бөтенлек хасил итә һәм шигъри форманы тагын да тотрыклы итеп, сыгылмалык тудыра. Көйне саклау җәһәтеннән дә бу рәвеш бик зур әһәмияткә ия.

Поэма Гайсә пәйгамбәргә һәм аның анасы Мәрьям хәзрәтләренә багышлап язылган. Аллаһы тәгаләнең кодрәт белән Гайсә пәйгамбәрне тудыруы һәм үзенчәлекле хас колы итеп сайлануы, «Инҗил»нең иңдерелүе сөйләнелгәч, автор болай ди:

Әүлияләр ыругы,
Әнбияләр соруры,
Хөрмәтене белдерде,
Күктә урын бирдия.

Шулай итеп, Сөләйман Бакыргани суфичылык фәлсәфәсенә хас рәвештә, Гайсә пәйгамбәрне, иң беренче сыйфатта, әүлия итеп күрсәтә, аннан соң гына пәйгамбәрлегенә басым ясый. Суфилар Гайсә пәйгамбәрне күккә күтәрелүе һәм Аллаһы тәгалә хозурына «эрүе» белән өлге итеп санаганнар. Хәтта суфилардан Мансур Хәлләҗ, Гайсә пәйгамбәрне Мөхәммәд галәйһис-сәламнән өстен куюда гаепләнеп, дар агачына астырылып, җәзалап үтерелгән.

Бу дөньяга бакмаган,
Малга күңел бирмәгән,
Ил эчендә тормаган,
Гайсә сәүче ирдия.

Талак бирде дөньяга,
Кадәм орды гокбәгә,
Тәгать кылды Мәүләмгә,
Төннәр уягъ тордия.

(*Сүзлекчә:* Сәүче — пәйгамбәр; кадәм орды — аяк куйды; гокбәгә — Ахирәт көненә , Аллаһы хозурына; тагать кылды — буйсынды, бил бөкте; Мүләмгә — Аллаһы тәгаләгә; уягъ — уяу.)

Моннан соң Сөләйман Бакыргани Гайсә пәйгамбәрнең ничек туганлагы хакында хәбәрләр бирә, атасыз «җилдән тугмыш» дип бара, Аллаһы тәгалә кодрәте белән яралуы хакында икенче тапкыр искә төшереп тормый, аның кирамәтләре һәм могҗизалары турында бәян итүгә күчә. Ул күзсезләрне күзле иткән, аксакны йөрткән, саннарын төгәл иткән, үлекләрне терелткән. Моннан соң поэмада сюжетлы вакыйгалар башланып китә һәм Гайсә пәйгамбәр әнисе Мәрьям анага гыйбадәт вакыты ирешүен белдереп болай ди:

Гайсә әйтер: «И ана,
Бер пәнд әйтәем сиңа,
Ул пәндемне син аңла,
Бер сүзем яд килдия:

Ана — угыл кубалым,
Кәлим тунын киялем,
Бу дөньчны куялым,
Тагать вакты булдия!»

(*Сүзлекчә:* Пәнд — үгет; яд килдия — искә килде, хәбәр ителде; кубалым — кузгалыйк; кәлим тунын — дәрвиш, суфи киемен; киялем — киик; куялым — куярга кирәк).

Мәрьям ана улының бу сүзе белән килешә, алар икесе бергә, дөнья мәшәкатьләрен ташлап, Лөбнан тавына киләләр, көндез ураза тотып, кичләрен йокламыйлар, барча кош-кортлар вә хайваннар аларга сәлам бирергә җыелалар. Ә беркөнне, ашау өчен Гайсә пәйгамбәр үлән тамырлары җыеп килергә киткәч, Мәрьям ана янына Газраил килә һәм аның җанын алмакчы була. Ана улын көтеп алырга вакыт бирүен үтенә:

«Углым килсен, күрәин,
Башын-күзен сылаин,
Бер бәхиллек кылаин,
Җаным алгай!» — тидия.

(*Сүзлекчә:* Сылаин — сыйпыйм.)

Әмма Газраил фәрештә Аллаһы тәгаләдән андый фәрман юклыгын белдерә һәм Мәрьям ананың җанын ала. Гайсә пәйгамбәр кайта, анасын әле һаман йоклый дип белә, әхшам намазы, ясигъ намазы вакытлары үтеп китә, шуннан улы елый башлый, аны торарга өнди:

«Анам!» — дәю иңрәер,
«Купкыл!» — дәю ялварыр,
«Тәкый нәчә оерсән,
Таң намазы булдия!?»

(*Сүзлекчә:* Дәю — дип; иңрәер — иңрәр, аһ орыр; тәкый — тагын.)

Анасы тормый, Гайсә пәйгамбәр гаҗизләнә. Шунда күктән өн килеп, аңа Мәрьям ананың үлемен хәбәр итә. Гайсә пәйгамбәр моңа бик нык тәэсирләнә, һушы китеп егыла, барча галәм һәм фәрештәләр елаша башлыйлар.

Гайсә пәйгамбәрне Аллаһы тәгалә иленә кире кайтырга өнди, алардан кәфенлек алып килергә куша. Әмма халык аны сихерче һәм бозучы буларак белә икән. Бер нәрсә дә бирмиләр. Гайсә өметсез кайта. Әмма җәннәттән хурлар төшеп, җеназаны олылап ләхеткә куялар. Улы һаман елый. Әнисен күрергә теләвен әйтә. Шунда Хак тәгалә әмере белән кабер ярыла һәм Мәрьям ана терелеп чыга да аны ачулана.

Әйтер: «Нәчек мондаг сән,
Нәчек сабыр кылмаз сән?
Җан ачыгын белмәз сән!» —
Җавап мондаг бирдия.

(*Сүзлекчә:* Мондаг — мондый; кылмаз — кылмас; ачыгын — ачысын; белмәз — белмәс).

Шушының белән Мәрьям ана ике тапкыр җан алынуның никадәр авыр буласын белдерә һәм улының аны моңа мәҗбүр итүенә ачына, дөнья малына кызыкмаска чакыра. Шуның белән поэма бетә, автор бу рәвешле йомгак ясый:

Гариф япан гизәр тик,
Нәкъкаш туны бизәр тик,
Данә-энҗе тезәр тик
Кол Сөләйман ирдия.

(*Сүзлекчә:* Гариф — дин галиме, акыл иясе; япан — басу-кыр; нәкъкаш туны — суфи чапаны; данә-энҗе — ак энҗе).

Шул рәвешле автор үзенең суфи булуын, дөньяны ташлавын, шигырь сөйләп йөрүен, аларны ак энҗе кебек тезүен һәм үзенең Кол Сөләйман, ягъни Сөләйман Бакыргани булуын, бу поэманы язуын сөйләп уза.

«Мәрьям апа» китабы изгелек хакында, ана белән баланың мөнәсәбәтенә багышланган әсәр. Сөләйман Бакыргани Гайсә пәйгамбәрнең кичерешләре аша баланың анадан аерылу хәсрәтен оста итеп сурәтләп һәм, шул ук вакытта, ананың бала өчен хәтта кабердән кубарылып, баласының күз яшенә түзеп тора алмаслыгын ачып бирә. Эчтәлекнең үтемле булуы өчен пәйгамбәрне һәм пәйгамбәр анасын сайлый һәм хәтта алар кебек кешелек алдында идеал затларның да гадәти хисләр эчендә көйгәнлекләрен белдерә. Автор аларны Ислам динендә итеп күрсәтә. Алар мөселманча намаз укыйлар, шәригать кушканча ураза тоталар.

«Мәрьям ана» әсәре *«мәдид бәхре»* белән язылган, ягъни «фәгыйләтүн-фәгыйләт» үлчәмендә, һәр мисрагы җиде буыннан торган көйле хикәят буларак такмаклап әйтү өчен бик уңай эшләнелгән. Бу рәвешле язылуы аның үтемлелеген дә арттырган. Вакыйгалар тиз алмашынып бара. Шунысы бәхәссез, «Мәрьям ана» әсәре борынгы төрки әдәбиятыбызның иң гүзәл үрнәкләреннән берсе булып тора, аның һәрьяклап тарихи әһәмияте зур.

«Ахыр заман, яки Тәкый гаҗәп» китабы. Сөләйман Бакыргани алдагы әсәренең исемен үзе аерып күрсәтмәгән шикелле, бу поэмасына да нинди исем биргәнен белдерергә кирәк тапмаган. Халык телендә бу китапны «Ахыр заман» дип тә, «Тәкый гаҗәп» дип тә атап йөртәләр. Басма нөсхәләре «Ахыр заман, яки Тәкый гаҗәп» дигән ике төрле исем белән дә чыгарылган.

«Ахыр заман» әсәре борынгы мәктәп-мәдрәсәләрдә укытылган төп әдәби — дидактик китапларның берсе булып тора. Аның кульязма нөсхәләре шактый еш очрый. Беренче тапкыр Казанда 1847 елда Университет нәшриятында дөнья күргән. Күләме 16 биттә булып, кул яссылыгы зурлыктагы китап. Поэма, 56 куплеттан тора. Мисраглар *«һәзәҗ бәхре»* белән, ягъни «мөфагыйлүн-мөфагыйлүн- мөфагыйлүн» үлчәме белән төзелгәннәр, беренче өч юл үзара рифмалашып, соңгы дүр-

тенче мисраг исә *«андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар»* дигән сүзләр белән тәмамлана һәм Әхмәт Яссәви хикмәтләрен үлчәмдә дә, телдә дә шактый нык хәтерләтәләр.

Әсәр Аллаһы тәгаләнең җиргә каршы күкне, айга каршы кояшны яратуын һәм күп төрле пәгамбәрләр китерүен хәбәр итүдән башланып һәм боларның гаҗәеп эшләр булуын белдерү белән вакыйгалар алга таба үстерелеп китә. Икенче куплетта ук автор заман ахыры мәсьәләләрен кузгата һәм халыкның бозылуын, җир йөзенә һәртөрле бәла-каза тулуын, мәсҗедләрнең буш калуын, хәрам эшнең өстен күрелүен берәм-берәм сурәтли-сурәтли, Ахирәт көне, гарасат мәйданы, сират күпере кебек мәсьәләләргә тукталып, Мөхәммәт пәйгамбәрнең, сөнниләр мәзһәбендә кабул ителгән фәлсәфәдәгечә, мөселманнарны авыр газаплардан коткарачагы вакыйгаларын бәян итеп әсәрен төгәлли. Ахыр заман ирешү билгеләрен Сөләйман Бакыргани сөйләп килә һәм Ахыр заманның үзе хакында бәян итүгә күчә:

Дәҗҗал мәлгунь чыкубән Румга баргай,
Сиксән меңе җәһүд-тәрсә җәмигъ булгай,
Мәһди чыкты тию аңа хәбәр булгай,
Андин артик тәкый гаҗәп таңнары вар.

(*Сүзлекчә:* Дәҗҗал мәлгунь — ахыр заман ирешкәч, дини хәбәрләр буенча, җир йөзенә Дәҗҗал туар, ул арты белән ишәккә атланып, халыкны аздырып килер, ахмаклар аңа иярерләр; чыкубән — чыгып; Румга — Антолия, Рум дип Сөләйман Бакыргани чорында Сәлҗүк төрекләре илен атаганнар; җәһүд-тәрсә — җәһүди-христиан; җәмигъ булгай — җыелыр; Мәһди — дини хәбәрләргә караганда, Дәҗҗалга каршы килүче пәйгамбәр, иң соңгы булып киләчәк рәсүл, халыкны туры юлга кайтарачак; тию — дип; таңнары вар — таң-гаҗәеп эшләре бар.)

Сөйләйман Бакыргани Румга юнәлгән Дәҗҗалны Хорасанга да барган итеп күрсәтә, бәдбәхетләр аның килүе өчен сөенәләр. Мөселманнар Мәһди тирәсенә тупланалар. Мәһди исә һәртөрле бозыклыкка, Дәҗҗалның үзенә каршы сугыша башлый, кояш тотыла, Мөхәммәд пәйгамбәрнең каберенә йөзен сөртә. Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр, гүрендә хәлендә, Гайсә пәйгамбәрне күктән дәшеп китерә. Шулай итеп, Мәһди белән Гайсә пәйгамбәрләр Дәҗҗалга каршы сугышып, аны җиңәләр, үтерәләр. Бу вакыйгалар «тәмам төгәл тукыз йөз»нче ел-

да булалар. Шуннан соң җир йөзенә бар нәрсәне кортып килүче Йәҗүз (һәм Мәэҗүз) хаклы чыга:

Тукыз йөз дә унбишендә Йәҗүз чыкгай,
Гайсә берлән Мәһди варып, Турга ашкай,
Ул кяферләр бу дөньяга тәмам тулгай,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

(*Сүзлекчә:* Тукыз — тугыз; варып — барып; Турга ашкай — Муса пәйгамбәрнең Аллаһы тәгалә белән сөйләшкән Сур тавына ашулары хакында сүз бара.)

Сөләйман Бакыргани образлы сурәткә омтылмый, бәлки вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләп бара. Тәэсир көчен шушы гаҗәеп вакыйгаларның һичшиксез булачагы хакында укучының уйланулары тудыра. Коръәннең күтәрелүе, Сур өрелү, барча җаннарның үлеп бетүләре, шуннан соң гына Ахирәт көненең ирешеп, бәндәләрнең гарасатка сөрелүләре, рәхим-шәфкать өмет итүләре һәм башкалар языла. Хак тәгалә җәннәтне мөселманнарга бирә, кяферләр тәмугка сөреләләр. Автор Әбу-Җәһил белән Әбу-Ләһәпнең, Мөхәммәд пәйгамбәрнең дошманнарының, шушы көндә кан елап гафу үтенүләрен сурәтләп үтә, кяферләрнең дә Мөхәммәд пәйгамбәрдән яклау таләбендә булуларын яза.

Бу вакыйгалар барчасы да Коръәнгә һәм дини риваятьләргә таянып эшләнелгәннәр. Сөләйман Бакырган үзеннән «өстәми», бәлки дини хәбәрләргә карап вакыйгаларны үстерә, кяферләрнең хур булачакларын, өммәтләрнең сөенәчәкләрен язып үтә.

Менә шунда Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең әти-әнисе белән очраша. Ул алардан сабый чагында ук ятим калса да, аларны таный һәм очрашуга сөенә.

Габдулла да Әминәгә җитеп килгәй,
Мөхәммәднең алын тотып, йөзен үпкәй:
«Бәрәкаллаһ! Синдин һиммәт булыр», — тигәй,
Андан артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

Мөхәммәд анасыга тәгъзим кылгай,
Атасының муйнын кочып: «Атам!» — тигәй,
«Кечелектә ятим калдым сездин», — тигәй,
Андан артык тәкый гаҗәа таңнары вар.

(*Сүзлекчә:* Габдулла — Габдулла бине Габделмотталип, Мөхәммәд пәйгамбәрнең антсы, улына алты-җиде яшьләр булганда вафат; алын — кулын; һиммәт — ярдәм; тигәй — дияр; тәгъзим кылгай — хөрмәт күрсәтер.)

Шуннан соң Мөхәммөд пәйгамбәргә сират күперен кичеп җәннәткә керү өчен яшен тизлегендә йөрешле буракны китерәләр. Ул анда этиәнисен дә үзе белән алып, оҗмахка китә. Аларны җәннәт капкаларын ачып көтеп торалар, бөтен сарайлар һәм сигез оҗмах нурга чума. Шуның белән поэма тәмам була. Соңыннан автор бер куплетны үзе хакында сөйләүгә багышлый һәм болай дип белдерә:

Кол Сөләйман, тагать кылгыл, гафу кылгай,
Уганым лотфы берлә хөкем кылгай,
Ахирәт әсбабыны тизү виргәй,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

(*Сүзлекчә:* Тагать кылгыл — гыйбәдәт кыл; Уганым лотфы — Аллаһы тәгаләм яхшылыгы; тизү — тиздән; виргәй — бирер).

Бу әсәрнең Казан басмаларында тагын бер куплет урнаштырылган. Анда әсәрне яңадан басма өчен «Мескен Гали» имзалы берәүнең әзерләве хакында хәбәр бирелә. Аның XIX гасыр татар шагыйре Гали Чокрый икәнлегенә шик юк. Гали Чокрый «Ахыр заман» китабының авторы Сөләйман Бакыргани икәнен яхшы белгән, бу әсәрне бастырып таратуны яклап чыккан аның һәм аның тарихи әһәмияте барлыгын яхшы аңлаган әдип. Ул бу әсәр хакында «Замму назыйрә» дигән хезмәтен дә язып бастырган.

«Бакыргани китабы». Татарлар арасында кульязма рәвешендә күп таралган булып, беренче мәртәбә Казанда 1846 елда басылып чыккан. Башка халыклар арсында очрамый, шуның өчен дә чын мәгънәсендә Татар китабы исме белән йөртелә ала.

Аңа 144 шигъри әсәр теркәлгән. Хрестоматия буларак мәктәп — мәдрәсәләрдә дәрес бирү өчен файдаланылган. Сөләйман Бакырганиның үзен дә кертеп, санаганда, бу китапка 20 авторның әсәрләре урнаштырылган. XII — XVIII йөзләрдә яшәгән төрле шагыйрьләр булуларын искә алсак, «Бакыргани китабы» XVIII гасыр ахырларында төзелеп беткән булса кирәк дип нәтиҗә ясый алабыз. Һәрхәлдә аның моңа кадәр таралган кульязмалары әлегә табылмаган, анда Урта Азия һәм Казан шагыйрьләре урын алган: Сөләйман Бакыргани, Раҗи,

Мәшрәп, Мәһди, Әхмәт Яссәви, Шәмсетдин Гасый, Колшәриф, Ходадат, Иканый, Габиди, Шаһа Шоһуди (Лотфи), Гидаи, Газәли, Нәсими, Фәкыйри, Тафи, Касыйм шәех, Гариби, Кәрим Хөбби, Хатаи Сакыйн, Баба Мачин. Алар һәммәсе дә Яссәвия тарикате әдипләре, җаһриячеяссәвиче-бакыргани суфилары, ягъни догаларны-гыйбадәтләрне кычкырып укып (эчтән укып түгел) башкаручылар.

Китап Сөләйман Бакыргани хикмәте белән ачыла һәм монда, китапның өчтән бер өлешенә диярлек аның әсәрләре төрле урыннарда бирелгән. Шул сәбәпле аны Сөләйман Бакырганига бәйләп, «Бакыргани китабы» дип атап йөртеләләр.

Китапка Сөләйман Бакырганиның 25 хикмәте һәм өч поэмасы кертелгән. Хикмәтләре төрле үлчәмдә язылып, укытучы-остазы Әхмәт Яссәви әсәрләрен хәтерләтәләр.

Китапка кертелгән поэмаларыннан *«Ярты алма»* әсәре тарихи шәхес имам Газый Ногманга[1] багышлап язылган. Авторы күрсәтелмәсә дә, әсәрнең Сөләйман Бакырганига караганы аңлашыла.

Калган ике поэма пәйгамбәрләр тормышына атап язылган. Берсе — Ибраһим пәйгамбәр һәм аның улы Исмәгыйль турында, тетрәндерерлек итеп эшләнелгән. Мөгаен Сөләйман Бакырганиның улы Хөбби Хуҗаның үлеменнән соң язылгандыр. Шагыйрь улы белән аерылышуны бик авыр кичергән. Бу тойгылары «Хәким ата китабы»ында да сизелә.

Поэманың өченчесе Мөхәммәд пәйгамбәрнең мигъраҗы хакында, җиде кат күкләргә вә җиде кат җирләргә сәяхәте сурәтләнелә. Өч әсәр дә тидия, итдия, булдия кебек сүзләр белән буйдан буйга берегеп баралар. Өчесенең дә бәхәссез рәвештә Сөләйман Бакырганига караганын белдереп торалар.

Сөләйман Бакыргани үз стилен бик сирәк үзгәрткән һәм әсәрләрен шигъри итеп язган. Әмма ул дөньяга карата яңача фәлсәфи караш тудырмаган һәм «яссәвия» тарикатеннән читкә чыкмаган, күбрәк шигъри көчне үстерүгә әһәмият биргән. Әгәр дә Яссәвинең иҗатында дидактик ысул алга чыкса, Бакырганида образлылык үсеп киткән. Болар

---

[1] Ногман бине Сабит, бөек имамнарның дүртесеннән берсе. 702 елда Күфәдә туган, «Фәраиз» әсәре белән дан казанган. Багдад һәм Мисырда яшәгән. Аңа Имам Хәнифә исеме биргәннәр. Хәлиф Әбу-Җәгъфәр Мансур тарафыннан җәзалап үтертелгән.

бигрәк тә «Бакыргани китабы»на кертелгән әсәрләреннән сизелеп торалар. Әмма Сөләйман Бакыргани күпвакыт үзенең остазы күтәргән идеяләрне шигъри эшкәртү белән шөгыльләнгән, хәтта күп кенә темаларны да үзенчә «шомартырга» омтылган.

«Хәким ата китабы». Бу әсәр китап булып Казанда 1846 елда 23 бит күләмндә «Хикәяте Хәким ата» исеме белән басылып чыккан, аңа кадәр халык арасында кульязма хәлендә күчерелеп һәм укылып йөргән.

Әсәрдә Сөләйман Бакырганиның тормышы хакында язылган һәм автобиографик китап буларак карала ала. Күп урында дини риваятьләр белән беррәттән әкияти эчтәлектәге гаҗәеп хәлләр дә сурәтләнелә. Укучы өчен кызыклы вә гыйбрәтле итеп язылган, күңелләргә өн салырлык итеп эшләнелгән.

Бу китапта Сөләйман Бакырганиның тормыш юлы сөйләнелгәнлектән, вакыйгаларга тукталып тору кирәк табылмады. Аның теле авыр түгел, татарчага якын. Эчтәлеге кызыклы. Тарихи әһәмияте зур.

Йомгак: 1. Сөләйман Бакыргани — 1111-1186 елларда яшәп иҗат иткән, Яссы (Төркестан) шәһәре белән бәйле сәйрамда туган, Әхмәт Яссәвидән гыйлем алган, Әму-дәрья елгасы буендагы Бакырган шәһәрендә гомер кичергән суфи шагыйрь. Аның иҗаты безнең көннәрдә дә әһәмиятен югалтмаган.

2. Сөләйман Бакыргани — үгет-нәсихәтче дидактик шагыйрь, үзеннән соң шактый бай әдәби мирас калдырган әдип.

БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ТӨРКИ ӘДӘБИЯТ ҺӘМ МӘДӘНИ МӨХИТ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

IX-XIII йөзләрдә чәчәк аткан төрки төбәкләрнең берсе — Болгар дәүләте булып, ул Идел-Урал буйларында шактый олуг һәм бай мәмләкәт сыйфатында тарихларда дан вә шөһрәтен калдырган. Болгарлар 625-629 нче елларда ук Фәруһ хан заманнарында, Аллаһы тәгаләнең әмере һәм Мөхәммәд пәйгамбәнең фәтвәсе белән, сәхабәләренә ияреп, Ислам диненә кереп, 922 елда Алмуш хан чорында рәсми төстә сөнни мәзһәбен дә кабул иткәннәр.

Болгар халкы Ислам мәдәнияте белән Харәзм аша тыгыз бәйләнештә яши башлаган. Аларның икесе арасында даими сәүдә юлы булган һәм бу, кыпчак далалары аша үтеп, ике якның да алга таба үсешен тәэмин иткән. Болгар төркисе белән Харәзм телендә әллә ни аермалык булмыйча, асылда алар икесе дә бер әдәби тел мөхитендә яшәгәннәр һәм мәдәният, икътисад мәсьәләләрендә дә араларында каршылык күренмичә, ике ил дә охшашлыклары белән күз алдына киләләр. Бу ике мәмләкәт арасындагы икенче бер сәүдә юлы Иртыш-Кама буйларыннан, әйләнеч юл аша узган. Монысы күп очракта ышанычлырак булган.

Көнчыгыш Европада Болгар дәүләте алга киткән илләрнең берсе саналган. Монда беренчеләрдән булып корыч кою серләренә төшенгәннәр, һөнәрчелек, тәзелеш, сәүдә һәм гыйлем-фән болгарларда зур тизлек белән үскәнлеге тарихи бәяннәрдән ачык күренә. Гарәп сәяхәтчеләре дә бу хакта язып калдырганнар.

Унынчы гасырга кадәр Болгарда гарәп язмасына нигезләнгән төрки язма үсеш алып, борынгыдан файдаланып киленгән руник язу традицияләрен кысрыклап чыгарган. Болгар илендә мәктәп-мәдрәсәләр системасы ныклап урнашкан, дин галимнәре, муллалар җитешкән һәм алар, гарәп сәяхәтчеләренең хәбәрләренә караганда, шәригать һәм башка гыйлемдә яхшы хәбәдар һәм киң мәгълүматлы булулары белән аерылып торганнар.

1235 елда Болгарга килгән гарәп сәяхәтчесе Мөхәммәд Әбу-Габдулла бине Габдеррәхим бине Сөләйман-Гарнати Болгар тарихына кагылышлы хезмәтләре белән билгеле булган галим Ягъкуб бине Ногман

Әл-Болгари белән очрашкан һәм аның киң мәгълүматлы булуына соклангал. Ягъкуб бине Ногман Әл-Болгари үзе Болгарда казый хезмәтендә торган, остазы — Әбул-Мәгали Габделмәлик бине Габдулла Әл-Җөвайни икән. Ул 1163/64 елларда, Һиҗри ел исәбе белән 559 да вафат булып, Болгарда җирләнгән. Әмма язган тарихи хезмәтләре бүгенге көнгә кадәр яки килеп җитмәгән, йә булмаса әлегә фәнгә билгеле түгел, халык арасында йөри булса кирәк.

Болгарда риторика һәм дарулар хакында язган хезмәтләре белән танылган галимнәрдән Борһанетдин Ибраһим ибне Йосыф Әл-Болгари яшәгән.Ул үз заманында Сәмәркандинең «Әдәп» дип исемләнгән үгет-нәсыйхәт әсәренә шәрех-аңлатмалар язган, фәлсәфә белән шөгыльләнгән. 1204 елда вафат.

XI гасыр башларында Болгарда танылган галим Хуҗа Әхмәт Болгари яшәгән. Ул Солтан Мәхмүд бине Сөбүктәгин Газнәвинең (967–1030) шәкерте булып, «Әҗ-Җамигъ», «Әт-Тарика», «Әл-Фәваид» исемле әсәрләре белән Урта Азия һәм Көнчыгыш илләренә үзен таныткан, фәнни әдәбиятта аның исемен фәлсәфә галимнәре телгә алгалыйлар, аңа таянып фикерләрен белдергәлиләр.

Шундый танылган галимнәрдән икенче бер кеше — Хәмид бине Идрис Әл-Болгари, Болгарда казый хезмәтен үтәп, әле 1106 елларда исән булган, мәдрәсә тотып, шәкертләр тәрбияләгән. Идрис Болгари фәндә Сөләйман бине Дауд Әс-Суваринын остазы булып санала.

Шәех Сөләйман бине Дауд Әс-Сувари фарсы телендә «Бәһҗәтел-әнвар мин хакыйкатель-әсрар» («Хакыйкать серләренең нурлар яктылыгы») исемле җитмеш бүлектән торган китап язган. Дини мәсьәләләрне һәм суфичылык фәлсәфәсен алга таба сөреп, үгет-нәсихәт, мәгънә гыйлеме белән шөгельләнгән. Шулай ук гарәп телендә «Нүзһәтүл-колубүл-мәраз» («Авыру күңелләр сөенече») исемле китап язган. Соңыннан аны бераз үзгәртеп, «Зәһрәтүр-рийаз вә нүзһәтүл-колбүл-мәраз» («Бакча чәчәге, яки авыру күңелләр сөенече») исеме астында эшләгән.

Шәех Сөләйман Әс-Сувари һәр бүлек башында үзенең остазына атап мактау сүзләрен әйтә, аның дин галиме буларак өстенлеген һәм олуг фикер иясе, киң мәгълүматлы булуын тәкрарлый, мөдәррисе Идрис Болгари теленнән хәдисләрне сөйли.

Болгарда җитлеккән икенче бер галимнең исеме — Таҗетдин бине Юныс Әл-Болгари. Ул медицина буенча эшләгән һәм аның «Әт-Тир-

йакыл-кәбир» («Көчле дәвалар») исемле китабын бертуган Хәсән бине Юныс Әл-Болгари 1220 елда күчереп язып калдырган.

Бу фактлардан чыгып, Болгар төркиләре арасында фән вә гыйлемнең шактый үсеш алуы хакында азмы-күпме күз алдына китерергә мөмкинлек туа. Әмма тарих бик күп ядкәрләрне саклап кала алмаган, аларның шактые бүгенге көнгә килеп җитмәгән. Шулай да эзләнүләр, тикшеренүләр кирәк, ул вакытта җитәрлек кызыклы мәгълүматлар табылырга мөмкин.

Болгарда әдәбият та зур үсешкә ия булган. Халык китабы дәрәҗәсенә күтәрелгән «Бәдәвам»ны галимнәр болгар чорында язылган дип баралар. Әсәрнең эчтәлеге, теле, мәртәбәле галимнәрнең дәлилләре моның дөрес булуын раслап торалар. «Бәдәвам» поэмасы суфичылык юнәлешендә, бозыклыкка һәм мәҗүсилеккә каршы язылган, һәрдаим Аллаһы тәгаләгә таянырга өйрәткән әһәмиятле ядкәр.

Күп кенә галимнәрнең фикерләренә таянсак, Болгар чорыннан бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән мәртәбәле әсәрләренең берсе — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» («Йосыф кыйссасы», «Йосыф Зөләйха кыйссасы»). Бүгенге көндә милли горурлыгыбыз санала торган олуг мирасыбыз булып тора.

КОЛ ГАЛИ
(XIII гасыр)

Татар халкы гасырдан-гасырга укып-өйрәнеп килгән, мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек китабы итеп йөрткән «Кыйссаи-Йосыф» әсәре әдәбиятыбызның нигезләреннән берсен тәшкил итә. Аның авторы Кол Гали буларак кына билгеле, тулы исеме ничек булгандыр, анысы әсәрдә яктыртылмаган, әмма язма тарихи риваятьләр сакланып калган. Аларга 1960 еллар башында ук галим Х.Мөхәммәтов игътибар иткән. Ул Таҗетдин Ялчыголның (1763-1837) борынгы чыганакларга нигезләнеп 1805 елда төзегән «Тарихнамәи-Болгар» («Болгар тарихы») мөрәҗәгать иткән һәм Кол Галинең тормыш юлын ачыклый алган. Һәрхәлдә соңырак бүтән галимнәр бу биографияне инкарь итсәләр дә, Х.Мөхәммәтовның «Борынгы татар әдәбияты» (Казан, 1963) китабында тәфсилләп биргән табышын бәясез калдырырга тиеш түгелбез.

Кол Галинең тормышы. Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи-Болгар»да бәян иткән вакыйгаларны, Х.Мөхәммәтовка ияреп, эзлекле бер рәвешкә китереп карасак Кол Гали турында болар билгеле булыр: Болгарда Илһам хан исемендә бер хөкемдарның Габдулла исемле улы туа, атасыннан соң ул тәхеткә утыра, илле ел буенча ханлык итә, әмма сугышларның берсендә (Таҗетдин Ялчыгол аны Аксак Тимер белән сугышканда (XIV йөз ахырлары) дип белдерелә) Габдулла хан һәлак була. Габдулла ханның Галимбәк һәм Алтынбәк исемле ике улы булып, Галимбәк гомерен читтә, дәрвишлектә үткәрергә мәҗбүр ителә. Аннан Кашан шәһәрчегенә килеп, монда мәктәп-мәдрәсә тота. Анда улы Мирхаҗи туып, аны Хәзрәте Хаҗи кушаматы белән йөртә башлыйлар. Хаҗи утыз ел гомерен Кашанда уздырып, Зәй тамагына кайта. Монда аның улы Кол Гали туа. Әмма Хәзрәте Хаҗи Зәй тамагында озакка калмый, Харәзмгә китә һәм анда кырык биш ел буена мөдәррис булып, мәктәп-мәдрәсә тота. Кол Гали, шулай итеп, Харәзмдә үсә. 1219 елда Чыңгыз хан гаскәрләре караханиларның Җиде-су (Баласагун) төбәген басып алалар, төрки ханлыкларына сугыш куркынычы яный башлый. Монголлар Харәзмгә һөҗүм иткәч, Кол Гали күчмә төркиләр (кыргызлар) арасына китә һәм, качып, атасының йорты булган Зәй тамагына кайта, йөз дә ун яшенә кадәр яши. Аның Миргали исемле улы Үргәнечтә мөдәррислек итеп, шунда вафат була.

«Борынгы татар әдәбияты»нда Х.Мөхәммәтов тагын да шундый мәгълүматлар китерә: «Кол Гали Ибне Хаҗибның остазы булгач, ул аңардан олы булырга тиеш. Ягъни 1174 еллардан алда Кышанда[1] яки Бараҗ ханның резеденциясе булган башка бер шәһәрдә туган һәм үзенең башлангыч белемен шул тирәләрдә алган була. Соңыннан ул, Харизм шәһәрләренең берсенә барып, анда укып, чама белән алганда, 1176 елларда үзенең белемен төгәлләп, шундагы мәдрәсәдә укытырга калган. Кол Гали Харизмдә кырык биш ел (чама белән күрсәткәндә 1176-1220 елларга туры килә) мөдәррис була. 1220 елда монгол ханнарының, феодалларның армиясе Харәзмне яулап алган вакытларда, Кол Гали Үргәнечкә качкан. Ә 1221 елларда яулап алучылар Үргәнеч шә-

---

[1] Безнеңчә “Кашан” булырга тиеш, чөнки борынгы язмаларда, имла кагыйдәсе буенча, “Каф” хәрефеннән соң сүз башында “әлиф” язылмый, укылганда әйтелә. Бу Кашан дигән кала Казанның борынгы атамасы түгелме дигән сорау да туа. Ул, әлбәттә, кызыклы фараз гына. Әмма әһәмиятле. Чынлыкта рас килүе дә бик мөмкин.

һәренә килгән вакытларда Кол Гали, кыргыз далалары аша үтеп, Зәй тамагына, этисенең йортына кайта һәм шунда үлә... Кол Галине 1174 елда туып, 1221-1248 еллар арасында үлгән дип санарга мөмкин» (78 б.).

Риваятьләргә нигезләнгән эзләнүләр менә шушы нәтиҗәләргә китерә. Әмма монда исәп-хисап хаталары да шактый. Шунда ук сорау да туа, ул Кол Гали 1174 елда тугач, ике яшьлек вакытында, ягъни 1176 елда ничек мәдрәсәгә укырга китте икән? Шунлыктан соңгы вакытта галимнәр Кол Галинең тормыш юлы мәсьәләсен кузгатмаска тырышалар һәм аны әйләнеп узалар. Төрек галиме И.Х.Эртайлан фикерләренә ияреп, кырымтатар галимнәре Риза Фазыл һәм Сафтәр Нагаев «Къырымтатар эдебиятынынъ тарихы» (Симферополь, 2001) китабының 39-41 сәхифәләрендә Кол Галине кырымтатар шагыйре Хәлил угылы Гали (Халиль огълу Али) дип дәлиллиләр. Анда И.Х.Эртайлан эшләгән күчермәләр дә мисалга китерелә. Алар фәнни әһәмияткә ияләр. Мәсәлән:

Буны къошан заиф бенде аты Али
Йигирми дёрт ракъам ичре салды больди.
(*Ягъни:* Буны Кашан зәгыйфь бәндә аты Гали
Егерме дүрт ракам эчрә салды булды.)

(*Сүзлекчә:* Кашан зәгыйфь бәнде — Кашанның зәгыйфь бәндәсе; ракам — шигъридәге иҗек үлчәме.)

Бу шигъри юллар татар кульязмаларыныкыннан бераз аерылып тора. Шунысы тагын да әһәмиятле, монда “Кашан зәгыйфь бәнде” сүзләре белән Кол Гали үзенең Кашаннан икәнлеген әйткән түгелме? Шулай булса, ул вакытта Кол Гали тормышы белән бәйле тарихи риваятьнең әһәмияте бермә-бер артачак. Әгәр дә Истанбул кульязмасында чыннан да шундый аермалы үзенчәлекләр бар икән, әсәрне тикшерү юлында кызыклы гына ачышларга юлыгырга мөмкинлек туачак. Ә «Кыйссаи-Йосыф»ның Казан басмаларында исә “Кашан” урынына “дөзән” (төзегән) сүзен укыйбыз.

Татар галиме Х.Мөхәммәтов, «Кыйссаи-Йосыф» әсәрендә күрсәтелгән датадан чыгып, фәнни әдәбиятта поэманың язылган елын 1212 елның 26 декабре һәм 1233 елның 12 мае дип билгеләрә, 1212 нче елны әсәрнең төп язылу датасы буларак билгели. Бер иш кульязмалар беренче датаны расласа, икенчеләре 1233 елның дөрес дип белдерергә

мөмкинлек бирәләр. Боларның беренчесе хакыйкый булып, икенчесе исә күчереп алу, тарату датасын караган дип уйларга нигез бар. Һәрхәлдә «Кыйссаи-Йосыф» Болгар шагыйре Кол Гали тарафыннан 1212 елда Харәзмдә язылып бетеп, үз илендә соңрак таралган да булуы дөреслеккә туры килә сыман.

Традиция буларак, борынгы әсәрләр кайсы да булса ханга яки хөкемдарга атап язылалар. Ә «Кыйссаи-Йосыф»та андый атау өлеше юк. Болгар шагыйре Кол Гали сәяси карашлары нигезендә «Кыйссаи-Йосыф»ны һичкемгә һәм һичнинди ханга атамаган булса кирәк. Болгар ханнарына атаса, Харәзм ханнары кулына килеп керергә мөмкин, Харәзм ханнарына атаса, Болгарда нинди йөз белән күренер иде дә халыкта яклау һәм мәхәббәт казанмас иде дип тә уйларга була. Бу факт шулай ук әсәрнең 1212 елда язылып тәмам булуын хисси күзалларга ярдәм итә, димәк поэмада күрсәтелгән 609 елның рәҗәпнең 30 көне дөрес булып чыга:

Мәүләдән мәдәд-носрат йитезеннән,
Рәҗәп ай җәлали утызыннан,
Тарих чөн алты йөз тукызыннан
Бу зәгыйфь бу китабы дөзде имде.

(*Сүзлекчә:* Мәүләдән — Аллаһыдан; мәдәд-носрат — ярдәм; йитезеннән — җитешеп; чөн — чөнки; дөзде — төзеде).

Икенче юлдагы “җәлали” сүзе күңелдә шик уята, чөнки ул Ираннан Солтан Җәлалетдин Мәликшаһ заманында Төркиядә кабул ителгән һәм 471 ел Һиҗридән беренче ел дип башланып киткән, кояш белән бәйле календарь исеме. Әгәр дә дә шулай икән, ул вакытта Җәлали исәп белән бу дата гомумән дә XVII гасыр ахырына туры килер иде.

Кырымтатар һәм төрек галимнәре бу сүзне “хәлаби” дип укыганнар. Ул яңгырлы-карлы вакытны белдерә. Ә татар кулъязмаларында ул “җәлаби” дип язылган (“Борынгы татар әдәбияты” китабындагы фотокүчермәсеннән дә укырга мөмкин). Аның мәгънәсе Аллаһы тәгалә, әфәнде, ага сүзләренә туры килә. Ул “җәнабе” вариантына да туры килә. Шулай итеп, мәгънәсе “Рәҗәп аеның хөрмәтле утызынчы көне” булып чыга.

Кол Галинең тормышы хакында Т. Ялчыгол китергән хәбәрләрне юкка чыгара торган башка мәгълүматлар юк, шунлыктан ул риваятьләрне хакыйкатькә туры килә дияргә мәҗбүр булабыз.

Алтын Урданың дәүләтчелеген Аксак Тимер явы җимергән дәвердә, «Тәфтәри Чыңгызнамә»дән аңлашылганча, Кол Гали исемел бер шаһзадәнең башын чабып, катил иткәннәр икән. Бу факт белән таныш булган галимнәр икеләнү алдында калалар һәм Таҗетдин Ялчыгол китабындагы риваятьне юкка чыгарырга омтылалар. Әмма дә ләкин «Кыйссаи-Йосыф» әсәре бу очракта үзе ярдәмгә килә, поэманың 1212 елда язылган булуы сәбәпле, Кол Галинең дә XII йөз ахыры һәм XIII гасыр башы шагыйре икәнлеге дәлилләнә. «Дәфтәри Чыңгызнамә»дәге хәбәрнең исә, яки ялгыш, яисә башка бер кеше хакында барганлыгы аңлашыла.

«Кыйссаи-Йосыф» әсәрнең теле һәм әдәби үзенчәлекләре, галимнәр билегәвенчә, Харәзм-Болгар дәверенә карый, шагыйрьнең дә шул җирлектә тәрбияләнеп, шул әдәби-мәдәни мөхиттә иҗат иткәнлеген раслап тора. Шулай итеп, Кол Гали хакында теркәлгән Таҗетдин Ялчыголның риваяте, кайбер тарихи хаталарга да карамастан, дөрес булып чыга. Димәк, Кол Гали XII гасырның беренче яртысында, Болгар дәүләте ханнарының берсенең варисларыннан булып, Зәй тамагында дөньяга килгән, гомеренең зур өлешен Харәзмдә уку-укыту шөгыле белән уздырган, аннан соң яңадан Зәй тамагына кайтып, шунда вафат булган. Харәзмдә торган вакытында, ягъни 1212 елда «Кыйссаи-Йосыф» поэмасын тәмамлаган. Әсәр Идел буенда таралыш тапкан һәм яратылып укылган. 1233 елда автор аны кабат, берникадәр редакция белән, Болгар илендәге Кашанда күчереп чыккан. Шунлыктан тарихка бу әсәр ике дата белән кереп калган.

«Кыйссаи-Йосыф»тан тыш Кол Гали башка әсәр язганмы-юкмы, монысы әлегә билгеле түгел. Әйе, мәсәлән «Кисекбаш» поэмасында сүз болай башланып китә: «Башлагали сүзне «Бисмиллаһ» илә...» Беренче булып килгән «башлагали» сүзен галимнәр икегә бүлгәннәр, «башлыйк әле» дип аңлыйсы урынга, «башла, Гали» дигән тезмә итеп кабул иткәннәр һәм авторын да Гали исемле кеше булса кирәк дип тикшергәннәр. Моңа нигезләнеп, әлбәттә, «Кисекбаш» поэмасын Кол Гали язган икән дип нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек туа. Әмма болай фикерләү хата булыр иде. Поэманың бу урынында сүз Гали хакында бармый, бәлки авторның укучыга мөрәҗәгате буларак, фигыльнең үтенү формасы кулланылган, дөресе «башлыйк әле» икәнлеге аңлашылырга тиеш.

«Кыйссаи-Йосыф» әсәре. Поэмада кардәшлек мәсьәләсе һәм Зөләйханың Йосыфка карата булган мәхәббәте калку итеп сурәтләнелгән, башка вакыйгалар һәммәсе дә менә шушы ике төп идеяне ачып бирү өчен хезмәт итәләр һәм болар белән бәйле булган шактый күп сәбәпләрне белдерү рәвешендә файдаланылганнар.

Әсәр, Шәрык әдәбиятларына хас булганча, Аллаһы тәгаләне зурлау вә данлау, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламне олылау, сәхабәләрен һ.б. изгеләрне һәм фәрештәләрне хөрмәтләү хисләрен белдерү белән ачылып китә, шуннан соң гына автор, асыл вакыйгаларга күчеп, Йосыфның төш күрүен һәм әтисе Ягъкуп пәйгамбәрнең үгет-нәсыйхәтләрен сөйләп, вакыйгалар тезмәсен башлый. Монда кардәш-карендәшлек мәсьәләсе алгы планга чыгарыла, гүяки Кол Гали һаман да ваклана һәм бүлгәләнә барган төрки дөньясын күз алдында тотып иҗат итә, туганнарның үзара дошманлыгы яхшылыкка китермәячәген һәрдаим сиздереп бара.

Йосыф — гади кеше генә түгел, ул пәйгамбәр дә. Шунлыктан карендәшлекнең нәрсә икәнлеген яхшы аңлый һәм шушы тойгысыннан чыгып эш йөртә, абыйлары аңа начарлык эшләгәндә дә ул аларга нәфрәт белән карамый, үгет-нәсыйхәт белән аңлатырга тырыша, дошманлыкның ахмаклык булуын белдерә. Әмма туганнары — гади кешеләр, пәйгамбәр энеләренең сүзен төшенеп җиткермиләр, аның сүзеннән ялган һәм усаллык эзлиләр. Алар бу эшләре белән Йосыфны түгел, үзләрен түбәнлеккә төшерәләр. Әмма монда кан кардәшлеге генә түгел, дини карендәшлек мотивы да алга сөрелә һәм эчтәлек шуның белән шактый баеп китә.

Йосыф әйтер: «Кардәшләрем, өмидләрем,
Нишә бийлә кыладыңыз, олугларым?
Нишә бийлә идәресез, газизләрем?
Бән сезләре нә сөч кылдым?»-диер имди.

Йосыф шушы рәвешле агаларыннан миһербанлык үтенә. Әмма көнчелектән сукырайган абыйлары аның сүзләрен колакларына да элмиләр, аны үтерергә ниятлиләр. Бары тик Яһүдәнең генә миһербаны килеп, болай дип белдерә:

Яһүдә әйтте:»Бу вәгъдә рәва ирмәз,
Карендәш карендәшне һич үлтермәз,

Буны кылан, халаикъдин рәхмәт булмаз,
Ягрәк улдыр: тәүбә кылып дүнең имди».

(*Сүзлекчә:* Нишә бийлә — нигә болай; кылдадыңыз — кыласыз; идәресез-итәсез; бән — мин; сезләре — сезгә; нә сөч — нинди яманлык; рәва ирмәз — дөрескә килмәс; үлтермәз — үтермәс; кылан — кылып; хлаикъдин — халыктан; булмаз — булмас; ягрәк улдыр — яхшысы шул; дүнең — түнегез, кире кайтыгыз.)

Әмма Йосыфның агалары карендәшлекнең асыл мәгънәсен төшенеп җиткерә алмыйлар, хәтта алар этиләре Ягъкуп пәйгамбәргә нәрсә дип җавап бирәчәкләре хакында да уйламыйлар, бәлки үзләренең яман ниятләрен ахырына кадәр җиткерү турында гына уй йөртәләр, аны коега ташларга булалар.

Агаларының бу кадәр ахмаклыклары динсез булуларыннан килә, чөнки Шайтан коткысына бирелгәннәр, Аллаһы тәгаләне бар дип тә белмиләр.

Йосыф әйтте: «И кардәшләр, боны кылмаң,
Шайтан сүзнә гөмраһ улып, аңа оймаң,
Бәнем тәнем гөрйан кылып, туным суйман,
Ата хакын, кардәш миһрен саклаң имди!»

(*Сүзлекчә:* Боны кылмаң — моны кылмагыз; гөмраһ улып — ияреп; оймаң— буйсынмагыз, оемагыз; гөрйан кылып — ялангач итеп; туным суймаң — киемемне ертмагыз; миһрен — бәясен, хакын; саклаң— саклагыз).

Йосыфның агалары миһербансыз, ялганчы һәм ахмак булуларын әсәрдә һәрдаим раслап торалар. Вакыйгалар шул юнәлештә үстереләләр. Энеләрен коега ташлагач, аны Мисыр сәүдәгәрләреннән Малик бине Дугар коткара. Монда да вакыйгалар төш күрү белән бәйле була.

«Кыйссаи-Йосыф» китабы гомумән төшләргә бик бай һәм алар ярдәмендә автор Аллаһы тәгаләнең иркен һәм кешеләргә китергән язмышларның алдан ук билгеләнгән булуын күрсәтеп бара. Төшләренең тәгъбирләре, ягъни юраулары вакыйгалар барышында дөрескә чыга. Бу яктан «Кыйссай Йосыф» укучыларга көчле тәэсир ясаган һәм татар халкында, башта кулдан-кулга күчерелеп, аннан соң бастырылып, «Йосыф галәйһис-сәлам тәгъбир намәсе» киң таралыш тапкан һәм әһәмиятле төшләрне юрау китапларыннан берсе булып торган.

Йосыфның үзе күргән төше, Малик бине Дугарныкы, Зөләйханыкы, Мисыр мәлиге Канзафәрнең төшләре һ.б. шушы рәвешле илаһи хәбәр-

ләр әсәрнең эчтәлеген генә баетып калмыйлар, бәлки вакыйгаларны да кискен үзгәртеп җибәрәләр. Шулай итеп, төш күрү әдәби алымга әверелеп китә һәм әсәрнең үзенчәлекле якларыннан берсе булып тора.

Карендәшләре Йосыфны очсыз бәягә генә колыкка сатып җибәрәләр.

Әсәрдә алга таба карендәшлек мәсьәләсе тагын үз югарылыгында калкып чыга. Кинган иленә ачлык ирешкәч, Йосыфның агалары Мисырга килә. Йосыф бу вакытта олуг мәлик сыйфатында була. Әмма ул аларга яманлык белән җавап кайтармый, бәлки карендәшлек вә кардәшлек кануннарына туры китереп, яхшылык кына кыла, ярдәм кулын суза һәм үзләренә үк никадәр ахмак булуларын төшендерә. Йосыф каршында «унбер йолдыз» булган агалары һәм «тулган ай» булган Ягъкуп пәйгамбәр сәҗдә итәләр, бәни-исраил халкы, хәбәрләрдән күренгәнчә, Мисыр иленә күченәләр һәм шунда яшәп калалар.

Поэмада кардәш-карендәшлек мәсьәләсе шушы рәвешле чишелеш таба һәм аның ярдәмендә туганлык вә бергәлек идеясе калку итеп алга чыгарыла. Йосыфның гадел хөкемдар булып җитлегүе, һәрдаим үзенең сафлыгын һәм өстенлеген саклавы — болар шулай ук Кол Галинең күтәргән фикерләреннән әһәмиятлеләре, әмма алар Йосыфның пәйгамбәрлеген билгели торган сыйфатлар буларак кына чагылыш тапмаганнар, әсәрнең төп эчтәлеге утопик җәмгыять төзү фәлсәфәсен ачыклауга багышланган. Бу яктан ул Йосыф Баласагунлы юлыннан да бара, бердәмлек идеалларын да алга чыгарырга омтыла. Моның сәбәбе ул вакытта төрки халыкларның таркаулыгын бетерергә омтылыш белән генә аңлатыла ала, Чыңгыз яулары алдыннан бу эчтәлектәге әсәрнең тууы тарихи яктан да әһәмиятле.

Сюжетның икенче сызыгы Зөләйханың Йосыфка мәхәббәтен сурәтләүгә багышланган.

Йосыф һәрьяктан өстен. Ул чибәр дә, акыллы да, көчле рух иясе дә. Авырлыклар алдында каушап калмый, ялганлый белми, хак сүзле, миһербанлы, сәүче-пәйгамбәр. Бу яктан аның белән һичкем тиңләшә алмый. Шунлыктан аның кол булуы да күңелдә авыр эз калдырмый. «Пәйгамбәрләр тарихы»ның бәяннәреннән күренгәнчә, ул дөньяда иң чибәр кеше булган.

Мондый бер риваять бар: Аллаһы тәгалә гүзәллекне яраткан. Аны ун өлеш (яки йөз өлеш) Адәм пәйгамбәргә тапшырган. Тагын да ун өлешнең (яки йөз өлешнең) тугызын Хәувага биргән, калган бер өле-

шен ун кисәккә бүлеп, тугызын Йосыф пәйгамбәргә атаган, бер өлешен исә, меңгә кисәкләп, җир йөзенә чәчкән, үз гүзәллеген һәркем эзләп тапсын өчен. Шулай итеп Йосыф, Адәм белән Хәувадан кала, җирдә яшәгән кешеләрнең иң гүзәле һәм сокландыргычы буларак яратылган.

Зөләйха да чибәр кыз, әмма анда мондый гүзәллек юк. Кол Гали моны бик сиздермәскә тырыша һәм аерым басым ясап та үтми. Әмма Зөләйха тыелгысыз хис белән Йосыфка гашыйк, ул моны белдерергә тели, мәхәббәтен аңлатып карый, төрле хәйләләр кора, тик барыбер күңелен яулап ала алмый. Йосыф җитәрлек кадәр намуслы, үз кешелек дәрәҗәсен югалтмый.

Йосыф никадәр генә Зөләйхадан өстен булмасын, әмма мәхәббәт өлкәсендә ул аннан калыша. Аның атап кына яраткан, гашыйк булган бер генә кешесе дә юк. Атасы Ягъкуп пәйгамбәргә карата йөрәгендә йөрткән изге хисләре дә, агаларына багышланган миһербанлыгы да — болар барсы да мәхәббәтән түгел, бәлки пәйгамбәрләргә хас сыйфат, карендәшлек хисләре, кардәш-карендәшне олылау, бар нәрсәдән өстен күрү билгесе генә. Кайсы гына пәйгамбәрнең тормышын искә төшерсәк тә, бер әйбер билгеле, алар үзләренең йөрәкләрен Аллаһы тәгаләгә багышлаганнар. Йосыф та алар рәтеннән. Шунлыктан Кол Гали дә Йосыфны шушы яктан сурәтли.

Ә Зөләйхада, киресенчә, мәхәббәт аның йөрәгендә дөрләп чәчәк ата, ул шуның белән Йосыфтан өстен чыга да.

Мәхәббәттә Зөләйха тугрылыклы, Мисыр падишаһына кияүгә барып та, аның төштә күренгән зат түгеллеген белгәч, үзе урынына кияү ятагына колын яткыра, үзенең гиффәтен саклап кала. Чөнки ул бары тик йөрәге кушкан кешегә, мәхәббәтенә генә тиң була ала, максатын да бары шуңа гына юнәлдерә.

Зөләйха гүзәллек ягыннан Йосыфтан калышса да, башкалардан өстен. Кол Гали аның чибәрлеген алдан ук белдереп куя:

Колак дотып дыңлаңыз ошбу сүзи:
Ул Зөләйха мәликзадә, Таймус кызы,
Тулган ай тик балкыр ирде аның йөзи —
Оҗмах эчрә хурыл-гаян биңзәр имди.

(*Сүзлекчә:* Дотып — тотып; дыңлаңыз — тыңлагыз; мәликзадә — мәлик баласы; хурыл-гаян биңзәр —хури кызына тиңләшерлек).

Ни генә булмасын, Зөләйханың мәхәббәте аркасында Йосыфка лаеклы күрелә, алар кавышалар. Мәхәббәтенә тугырылыклы булганлыгы сәбәпле Аллаһы тәгалә Зөләйхага икенче яшьлек бүләк итә, бер-берсенә тиң күреләләр. Моның белән мәхәббәтнең бар нәрсәдән өстен булуы раслана. Иң чибәр зат та мәхәббәттән гүзәлрәк була алмый.

Йомгак: 1. Кол Гали XII йөз ахыры һәм XIII гасыр башында Болгар җирендә Кашанда һәм Харәзмдә яшәгән олуг шагыйрь, ул борынгы татар әдипләренең берсе булып тора.

2. Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» поэмасы бердәмлек, ягъни кардәш-карендәшлек темасына язылган һәм мәхәббәтнең өстенлеген сурәтләгән үлемсез әсәр.

УГЫЗ-КЫПЧАК ДӘВЕРЕНӘ ЙОМГАК

X-XII гасырларда төрки халыклар, аерым дәүләтләргә бүлгәләнеп яшәүләренә карамастан, әдәбиятны уртак юнәлештә үстерә алуга ирешкәннәр, гомуми төрки әдәби тел ныгып, мәдәни күтәрелешне тәэмин иткән. X-XII гасырларда Баласагун, Төркестан (Яссы), Харәзм өлкәләре төркиләрнең фән һәм әдәбият үзәкләренә әверелгән, Бохара, Сәмәрканд, Болгар җирләрендә дә шушы ук хәлне ачык күз алдына китерә алабыз. XII йөзнең икенче яртысыннан XIII гасырның беренче чирегенә кадәр төркиләрдә шигърият һәм суфичылык фәлсәфәсенең киңәеп үсеш алуын аерым билгеләп үтми мөмкин түгел.

XI гасыр шагыйре Йосыф Баласагунлыны дәүләт төзелеше, гадел җәмгыять тудыру мәсьәләләре борчыган һәм ул аларга фәлсәфи чишелеш тапкан булса, аннан соңрак елларда яшәпр иҗат иткән Әхмәт Йөгнәкине тәрбияви-дидактик, дини мотивлар үзенә җәлеп иткән, XII гасырның икече яртысында иҗатлары күтәрелеш тапкан Әхмәт Яссәви һәм аның шәкерте Сөләйман Бакырганины суфичылык фәлсәфәсе вә шәхес иреге проблемалары мавыктырган. Болар барсы да төрки халыкларда X-XII йөзләр эчедә кискен үсеш һәм үзгәрешләр барганлыгы хакында сөйлиләр. Безгә ул тарихның бик күп катлаулы яклары әлегә билгеле дә түгел, әмма дә әдәби фикерләүнең үсеш юнәлешләрен тикшереп карап, тарихи аң күтәрелешендә кыпчакларның тарихи роле зур булганлагы тарихи фактлардан аңлашылып тора.

Идел, Урал, Себер төбәкләренең күп кенә әдәби-мәдәни ядкәрләре бүгенге көнгә кадәр килеп җитмәгән, әмма монда бигрәк тә гыйльми-

фәлсәфи фикерләү алга китканлеген билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» поэмасы әлбәттә буш җирлектә барлыкка килмәгән, моның өчен төбәкнең әдәби традицияләргә бай булуы кирәк иде. Болгар төркиләрнең Харәзм белән мәдәни берлектә торуы, уртак әдәби телне саклау омтылышлары, дин уртаклыгы, сәүдә вә икътисади бәйләнешләре — болар барысы да әдәбиятны үстерүгә мөмкинлекләр тудырган. Кол Гали дә Әхмәт Яссәвинең укучыларыннан берсе булырга мөмкин.

Угыз-кыпчак дәвере дип шушы чорны бүлеп атау әлбәттә шартлы рәвештә генә ясалды. Әмма моңа аерым җирлек тә бар. Угызлар һәм кыпчаклар хакында сүз барганда Хәзәр диңгезеннән (Каспийдан) алып Байкалга кадәр булган җирләрдә тормыш кичерүче төрки кавемнәр күздә тотыла.

XIII гасырның беренче чирегеннән кискен тарихи үзгәрешләр угыз-кыпчак традицияләрен күпчелек төрки төбәкләрдә үстерү өчен яңа шартлар тудырганнар.

АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕ
ОЕШУҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Алтын Урда дәүләте тарих китапларында да төрле исемнәр белән аталып йөртелә: «Җүҗи улусы», «Кыпчак йорты», «Дәште кыпчак» дип. Урыс елъязмаларында һәм тарихларында аны «Золотая Орда» («Алтын Урда») дип исемлиләр, шуннан алып, татар тарихчылары да язган гыйльми хезмәтләрнең күбесендә ул шушы исеме белән аталып киленә.

Алтын Урда империясенең халкы милли сотавта төрле булганлыктан, ханлыкларга бүлгәләнеп идарә ителгән дәүләтләр дә яки ханның исеменә бәйле атама белән, яки башкалага нисбәттә аталганнар, мәсәлән, Чыгтай дәүләте — Чыгтай ханга бәйле атама, Җүҗи улысы — Җүҗи ханга нисбәттә. Алтын Урданы, анда яшәүче халыкларның төрле булуларына карамастан, татар дәүләте дип беләбез.

1236 елда Идел буйлары, Урал һәм Себер тәмам монгол яулары астында кала һәм Бөек Болгар дәүләте аларга буйсындырыла. 1219 елда ук Җиде-Су монгол яулары тарафыннан таланган, монда яшәүче төркиләрдән Чыңгыз хан гаскәриләр туплый. Байкал, Алтай тирәләрнедәге күчмә тормыш белән гомер кичерүче төрки-татарлар, кыпчаклар инде гаскәр арасында шактый була. Яуның исеме монгол-татар дип аталу да шуның белән бәйле рәвештә икәнлеге мәгълүм.

Җиде-Су эчке ханлыгында яшәүче төркиләрнең атамасы да татар булуы мәгълүм. Әгәр дә Әхмәт Яссәвинең хикмәтләрендә, Сөләйман Бакырганиның әсәрләрендә татар исеме христиан-яһүдиләр белән «тәрсә-җәһүд-татар» дип күрсәтелгәнлеген дә искә алсак, татарлар хакында инде XII гасырда ук Ислам динен кабул иткән төркиләр яхшы мәгълүматлы булганнар. Алар мәҗүсиме, әллә инде Тәңре динендә иделәрме, моны әлегә тарихи хезмәтләр ачык хәбәр итмиләр. Шулай да Идел буена килгән монгол-татарларның идарәчел сотавының аерым өлеше нәсари мәзһәбендәге христианнар икәнлеге мәгълүм. Чыңгыз хан гаскәрләре басып алган тарафларның күпчелеге төрки дәүләтләр булып, иң беренче чиратта алар һәлак итледеләр, халкы исә моголлар тарафыннан һәм чит мәмләкәләр ягыннан, монгол яулары белән килгән татарларның төрки булганлыклары өчен татар дип аталдылар. Шулай итеп, татар атмасы Урта Азия, Көнбатыш себер, Кавказ, Идел-Урал буйларында яшәүче һәммә төркиләр өчен дә уртак исем булып

китте, Алтын Урдада исә Байкалдан алып Кара диңгезгә кадәр, Арал һәм Каспий (Хәзәр диңгезе, Кыпчак диңгезе) буйларыннан алып Пермь төбәгенәчә урыннарда гомер кичерүче төрки халыклар берләштерелде, Урта Азиядәге Чыгтай дәүләтендәге төркиләрнең татар исеме белән аталганы кебек, Алтын Урдадагы төркиләр дә монголлар һәм башка халыклар тарафыннан татар дип йөртелә башладылар. Идарә һәм тәхет Чыңгыз хан тораннары кулында булып, монголлар тарафыннан алып барылды, әмма җирле ханлыклар да татар иле, татар ханлыгы дип телләргә кереп калды. Монголлар төрки-татар арасында эреп югалдылар һәм Үзбәк хан (1300-1341) вакытында хәтта дәүләт эшләре дә төрки-татар телендә алып барыла башлады. Бу фактлар барысы да асылда монголларның төркиләрне җиңүен чагылдырмый иде. Шул рәвешле җиңүчеләр җиңелүчеләргә әверелде. Бу — тарих уены иде. Чыңгыз ханның басып алу сәясәте асылда таркау төрки дәүләтләрне һәм урыс кенәзләрен берләштерде, бу яктан гаҗәеп әһәмиятле тарихи роль уйнады.

Бату хан явыннан соң Идел буенда монголларга каршы халык күтәрелешләре әледән-әле булгалап тора. 1237 елның көзеннән башланып, 1238 елның кышынача Басман җитәкчелегендә баш күтәрү һәм халык күтәрелеше Бату хан гаскәрләрен кирегә борырга мәҗбүр итә. Рәхимсез яу белән килеп, халык кузгалышын монгол гаскәрләре канга батыралар. 1238 елда Бохара һәм аның тирәсендә Мәхмүд Тәраби җитәкчелегендә баш күтәрүләр була, аларны да монголлар буйсындыралар. Бу вакыйгаларның кабатлануы аркасында Чыңгыз хан тораннары һәм монгол ханнары халыкка ташламалар ясарга мәҗбүр булалар. Алар бигрәк тә кабилә башлыкларына, аксакалларга, алпавытларга сарай хезмәтенә керергә, үз якларына күчәргә юл ачарга кирәклеген аңлап эш йөртәләр.

Алтын Урда Бату хан тарафыннан 1243 елда тәртип телә, ныклы феодал иерархия төзелә һәм дәүләт белән идарә итәргә мөмкинлекләр ачыла. Болгар шәһәренең мәсҗидләре, биналары торгызыла. Тормыш җайга салына башлый. Җирле халыкка һөнәрчелек, иҗат мөмкинлекләре бирелә. Мәсҗид-мәдрәсәләрнең эшли башлавы илдә укымышлы кешеләрнең күбәюендә әһәмиятле ролен яңадан үти башлый. Болгар шәһәре Алтын Урда оешу чорында әүвәле пайтәхет булып тора, аннан соң да, сәяси һәм икътисади ролен югалтмый. Казанда (Кашанда) мәмләкәтнең хәзинәсен туплау пулатлары төзелә. Шәһәрнең исеме казна

белән бәйле Казан исеме белән йөртелә башлый. Конспирация максатыннан булырга кирәк, аны Болгарел-Җәдид (Яңа Болгар) дип тә атыйлар. Монда Алтын Урда акчалары басыла. Бу факт һөнәрчелекнең Казан төбәгендә алга киткәнлеген сөйли.

Төркиләрдә иҗади потенциал көчле булган. Шул сәбәпле Алтын Урда да әдәбият һәм фән электән килгән традицияләрне тогызу ярдәмендә үсешен дәвам итә. Әмма күпчелек укымышлылар үз торган җирләреннән кубарылып, читтә иҗат итәргә мәҗбүр булалар. Әдип, шагыйрь Мәхәммәд Гауфи — Бохара җиреннән, Бәдретдин Чачи — Ташкентлы шагыйрь, Кашкадарья ягыннан Зыя Нахшәби исемле шагыйрь һәм башка иҗат ияләре Урта Азиядән Һиндестанга күченеп китәләр. Идел-Урал буйларыннан шагыйрь һәм галимнәр Төркия һәм Мисыр якларына юл алганнар. Урта Азияле Кәмал Хөҗанди Иранның Әзербайҗан төркиләре арасына китә һәм Тәбриздә гомерен үткәрә, Насир Бохари да шул якларга юл ала.

Алтын Урда эчендә һәм төрки халыкларның әдәбиятларында бу чорда мистик юнәлеш тагын да ныграк үсеш ала. Шушы үзенчәлек фарсы һәм гарәп әдәбиятларында да күзәтелә. Бу исә дини тәгълиматның тагын да югарырак үсешенә мөмкинлекләр ача. Асылда Алтын Урда әдәбияты гарәп-фарсы шигърияттен үрнәк итеп ала, аларга назирә-компиляцияләр язу таралыш ала. Бу факт исә мәмләкәтнең тулы канлы Ислам мәдәнияте вәкиле булуга омтылышы белән генә аңлатыла ала. Димәк, бу чор илдә халыкны тәмам мөселманлаштыру дәвере дип тә атала ала.

БОРҺАНЕТДИН УЛЫ НАСРЕТДИН РАБГУЗЫЙ (XIII-XIV)

«Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр кыйссалары») исемле китабы белән төрки-татар әдәбиятында тирән эз калдырып киткән олуг әдип ул — Насретдин Рабгузый. Алтын Урда чоры әдәбиятының (фәнгә билгеле булганнары арасында) тәүге әдипләреннән дә санала.

Тормышы. Насретдин Рабгузый хакында тарихта җитәрлек мәгълүматлар сакланып калмаган. Аның Борһанетдин исемле укымышлы кешенең малае булуы, Харәзм вилаятендәге Рабаты-угыз дип аталган авылда туып үскәнлеге мәгълүм. Рабаты-Угыз (бу сүз Угыз йорты ди-

гән мәгънәгә ия) сүзен төркиләргә хас рәвештә кушып әйтү ярдәмендә кыскартып, Рабгуз исеме белән йөрткәннәр. Шуңа нигезләнеп, автор тәхәллүсен дә Рабгузый дип алган.

Насретдин Рабгузый XIII йөзнең 70 нче елларында (1270 нче елларда, бәлки бераз иртәрәктер дә әле) туган булырга кирәк. Ул үзенең данлыклы «Кыйссасел-әнбия» әсәрен 1310 елда (Һиҗри белән 710) Алтын Урдада тәмам иткән. Бу хакта әдип болай ди белдерә: «Бу китап төзегән, тәгать юлында түзгән, мәгъсийать япанын гизгән, аз азыклык, күп языклык Рабат казыйсы Борһанетдин угылы Насретдин». Болардан тагын да шул билгеле була: Насретдин Рабгузый казыйлык хезмәтен үтәгән һәм шул дәрәҗәгә нисбәттә Рабат казыйсы («Рабат-Угыз казыйсы») исемен йөрткән, Аллаһы тәгаләгә тез чүгеп, авырлык белән аз ризыкка риза булып, суфи-диндар рәвешендә яшәүне үзенә өлге санаган кеше икән.

Насретдин Рабгузый хакында башка төрле хәбәрләр вә риваятьләр сакланып калынмаган, әмма ул, казый булу белән бергә, яхшы шагыйрь һәм язучы да. Галимнәр аны XIV гасырның беренче чирегенә кадәр яшәгән дип баралар. Аның кайчан һәм ни сәбәпле үлеме дә, кайда җирләнгәнлеге дә фән өчен мәгълүм түгел.

Төрки-татар әдәбиятларында Насретдин Рабгузыйга кадәр кем дә булса берәр әдип «Пәйгамбәрләр тарихы» хакында махсус китап язганмы-юкмы, бу сорауга җавап бирүе авыр. Мәгәре, изгеләр, пәйгамбәрләр хакындагы «Нәсыйхәтес-салихин» («Изгеләр нәсыйхәте») исемле әсәрнең Болгар чорында Идел буенда язылганлыгын тәкърарлаучы галимнәр белән беррәттән, XYIII йөздә төзелгәнлеген белдерергә вә дәгъвәләргә омтылучылар да аз түгел. Әммадә ләкин «Кыйссасел-әнбия» китабының буш җирлектә генә барлыкка килмәгәнлеген аерым әйтеп үтәргә кирәк.

«Кыйссасел-әнбия» әсәре хакында. Казан татарлары аны шушы рәвештә укып һәм атап йөртәләр. Һәрхәлдә автор аны үзе «Кыйссаи-Рабгузый» дип атаган. Казанда ул китап булып, «Кыйссасел-әнбия», «Кыйссасел-әнбия Рабгузый» исемнәре белән 1859 елдан башлап туктаусыз бастырылып таратылган. Аның XY гасыр күчермәсе Лондонда Британия музеенда, XYI гасырга нисбәтлесе Санкт-Петербургтагы Көнчыгышны өйрәнү институтында сакланган. Шулай ук Казан, Ташкент китапханәләрендә аның кульъязмалары бар. Болар исә «Кыйсса-

сел-әнбия» әсәренең киң кулланылышта йөргәнлеге хакында сөйлиләр.

Насретдин Рабгузыйның китабы 84 хикәя һәм кыйссалардан тора, кайбер бүлекләрдә автор шигъри формаларны да оста куллана, Коръән аятьләренә таянып, сөйләнгән хәбәрләренең дөреслеген раслап бара. Шушы сәбәптән «Кыйссасел— әнбия» әдәби дә, фәнни дә. Дидактик әдәбиятның гүзәл җимеше булып тора. Аны өлге буларак төрле чорда төрле әдипләр файдаланганнар. Ул татар мәктәп-мәдрәсәләрендә башлангыч сыйныфларның төп укыту предметы саналган һәм мондагы хәбәрләр нигезендә шәкертләр имтихан биргәннәр.

Насретдин Рабгузый төрки әдәбиятында беренчеләрдән булып табигать темасына багышланган дөньяви эчтәлектәге газәл иҗат иткән шагыйрь буларак еш телгә алына. Аның бу газәле «Кыйссаи Йосыф галәйһич-сәлам» бүлегендә, Йосыф пәйгамбәрне агаларының сәйранга, ягъни җәйләүгә алып чыгу өчен әтиләре Ягъкуп галәйһис-сәламнән үтенгән сүзләреннән соң бирелгән. Йосыфның агалары яз көнен мактыйлар, рәхәтлекләре вә күңеллекләре хакында сөйлиләр, кызыктыралар һәм шушындый вакытта ничек өйдә ятырга мөмкин дип вәсвәсә кылалар. Йосыф аларга иярә, әтиләре каршы килә алмый.

Рабгузый газәлен «Бәһарийййәт» («Яз хакында касыйдә») дип атый. Ул моңардан гыйбәрәт:

Көн хамәлгә керде ирсә, килде галәм нәүрузы,
Кичте бәһмән зәмһәрир кыш, калмады кары-бозы.

Көн килә мең күрке артып, терелер үлмеш җиһан,
Таң пәзирләп нәкъшы берлә бизәнер бу йир йөзе.

Таң атарда түрт саридин иснәер бады саба,
Кийк йөрер киндик япар дик исләнер япан язы.

Тизлеге тигин ягырдин ойыгы яшел-кызыл,
Арасы бодак ябыргак тол чәчәкләр төп-төзе.

Авырласа егълап болытлар, гөл чыкар, багы-бөстан,
Тал егачларың салышыр, уйнаер бик-бай кызы.

Кершәне караңлеге кан якса таглар сурәте,
Тунлыгы тансык тагардин рум-хытай атлас хизы.

Лэлэ сыгракын эчэрдэ сайрап исрер сандугач,
Торна өн тартып үтэрдэ сикрэер баклан-кузы.

Күктэ уйнап каль салышыр кырыказ филтулыгач,
Йирдэ йөгреп җефте алышыр ас, тиен, кеш, кондызы.

Нэйшэкэрлэр мэнбэрендэ тутый кош мэҗлес тотар,
Комри, былбыл мукрый булып өн төзэр төн-көндезе.

Бу ягыз йир-күк мэнгизлек яшьнэер мэйдан булып,
Уграшыр ай тик чэчэклэр тигрэсендэ йолдызы.

Хури гайн оҗмах эчендэ биң салнып, тэхсин кылыр,
Яз үзэ мондаг газэл эйтте Насыйри Рабгузый.

(*Сүзлекчэ:* Хамэлгэ — Кучкар йолдызлыгына, март ае ахыры, апрель башына; нэүрузы — язы, яңа көне; бэhмэн зэмhэрир — январь hэм февральгэ туры килэ торган салкын; пэзирлэп — буйсындырып; нэкъшы берлэ — бизэге белэн; түрт саидин — дүрт ягыннан; иснэер бады саба — саба җиле исэ; кийк — киек; киндин япар-дик — каплан-гипар кебек; ислэнер япан язы — язгы болыннарны иснэп; тизлеге тигин ягырдин; ойыгы — тезлэре үлэн тиеп, аягы; бодак-ябыргак — ботак-яфрак; тол — ялгыз, үзе генэ; чыкар — чыгар; багы-бөстан — гөлбакча; егачларың — агачларың; салышыр — чалышыр, кочаклар; караңлеге — каралыгы; тегардин — тегелгэн; атлас хизы — үтэли күренүче атлас; сыгракын — суын, шэрабен; сандуач — сандугач; сикрэер — сикерер; кузы — бэрэн; каль — аваз; кырыказ филтулыгач — кыр казы, соры казлар; җефт — хатын; нэйшэкэрлэр мэнбэрендэ — шикэр камышлары арсында; мукрый — Коръэн укучы; ягыз — вакытта; мэнгизлек — акылдан шашып; уграшыр — уралыр; хури гайн — хур кызы; биң — иң, җилкэ; салнып — салынып; тэхсин кылыр — мактар, сөенер; үзэ — турында; мондаг — мондый.)

Бу юллар Насретдин Рабгузыйның көчле шагыйрь булганлыгын күрсэтэ. Безнең алдыбызда лирик сыйфатлары ачыла. Бу газэленнэн тыш та аерым шигырьлэр язган булса кирэк. Дөрес, «Кыйссасел-энбия»дэн тыш гайре китабы барлыгы фэнгэ мэгълүм түгел, эмма алга таба үсэ барган фэнни эзлэнүлэр табышка да китерергэ мөмкин hэм Рабгузыйның шигырьлэр мэҗмугасы булып, ул да табылуы бар. Һэрхэлдэ андый җыентыгы бардыр дигэн фикер күңелгэ килэ.

«Кыйссасел-энбия» китабы, бигрэк тэ Насретдин Рабгузый иҗаты төрле яктан кызыклы, тирэнрэк hэм киңрэк планда аларны өйрэнэсе, тикшеренүлэр үткэрэсе бар эле.

Нәтиҗә: 1. Борһанетдин улы Насретдин Рабгузый Алтын Урданың иң олуг әдип вә шагыйрьләреннән берсе. Ул XIII гасыр ахырларында Рабгуз (Рабатыугыз) авыл, яки шәһәрчектә туган, казыйлык хезмәтен тоткан, бер үк вакытта әдәби иҗат белән дә шөгыльләнгән.

2. Рабгузыйның 1311 елда тәмамлаган «Кыйссасел-әнбия» китабы Алтын Урда әдәбиятының әһәмиятле һәм мәртәбәле ядкарләреннән берсе булып тора. Ул борынгы төрки-татар әдәбиятының классик үрнәге санала.

КОТБ
(Котбетдин әр-Разый)

Алтын Урда шагыйрьләреннән берсе — Котб (фәнни китапларда аны Котби дип бирәләр). Аның ансыл исеме Котбетдин (“Дин терәге”). Шуңа да аны Котби дип атаучылар белән килешмибез һәм Котб диючеләр ягында торабыз.

Тормышы. Котбның тормышы, биографиясе фән өчен нигәдер мәгълүм түгел санала. Аның хакында кайбер хәбәрләрне аның үз әсәрләреннән дә таба алабыз.

Ул «Хөсрәү вә Ширин» дастанының авторы. Шигырь белән язылган бу мәхәббәт дастаны Алтын Урда ханнарыннан Үзбәк ханның улы Танибәккә аталган. Һәрхәлдә Танибәк Сарай тәхетенә утыра алмаган. Әмма ул шушында тәрбияләнеп үскән. Атасы ханлык иткә заманнарда (1313 — 1342) Идел буена күп кенә укымышлылар җыелган һәм Сарай шәһәре башка Көнчыгыш төбәкләре белән тыгыз бәйләнештә булган.

Котбның кемлеге хакында бер версия бар. Ул да булса Шәрыкта шул заманнарда тарихчы һәм фәлсәфә белгече буларак танылган Тәхтәни кушаматлы Котбетдин әр-Разыйга барып тоташа. Моңа карата Котб иҗаты буенча зур фәнни тикшеренүләр алып барган профессор Х.Й.Миңнегулов тәнкыйди караштa тора.

Котбетдин әр-Разый чыгышы белән Гыйракның Рай (Раз) бистәсеннән. Галим буларак танылганнан соң, 1336 елда ул Сарай шәһәренә килә. Алтын Урда ханнары Шәрык галимнәренә җитәрлек дәрәҗәдә игътибар күрсәткәннәр һәм аларны фән һәм әдәбият үсешендә файдаланганнар. Котбетдин әр-Разый да шаһзадәләрне тәрбия итүдә үзеннән зур өлеш керткән. Сарай шәһәрендә ул гыйльми хезмәтләр дә яза. Танибәк хан аның тәрбиясен күргән, аннан белем алган. Аңа үгет-нәсыйхәтләре белән ул дастан багышлаган.

Котбетдин әр-Разый Сарайда Үзбәк хан үлүенә кадәр (1342) яши. Олуг хан тәхетен варислары бүлешә башлыйлар. Танибәккә куркыныч яный. Ул гына да түгел, һәлакәт аның якыннарына да үлем китерергә мөмкин. Котбетдин Әр-Рази Якын Көнчыгышка китеп бара. Уку-укыту эшен ташламый. 1365 елда вафат була.

«Хөсрәү вә Ширин» дастанының каһарманы Хөсрәү белән Алтын Урдадан Танибәк арасында берникадәр язмыш охшашлыгын табарга була. Хөсрәү дә үзенең туганы Бәһрам Чубин белән тәхет өчен дошманлаша, Танибәк тә Җанибәк белән шушы ук яктан каршылыкта. Гүяки тарих яңадан кабатлана. Димәк, дастан юктан гына язылмаган һәм автор сюжетны шушы охшашлыкны күздә тотып сайлаган булып чыга.

Тагын да бер аналогиягә игътибар итик: ул да булса — Хөсрәүнең үтерелүе. Аны улы Шируя шымчылары урын өстендә йоклаган җирендә чәнчеп, канга батырып һәлак итәләр, Танибәк хан да Җанибәкнең җибәргән кешесе тарафыннан үтерекләә. Бу тарихи һәм әдәби вакыйгалардагы охшашлыклар күп нәрсәләр хакында сөйли. Болар, беренчедән, Котбетдин әр-Разыйның чыннан да Танибәк шаһзадәгә остаз икәнлеген раслый; икенчедән, Танибәк белән Җанибәк шаһзадәләр тәхет өчен шактый үзара тартышкан булсалар кирәк. Тарих үзе дә бу чыгармаларның дөреслеген раслап тора.

«Хөсрәү вә Ширин» әсәре. Бу дастан әзербайҗан халкының фарсы телле шагыйре Низами Ганҗәвинең (1141–1209) шушы ук исемдәге поэмасыннан ирекле тәрҗемә әсәре дип исәпләнелә. Низами аны фарсы телендә язган, шөһрәт казанган һәм халыклар арасында ул яхшы билгеле булган. Әмма Хөсрәү һәм Ширин вакыйгалары турындагы риваятьләр халкыбыз арасында электән киң таралыш алганлыгы да фәнгә яхшы мәгълүм.

Котбның «Хөсрәү вә Ширин» дастаны безнең көннәргә бердәнбер нөсхәдә килеп җиткән. Ул да Париждагы Милли китапханәдә сакланып калган. Бу нөсхә Котбның үз кулъязмасы түгел, бәлки 1383 елда Мисыр мәмләкәте Искәндәрия (Александрия) шәһәрендә Бәркә Фәкыйһ тарафыннан эшләнгән күчермәсе.

Котб дастаны 1342 елда тәмамланган. Бәркә Фәкыйһ исә 40-41 ел узганнан соң күчергән. Ни сәбәпле күчерүченең Танибәккә багышланган әсәргә тукталганлыгы мәгълүм түгел. Моны фараз итү юлы белән генә ачыкларга мөмкин: мәмлүкләр Мисырында Танибәк тарафдарла-

ры ул вакытларда идарәчел даирәләрнең төп составын тәшкил булсалар кирәк.

Бәркә Фәкыйһ үзен Алтынбога исемле аристократның укымышлы колы, «асылым кыпчак» дип күрсәтә. Алтынбога Мисырга Идел буеннан мөһим эшләр белән килгән, Бәркә Фәкыйһны да үзе белән алган, «Хөсрәү вә Ширин» дастанының күчермәсен эшләттергән. Бәркә үзе дә шагыйрь кеше булып, дастанның ахырына үз шигырьләрен урнаштырган.

Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре кулъязмада 280 сәхифәдән тора. Һәр биттә 42 шигъри юл. Дастан тулысы белән 90 бүлектән төзелгән. Эчтәлек ягыннан һәр бүлек Низами поэмасы белән туры килә. Төрки һәм Фарсы нөсхәләрен чагыштырып чыккан поляк галиме А.Зайончковскийның фикеренчә, ике телдәге бу ике әсәр эчтәлек ягыннан барберсенә тәңгәл киләләр, Котбның Низами әсәренә компиляция-нәзыйрә яркәмендә үз әсәрен тудырган. Аны галимнәр тәрҗемә әсәре дип түгел, бәлки оригиналь дастан буларак карыйлар.

Котыбның «Хөсрәү вә Ширин»е Аллаһы тәгаләне һәм аның пәйгамбәрләрен мактау һәм данлау белән башланып китә. Низами әсәренә килсәк, шундый башламнан соң ул Шаһ Мозаффаретдин Кызыл-Арсланга мәдхия укый, Котб исә бу урында Үзбәк ханының улы, Җанибәкнең абыйсы Танибәк шаһзадәгә һәм аның хатынына багышлау иҗат итә һәм болай дип белдерә:

Йөресен Мысрау-Шамда ярлыгыңыз!

(*Хәзергечә:* Мисыр һәм Шамда әмерегез йөрсен!)

Моңа нигезләнеп, Алтын Урда һәм Мисыр, Шам мәмләкәтләре арасында дустанә мөнәсәбәт барлыгын, Сарай ханнарының ярлыклары ул якларда да игътибарда торганлыгын күрсәтеп үтәргә кирәк.

Шунысын да искәртеп үтмичә мөмкин түгел, бу бүлекнең исеме дастанда «мәрхүмә»гә багышланган, димәк, ул вакытта, ягъни бу бүлек язылганда инде Танибәк ханның хатыны үтерелгән булган. Тарихи мәгълүматларга караганда, Танибәкнең хатыны үзе белән бергә һәлак ителә. Тикшерүче тел галиме Ә.Нәҗип бу бүлектәге «мәрхүмә» сүзен Бәркә Фәкыйһ өстәгәндер дип бара, чөнки Танибәк хан белән хатыны 1343 елда үтереләләр, ә дастан 1342 елда тәмам булган инде. Безнең карашка Котб үз әсәрен Танибәк үтерелгәннән соң гына төгәлләгән,

яки аерым төзәтүләр керткән. Юкса Хөсрәү белән Танибәк арасында аналогия уздыру урынсыз булыр иде, дастанның тарихи әһәмияте дә югалыр иде. Котбның хан үтерелгәч тә аңа тугыры калуы үзенең укучысы хакында ихластан ядкәр сакларга, исемен үлемсез итәргә омтылышыннан килгәнлеген аңлавы кыен түгел.

Җәмилә хан, мәлик ул, бәхете үрке,
Ак Урду дәүләте ул тәхет күрке.

(Сүзлекчә: Бәхет үрке — бәхет үре, биеклеге.)

Автор Ак Урда дәүләтен һәм аның ханы Танибәкне Алтын Урда, Сарай өчен бәхет урыны, тәхет күрке икәнлеген тәкрарлый бу шигъри юлларында. Моның белән Котбның «Хөсрәү вә Ширин» дастанын Танибәккә багышлау сәбәбе дә ачыла. Димәк, ул Танибәк ханны һәм Ак Урданы идеаллаштырган. Шагыйрь махсус рәвештә анда килгән, әмма күп җәбер-җәфалар күргән:

Морадым ирде, кем, бу капугда,
Килеп юл тапсаман тип бу тапугда,
Сәфәр ражен корып качы әййам,
Тапугка йитем имде уш сәрәнҗам.

(*Сүзлекчә:* Морадым ирде — максатым иде; капугда — бусагада, хан каршында; тапсаман — тапсам иде; тип — дип; тапугда — хезмәттә; сәфәр рәҗен — сәфәр авырлыгын; качы әййам — ничә көннәр; уш сәрәнҗам — ахырда.)

Әсәрнең эчтәлеге мәхәббәт темасына багышланган булса да, аның белән параллель рәвештә сәяси мәсьәләләр дә яктыртыла. Дастан Һормуз исемле падишаһның угыл теләве белән башланып китә һәм вакыйгалар үстерелеше шушы малайның тууы белән дәвам итәләр. Һормуз падишаһның угылы тугач, аңа Хөсрәү Пәрвиз исеме бирәләр.

Хөсрәү Пәрвиз бик тиз үсә: көчле, матур булып, шушы сыйфатлары белән һәркемдә соклану уята. Аның дөнья күргән, укымышлы акыл иясе Бозруг Өмид остаз тәрбияли. 14 яше тулганда Хөсрәү Пәрвиз акыллы бала булып җитлегә. Авторың тәрҗемәи хәле белән таныш булган укучы Хөсрәүнең остазы белән Котб арасында охшашлыкны таба ала.

Көннәрдән беркөнне Хөсрәү Пәрвиз иптәшләре белән ауга чыга, кәеф-сафа коралар һәм кичне бер авылда уздыралар. Икенче көнне Һормуз падишаһка хәбәр килеп ирешә: Хөсрәүнең иптәшләреннән берәү бер дәрвишнең бакчасында өлгермәгән йөзем җимешен өзгән, атлары белән бакчасын таптаганнар икән. Шаһ бу хәлгә бик ачулана һәм җәза бирә: Хөсрәүнең аты аягын кистерә, мәҗлес кирәк-яракларын өй хуҗасына бирдерә, кубызчының бармагын чаптыра. Бу хәлгә Хөсрәү бик кайгырып, атасы каршына гафу үтенеп килә, шаһ аны кичерә.

Төшендә Хөсрәү Пәрвиз Нәүширванны күрә. Ул аның бабасы икән. Яраткан дүрт нәрсәңне югалттың, шуның өчен сиңа дүрт сөенеч бирелер, ди: 1.) Ачы йөзем өчен татлы яр кочарсың, 2.) Аяклары чабылган атың урынына җилдән җитез Шәбдиз ат синеке булыр, 3.) Мәҗлесең таратылу өчен бай тәхет иясе дәрәҗәсенә ирешерсең, 4.) Бармаклары киселгән кубызчы урынына җан рәхәте бер җырчы табарсың.

Алга таба вакыйгалар шушы төшнең рас килүен дәлилли башлыйлар, Хөсрәү Пәрвизнең рәссам Шавыр исемле дусты бар икән. Бервакыт ул шаһзадәгә гаҗәеп кызыклы хикмәт сөйли: Куһистан җирендә Мөһинбану исемле бер падишаһ ханым булып, шаһлыгы көч вә куәт белән дан тоткан, аңа күп мәликләр буйсынып, алдында баш бөгәләр, ди, ә янында гүзәллек иясе бер кыз — карендәшенең кызы — Ширин бар икән. Бу кызның Шәбдиз исемле яхшы аты җилдән җитез дип белдерә.

Ни Ширин тик кеше күрде бу күзем,
Ни Шәбдиз яңлыг ат ишетте үзем, —

(*Сүзлекчә:* Яңлыг — төсле, кебек.)

дип әйтә Хөсрәүгә дусты Шавыр.

Егетнең төштә күргәннәре белән дусты Шавыр хикәяте арасында Хөсрәү охшашлык табып, йокысы кача, йөзе сула, күңелендә гашыйк уты кабына. Ширинне күреп, аның хакында мәгълүматларны тулырак китерү максаты белән Шавырны Куһистанга җибәрә.

Шавыр Куһистанда изге дәрвиш сыйфатында бер дәйргә туктала, бу монастырьда аңа бер монах-кәшиш Шәбдиз атның серле тууына бәйле урынны күрсәтә. Шавыр кызлар белән бергә йөрүче Шириннең дә кайсы аланга килеп ял иткәнлеген белеп ала. Хөсрәүнең рәсемен бер кәгазьгә ясый, агач төбенә куеп китә. Иртәгесен кызлар аланга килә, күңел ачалар, Хөсрәүнең сурәтенә очрыйлар. Сурәтне күрүгә, Ширин га-

шыйк була. Кызлар бу рәсемне җыртып ташлыйлар. Икенче көнне дә вакыйга кабатлана. Кызлар моны пәри эшенә санап, ял итә торган урыннарын үзгәртәләр. Юлда Ширин тагын Хөсрәүнең сурәтен күреп ала. Кызлар эшне сизенәләр, Шириннең гашыйк булганлыгын аңлыйлар. Аларга дәрвиш киемендә Шавыр очрый, сурәтнең серен чишә һәм кызга, Шәбдизгә атланыпауга чыккач, Хөсрәү янына качарга киңәш итә. Ширингә бер йөзек бирә, Хөсрәүнекен. Ул яши торган Мәдаин каласына барып җиткәч, шуны күрсәтеп, сарайга үтәрсең, ди. Ширин нәкъ шулай эшли дә, ауга чыккан җиреннән качып китә. Башкалар, Шәбдизнең тезгенен тота алмады, дип кайгыда калалар; Мөһин-бану апасы да бу хәлдән бик кайгыра һәм:

Төшемдә бу бәлане күрмеш идем,
Кем, илдин баглы кош ычкынмыш ирдем, —

(*Сүзлекчә:* Илдин — кулдан; баглы кош — бәйдәге кошны.)

ди.

Ширин 14 тәүлек буе килгәч, арып, юынырга туктала.

Бу вакытларда Хөсрәү Пәрвиз шаһлык идарәсендә катнаша башлый, хәтта үз исеменнән акча да суктырып тарата. Бу өлгерлеге атасында шик уята, Һормуз шаһ улы Хөсрәүне кулга алмакчы була. Бозруг Өмид Хөсрәүгә киңәш биреп, бәладән саклап кала. Хөсрәү, остазын тыңлап, Куһистанга китеп бара. Юлында исә суда юынучы Ширинне күреп кала, әмма алар бер-берсен танымыйлар, аралары ерагая барган саен гына аңлап алалар.

Ширин Мәдаингә килә, йөзекне күрсәтеп, Хөсрәүнең сараена үтә. Хөсрәү юк. Аның качып киткәнлеге беленә, Ширинне сихерче дип, һавасы начар булган тауларда сарай салдырып, шунда күчерәләр, аның газаплы тормышы башланып китә.

Хөсрәү исә Куһистанга килә. Мөһин-бану аны яхшы кабул итә, сыйхөрмәт күрсәтә. Шавырдан барсын да белешеп, аны Хөсрәү үз иленә кайтарып җибәрә, Шәбдиз нәселеннән булган Гөлген исемле ат белән ул Мәдаингә килеп ирешә һәм Шириннең нинди бәлаләргә дучар булуын күреп, аны кире Куһистанга озата.

Бу вакытта Хөсрәүнең әтисе вафат була, улы Куһистаннан тиз генә Мәдаингә кайтып, тәхеткә утыра, ике яр тагын бер-берсен күрә алмыйча калалар.

Хөсрәү гаделлек белән идарә итә башлый, әмма туганы Бәһрам Чубин аңа каршы коткы оештыра, ялган сүзләр тарата. Ике арадагы сугышта Хөсрәү җиңелә һәм кабат Куһистанга кача. Шунда Ширин белән очраша. Әмма Ширин намуслы кыз була, сабырсызлык күрсәткән Хөсрәүгә вакытыннан элек буйсынырга теләми. Моңа егет үпкәли һәм Шәбдизгә атланып, Рум иленә китеп бара. Рум падишаһы аны олылап каршы ала, христиан дине көчәйсен дигән ният белән кызы Мәрьямне аңа кияүгә бирә. Хөсрәү аннан зур гаскәр алып, Бәһрәм Чубинга каршы килә, җиңеп, тәхеткә кире кайтып утыра. Әмма Ширингә булган мәхәббәт хисеннән арына алмый.

Хөсрәүнең китүеннән соң Ширин кайгы-хәсрәт эчендә кала. Юатып карыйлар, күңеле тынычланмый. Ул арада Мөһин-бану да вафат булып, тәхеткә Ширин утыра. Гаделлек белән идарә итә, әмма ул да мәхәббәт утында яна. Хөсрәүнең Мәрьямгә өйләнүен бик авыр кичерә. Бер ел идарә иткәннән соң, тәхетен ташлап, хезмәтче кызлары белән бергә Мәдаиндәге тау сыртындагы сараена килеп, шунда яши башлый. Шавыр бу хәлләрне Хөсрәүгә сөйләп тора. Мәрьямнең сизенүеннән курыкса да, Хөсрәү һичшиксез Ширин белән очрашырга уйлый. Кыз аның бу ниятен кабул итми.

Шушы вакытлар эчендә әсәргә Фәрһад образы килеп керә. Ширин сөт эчәргә ярата. Әмма көтүлекләр ерак, шуның өчен дә ул шушы көтүлекләрдән сөт агып килсен дип хавыз-үткәргеч казытырга була. Бу хакта Шавырга сөйли, ул исә, үз чиратында, бу эшне Фәрһад исемле дусты башкарып чыгачагын хәбәр итә. Фәрһад белән Шавыр яшьлектә икесе бер остазның шәкерте булган икән. Шавыр каләм гыйлемен, Фәрһад кәйлә һөнәрен өйрәнгән. Олы гәүдәле, озын буйлы, чибәр егет була Фәрһад. Шириннең сараена килә, эшне башкара, бөтен осталыгын җигә, әмма Ширингә гыйшкы төшә:

Теле сүзне, иле эшне онытты,
Булып дивана, тик япанны тотты.

(*Сүзлекчә:* Иле — кулы; япанны — кыр-сахраны; тотты — йөрде.)

Кошлар, киек-җанварлар Фәрһаднең дустына әверелә, ул кешеләрдән читләшә, ялгызлыктан күңеленә ямь таба. Даны илләргә таралгач, Хөсрәү бу хәлгә ачулана, Фәрһаднең мәхәббәтен күп алтын-көмешкә сатып алмакчы була. Әмма егет малга карамый, Ширинннән башка аңа

һичкем кирәкми. Шушы рәвештә Фәрһад җавапсыз мәхәббәт символына әверелә. Ул арада артык кеше: Хөсрәүгә Ширин, Ширингә — Хөсрәү кирәк, ә Фәрһад — артык, әмма дә барысына караганда да күркәмрәк һәм лаеклырак итеп ярата белә.

Хөсрәү Фәрһадны байлык белән алдый алмаслыгын белгәч, хәйләгә бара, Бисутин тавын ярып чыгарга куша, әгәр дә моны эшләсә, Ширинне сиңа бирермен, ди. Үзе: «Таш кискәндә аның җаны чыгачак», — дип уйлый.

Фәрһад, Ширин белән Хөсрәүнең сурәтен кыяга уеп ясый да, аларның уртасыннан тауны ярып керә. Аның хакында халыкларга сүз тарала. Һәммә кеше аны карарга килә. Ширин дә монда бара. Фәрһад сөйгән ярын күреп, тагын дәртләнеп эшкә керешә. Кире кайтканда Шириннең аты сөртенә, Фәрһад аны аты белән бергә күтәреп ала да сараена китерә.

Менә тау егеткә буйсына, эше бетү алдында. Ширин дә аңа игътибарлы. Моңа Хөсрәүнең ачуы килә, ул тагын хәйләгә бара һәм бер кортка авызыннан Фәрһадкә: «Ширин үлде», — дигән ялган китертә. Бу хәбәрдән егет аптырашта кала һәм, миңа ансыз яшәү юк дип, кыядан ташланып, үзен үзе һәлак итә.

Ширин, бу хәбәрне ишеткәч, бик нык кайгыра. Җитмәсә егетнең үлемендә Хөсрәү аны гаепли. Әмма ул арада Мәрьям үлеп, Хөсрәү тизрәк Ширингә өйләнергә ниятли. Әмма кыз намуслы, шәригать таләбе буенча гыйддәт, ягъни хатын үлгәннән соң яңага өйләнүдән тыелып тору чорын кичмичә, кияүгә бармасын белдерә. Сабырсыз Хөсрәү аның бу җавабына ачу итеп, Исфаһаннан Шәкәр исемле бер гүзәлгә өйләнә. Әмма барыбер Ширинне оныта алмый, бервакыт, ауга чыккан җиреннән, исерек килеш аның сараена килә, әмма кыз аны эчкә үткәрми. Сарай каршына чатыр куйдырып, шунда кунак ясата. Әмма Хөсрәү ачуланып китеп бара.

Бу хәлдән соң Ширин күңелен тыя алмый, шаһның сараена үзе килә, Шавырны очратып, аңа эч серләрен сөйли. Шавыр аны бер чатырга яшерә, үзе, барып, Хөсрәүне уята. Шаһ аңа төшендә олуг бакчада чыраг (ут) тотып йөргәнлеген күрүен сөйли. Шавыр моны сөйгәне белән кавышуга юрый.

Икенче көнне мәҗлес җыела. Ширин барсын да чатыр эченнән карап тора. Барид белән Нәкиса исемле кубызчылар гыйшык көен уйныйлар. Кунаклар таралышкач, мәҗлестә Хөсрәү, шушы ике кубызчы,

чатыр эчендә Ширин генә калалар. Шунда газәл әйтешү китә. Барид — Хөсрәү, Нәкисә исә Ширин булып җыр башлыйлар. Бу хәлдә кыз түзеп тора алмый, яшеренгән җиреннән чыга, аны күреп, Хөсрәү таңгаҗәпкә кала.

Хөсрәү һаман да ашыга, Ширинне тизрәк үзенеке итмәкче була. Әмма Шавыр ярдәмгә килә һәм туйга кадәр түзеп торырга киңәш итә, алар имин генә аерылышалар.

Туй була. Хөсрәү сөенеченнән артыгын эчә, исерә. Ширин исә аңа алай булмаска үтенгән икән. Сабак өчен дип, беренче төннәрендә үзе урынына бер карчыкны яткыра.

Менә алар бергә тора башлыйлар, тормышлары көйләнеп китә. Алар янында Хөсрәүнең остазы— Бозруг Өмид. Ул һәрдаим шаһка киңәшләрен бирә. Падишаһлык гадел идарә ителә.

Әмма вакыйгалар тагын да куерып китәләр. Хөсрәү шаһ Ширингә өйләнгән вакытларда шаһзадә Шируя — Хөсрәүнең Мәрьямнән туган улы — үзенә Ширинне теләгән икән, менә хәзер атасы белән дошманлаша. Бу хакта Бозруг Өмид тә ишетә, шаһны тынычландырырга ашыга, олыгайгач төзәлер әле, ди. Тик аның юравы юш килми, көннәрнең берендә Хөсрәү шәһәрдән чыгуга, шуны гына көтеп торган шаһзадә Шируя тәхеткә менеп утыра, мәҗлесләр кордыра башлый. Ул гына да түгел, Хөсрәү белән Шириннең аякларына богаулар салдырып, аларны тоткын итә. Җитмәсә төнлә кеше җибәртеп, йоклап яткан әтисен үтертә. Ширин йокысыннан торып, бу хәлләрне күрә, кычкырып елый.

Ширин исә чарасыздан Шируяга кияүгә чыгарга ризалык бирә. Хөсрәүне зурлап күмәләр. Ширин матәмгә бизәнеп килә. Барсы да киткәч, Хөсрәүнең табуты янында үзен-үзе хәнҗәр белән кадап үтерә. Көннәр бозылып китә. Халык эшне сизенеп ала.

Вакыйгалар шуның белән тәмамлана.

Йомгак: 1. Котб — Алтын Урданың XIV гасырда яшәгән олуг шагыйрьләреннән берсе, аның чын исеме Гыйрак җирлегеннән килгән Котбетдин әр-Разый, Танибәк шаһзадәнең остазы; әмма бу раслауга каршы килүчеләрнең дә дәлилләре ышандырырлык дияргә була.

2. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» дастаны (шигъри романы) Алтын Урда вакыйгалары белән уртак яңгырашка ия булган, шунлыктан тарихи әһәмияте дә зур. Әсәрнең фольклор вариантлары халык арасында XIX йөз ахырынача сакланып килгәнлеге хакында да хәбәрләр бар.

ХАРӘЗМИ
(XIV йөз)

Алтын Урда әдәбиятының иң көчле вә әһәңле шагыйрьләреннән булган Харәзми күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп иткән, үз чорының данлыклы вәкиле буларак Сәйфи Сараиның «Гөлстан бит-төрки» аналогиясенә дә аның шигъри әсәре кертелгән.

Тормышы. Харәзми татар әдәбияты тарихында «Мәхәббәтнамә» әсәре белән лаеклы урынын алып тора.

Бу дәфтәр, кем, булыптыр Мисыр канде,
Йите йөз илле түрт эчрә төкәнде, —

дип белдерә автор әсәрнең ахырында.

Һиҗри ел исәбе белән бирелгән 754 ел хәзерге ел исәбе Милади хроникада 1353 елга туры килә. Моннан чыгып, «Мәхәббәтнамә» поэмасының 1342-1357 елларда Алтын Урдада ханлык иткән Үзбәк хан улы Җанибәк ханның чорында язылганлыгын белә алабыз.

Җанибәк ханлык иткән чорында Мәскәү кенәзлекләренә бик мәрхәмәтлек күрсәтә, аның бер хатыны урыстан була. Әмма тәхетне үзенә алу өчен туганнарын үтерүдән дә чирканмаган, вак җанлы зат ул.

1357 елда казый Мөхетдин Әл-Бәрдәгый исемле кеше Әзербайҗаннан Сарайга шикаять белән килә һәм үзләрендә мәлик булып торган, Сарайга буйсынган Малик Әшраф бине Тимерташ бине Чулпанны яманлый. Дәрбәнд һәм Ширван аша үтеп, Җанибәк гаскәрләрен Тәбризгә таба юнәлтә һәм Малик Әшрафның сугыш көчләре белән Миһрап елгасы буенда очраша, аларны тар-мар итеп, Малик Әшрафның башын чаптырып, байлыгын гаскәренә тарата. Бирдебәкне илле мең гаскәр белән Әзербайҗан идарәчесе итеп калдырып, Малик Әшрәфнең Тимерташ исемле улын һәм Солтанбәхет исемле кызын Сарайга алып кайтып китә. Күп кенә Тәбриз галимнәре вә шагыйрь-язучылары да Сарайга китерелә. Әмма Җанибәк бу сугыштан соң, кинәттән авырып, Сарайда үлә.

Җанибәк хан олуг галимнәрдән саналган Сәедшәриф ибне Габделхәмид тарафыннан тәрбия ителгән булган. Сарай шәһәрендә яшәгән бөек галим Сәгъдетдин Тафтазани «Шәрхе-Тәлхис» әсәрен Җанибәккә атап язган һәм аңа бүләк буларак тапшырган. Болардан чыгып, Җанибәк за-

манында Алтын Урда ханлыгында гыйлем вә мәгърифәтнең, әдәбиятның игътибар күзендә булганлыгын әйтә алабыз.

Харәзминең үз исеме һәм биографиясе әлегә тарих өчен мәгълүм түгел санала. Аның тәхәллүсеннән чыгып кына да Харәзм җирлегебелән бәйләнештә булганлыгын әйтә алабыз. Ул XIV гасырның башларында Харәзмдә туып үскән диярге мөмкин. Харәзм — Алтын Урданың мәдәни вә сәяси өлкәләреннән берсе булып, мәмләкәтнең үсешендә шактый көчле терәкләрдән саналган.

Харәзми күз алдыбызга суфи шагыйрь буларак килеп баса. Һәрхәлдә ул мәхәббәт хакында иҗат итсә дә, аның поэмасы Аллаһы тәгаләгә атап язылган.

Шагыйрь үз гомерен горбәтлектә, ягъни дәрвиш сыйфатында илдән-илгә йөреп яшәүдә үткәргән. Фарсы телендә язылган бер намәсендә Харәзми үзенең Шам мәмләкәтенә сәфәрен сурәтли. Ул аягына кәвеш тартып, кулына таяк тотып, күңелен сөендереп юлга чыга. Берәүләр аңа су бирсә, икенчеләр икмәк-ризыктан өлеш чыгаралар. Ул Хәзәр диңгезе (Каспий) аша көймәдә үтеп, Рум җирләренә, төркиләр арасына барып чыга, күп җәфалар күрә. Аннан Шам тарафына юнәлә, һәртөрле гыйбрәтләр белән күңелен ныгыта.

Болардан без Алтын Урда мәмләкәтендә гарәп илләренә сәяхәт юлының бу вакытларда үзгәргәнлеген белә алабыз. Идел-Урал халыклары элеккечә Харәзм аша Багдатка, аннан гарәп илләренә сәфәргә чыкмаганнар, бәлки әзербайҗан һәм Хәзәр диңгезе аша йөргәннәр икән. Бу сәфәр юлы Бәркә хан заманнарында ук урнашып калган булса кирәк. Чөнки Чыгтай дәүләте һәм Алтын Урда арасында дошманлык күренеп, үзара бәйләнеш вә юллар өзелгән.

Моннан соң Хәрәзми Урта Азия төркиләре арасына килеп чыга. Алтын Урда мәмләкәтенең Сырдәрья буйларына бара. Монда кече бәкләрдән булган, Җанибәк ханга буйсынган Мөхәммәтхуҗа бәк белән таныша һәм аның сараенда бераз вакыт яши һәм «Мәхәббәтнамә» поэмасын шунда иҗат итә.

Әсәрнең «Хатимател-китап» («Китапның ахыры») бүлегендә мондый юллар бар:

«Мәхәббәтнамә» сүзен монда йиттем,
Камугыны Сыр якасында беттем.

(*Сүзлекчә:* Йиттем — җиттем (*Әмир Нәҗип укылышында:* беттем — яздым); камуганы — барчасын; Сыр якасында — Сыр-дәрья буенда; беттем — яздым.)

Шулай итеп, әсәрнең язылган урынын да төгәл әйтә алабыз. Ул гына да түгел, поэманың «Бәяне вакыйганы әйтер» дигән бүлегендә «Мәхәббәт-намә»нең язылу сәбәбе белән дә танышырга мөмкин. «Әүвәл керешкәнен әйтер» бүлегеннән чыгып, бәйрәм айларының берсендә Мөхәммәтхуҗа бәк сараенда мәҗлес булганлыгын, кәеф-сафа эчендә өстәл корылганын беләбез һәм шунда бәк белән шагыйрь арасында барган сөйләшүгә тап булабыз:

Тәбәссем кылды, әйтте, и фәләни,
Китергел безгә лаек әрмәгани!

Күңел бәхрендә күп гәүһәрләрең бар,
Эчендә париси дәфтәрләрең бар.

Мәхәббәт нәрдене күпләрдин оттың
Шәкәр тик тел белә галәмне тоттың.

Теләрмен, кем, безнең тел берлә пәйда
Китабы әйләсәң бу кыш катымда.

Ки уш йил тик кичәр әййамы фани,
Җиһанда калса бездин әрмәгани.

Кабул кылдым, йир үптем, әйттем: “И шаһ,
Ишекең туарагы дәүләтле дәргәһ!”

Көчем йитмешчә күп хезмәт кылаен,
Җиһанда игү атыңны йәйәйен!

(*Сүзлекчә:* Тәбәссем кылды — елмайды; әрмәгани — бүләкне; бәхрендә — диңгездә, төбендә; париси — фарсыча; нәрдене — уенын; оттың — өстен чыгардың, җиңдең; шәкәр тик — татлы тел; белә — белән; китабы әйләсәң — язсаң, китап төзесәң; уш йил тик — ул җил кебек; әййамы фани — вакытлы дәвер, фани чор; йир — җир; ишекең — ишегең; тупрагы — туфрагы; дәргәһ — тупса, урын; игү — изге; йәйәйен — җәям, таратам.)

Шулай итеп, Харәзми үз вакытынында фарсы телендә яхшы шигырьләр иҗат иткән икән. Моннан чыгып без аның асылы фарсы телле шагыйрь булганлыгын беләбез. Аның язган әсәрләре арада мәгълүм булып, үзен мәхәббәт шагыйре сыйфатында белгәннәр. Ул барча ша-

гыйрьләрдән бу тематикада өстен саналган, шунлыктан Мөхәммәтхуҗа бәк Харәзминең мәҗлестә булуыннан сөенеп, аннан төрки теле белән китап язуын үтенгән. Харәзми үзе дә бу эшкә бик теләп тотынган, әмма башкарып чыгу аңа бик авыр булган.

Китабәт башладым, әнҗамә йиткәй,
«Мәхәббәтнамә» Мисыр вә Шамә йиткәй!

Бу хан үзрә салаи гаммә кылдым,
«Мәхәббәтнамә»не ун намә кылдым.

(*Сүзлекчә:* Китабәт башладым — яза башладым: әнҗамә — ахырына; йиткәй — җитәр; Шамә йиткәй — Шамгә таралыр; хан үзрә — хан белән, хан алдында; салаи — чакырылып; гаммә кылдым — сагыш йоттым, хәсрәткә төштем; намә — хат, бүлек.)

«Мәхәббәтнамә» әсәре. Әсәр шигъри тупланма формасында. Тел галиме Әмир Нәҗип аны *намә* жанрында язылган дип билгели. «Мәхәббәтнамә», традиция нигезендә, Аллаһы тәгаләне мактау вә олылау белән башланып китә, алга таба пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһис-сәлам һәм аның яраннары-сәхабәләргә дан җырлана, моннан соң Мөхәммәтхуҗа бәк телгә алына, мактала, лирик чигенеш ясалып, газәл бирелә, шуннан соң гына Харәзми намәнең язылу сәбәпләрен ачыклап, төп әсәр үзе башлана.

«Мәхәббәтнамә» әсәре аерым бүлекләргә, намәләргә бүленгән. Һәр намә ахырында автор берәр мәснәви, кайвакытта газәл, кыйтга, фәрд урнаштырган, шуның белән эчтәлекне тагын да баетып, кызыклырак итеп эшләгән. Яза башлаганда әсәре ун бүлектән торачагын белдерсә дә, әсәрен унбер намәдән соң тәмамлап, Харәзми аңлатусыз гына әйтеп куя:

Бу йиргә йитте сүз, тәгъйир булды,
Борын ун дидем, у унбер булды.

(*Сүзлекчә:* Тәгъйир — үзгәреш; борын — элек; у — ул.)

«Мәхәббәтнамә»нең сигезенче һәм унберенче намәләре фарсы телендә язылган. Өченче намәгә ияреп төрки газәл килсә, унберенченең ахырында фарсыча газәл урнаштырылган. Әсәрне Аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать итү, кыйтга, «Хатимәтел-китап» («Китапның ахыры») һәм

фарсы телендәге хикәят (намә) тәмамлый. Болардан соң шагыйрьнең үтенече урнаштырылып, поэма төгәлләнә. «Мәхәббәтнамә» әсәрнең ике кулъязмасы сакланып калган. Аларның берсе уйгур язуында, икенчесе исә гарәп графикасында. Уйгур язуындагы кулъязма 1431 елда (Һ.835) Яздә шәһәрендә, Мир Җәләлетдин исемле кешенең кушуы буенча, Бакый Мансур бахши тарафыннан күчерелгән, ягъни әсәр тәмам булганнан соң 78 ел үткәч эшләнелгән. Ул «Сиражел-колуб» («Күңелләрнең нуры»), «Мәсәл китабы», «Рәхәтел-колуб» («Күңелләр рәхәтлеге») һәм дә Лотфыйның дүрт газәле, Камәр-углы һәм Мансур бахшиләрнең берничә шигырьләре белән бергә теркәлгән. Бу кулъязма Британия музеенда саклана, 1957 елда Италиядә нәшер ителгән.

Гарәп язмасындагы кулъязма исә, шулай ук, уйгур язуындагысыннан соң 78 ел соңрак күчерелгән. Ул 1509 елларда (Һ.914) эшләнгән. Уйгур язмасында фарсы телендәге намәләр юк, әсәрнең композициясе дә бозылып бирелгән, бүлекләрнең исемнәре юк, бар җирдә дә «сүз башы дигән стандарт сүзләр куелган. Шулай уе төрки телдә язылган һәм әсәрнең язылу сәбәпләрен аңлаткан 53 бәете уйгур язмасында төшереләп калдырылган.

Гарәп графикасында эшләнелгән «Мәхәббәтнамә» нөсхәсе 473 бәеттән тора, аның 317 се төркичә, калган 156 сы фарсы телендә язылган.

«Мәхәббәтнамә» әсәре аерым сюжетка корылмаган. Аерым намәләрдән, ягъни хатлардан торуына игътибар итсәк, әсәр чыннан да бер гүзәл гашыйк җанашка атап язылган хатлар кебек тәэсир калдыралар, һәр намәдә Харәзми гүзәллекне мактый, намә адресланган затны күкләргә чөя, тиңдәшсез гүзәл итеп белдерә, йөзен дә, сүзен дә, буен да, чәчен дә — һәммәсен тиңдәшсез итеп сурәтләп бара. Әле ул аның йөз матурлыгыннан намә юлларын башлый, әле сүзеннән, әле буй вә кашыннан. Аларга ияреп, үзенең мәхәббәтен һәм хисләр ялкынында янганлыгын сөйли. Шагыйрьнең «шикәр кебек татлы теле» күңелләрне яулап ала, укучыда рухи көч вә дәрт уята.

Күңелнең каны кайнап, барча ташкай,
Күземнең яшедин Кәүсәр булашкай.

Кешенең синсезин ни җаны булсын,
Аның тик гомернең ни саны булсын?

Шәкәр ирне набәте Хозрә охшар,
Аягың кем ки үпсә, мәңге яшәр.

Җамалың тик юк кешенең җамалы,
Дарига, булмаса ирде зәвалы.

(*Сүзлекчә:* Ташкай — ташыр; булашкай — болганыр; набәте Хозрә — Хозер пәйгамбәрнең мәңгелек суы; җамалың — гүзәллеген; даригани кызганыч; ирде — иде; зәвалы — ахыры, соңгы.)

Харәзми гүзәллек һәм мәхәббәтне бәян иткәндә дини-мифологик образларны да, әдәбиятта танылган каһарманнарны да оста файдалана, алар аша тагын да киңрәк гомумиләштерүгә ирешә.

Уган Йосыф җамалын сезгә бирде,
Мәхәббәт кимиясен безгә бирде.

Сүзең Ширин, үзең Хөсрәүдин әфзун,
Булыр Ләйлә синең хөснеңгә Мәҗнүн.

(*Сүзлекчә:* Уган — Аллаһы тәгалә; кимиясен — ялганын, фәлсәфәсен; әфзун — өстен, артык; хөснеңгә — матурлыгыңа; Мәҗнүн — акылдан язган, дивана хәленә калган).

Харәзми гаҗәеп дәрәҗәдә зур шагыйрь булган, «Мәхәббәтнамә» әсәре моны дәлилләп тора. Һәм ул бу рәвешле белдереп һич тә ялгышмаган:

Синең гыйшкыңда Харәзми юкалды,
Вәләкин йир йөзендә аты калды.

Йомгак: 1. Харәзми — Алтын Урданың да мәхәббәт шагыйрьләреннән берсе булып тора. Ул XIV гасырда яшәгән һәм иҗат иткән, «Мәхәббәтнамә» исемле үлемсез әсәрен 1353 елда язган. Әлегә тулы биографиясе мәгълүм түгел. Төп чыгышы фарсылардан булуы бик мөмкин.

2. «Мәхәббәтнамә» аерым намә-хатлардан, газәл, мәснәви, кыйтга, фәрд, хикәят кебек жанрлардан төзелгән, 473 бәеттән торган төрки-татар һәм фарсы телендә язылган мәхәббәт әсәр.

ХИСАМ КӘТИП
(XIV йөз)

Хисам Кәтип исемен китаплаында галимнәр төрлечә язалар, әле Хөссам Кәтиб рәвешендә, әле Хисам Кәтип дип. Татарда Хисам исеме бирү гадәте бар, ул Хисаметдин формасында булса, “дин кылычы” дигән сүз булыр иде. Шушыннан чыгып кына да бу шагыйрьнең дә тулы аты Хисаметдин дип фараз кыла алабыз. Кәтип — “язучы, язу эшләре иясе” дигән сүз.

Хисам Кәтипнең тормышы. Аның кайда, нинди гаиләдә туганлыгы фәнебез өчен мәгълүм түгел. Ә менә эшләгән эше, язган поэмасы, гасырларны үтеп, безнең көнебезгә кадәр килеп җиткән.

Тарих, кем, йите йөз йитмеш иде,
Кем, Хисам Кәтип моны бетмеш иде, —

дип бер кулъязмада күрсәтелсә, икенчесендә, халык арасында киңрәк һәм күбрәк таралганында алар бераз үзгәртелеп бирелгәннәр:

Тарих йите йөз йитмеш йите иде,
Кем, Хисам Кәтип моны әйтмеш иде.

Бу — Хисам Кәтипнең сакланып калган бердәнбер әсәреннән, ягъни «Җөмҗемә сотан дастаны»ннан алынган сүзләр. Беренче күчермәдән чыгып, иң әүвәл, без шагыйрьнең XIV гасыр урталарында яшәп иҗат иткәнлеген белә алабыз. Һиҗри ел исәбе белән 770, Милади белән 1368/69 елларга туры килә, ә 777 ел исә Миладида 1375/76 еллар булуы хакында сөйли. Мондый ике төрле дата очраган вакытта фәндә аларның беренчесен әсәрнең башлап язылу чорын белдергән, икенчесен, соңрагын исә күчерү елы дип карыйлар. Бу принцип монда да дөрес нәтиҗәгә китерергә тиеш. Шунлыктан «Җөмҗемә солтан дастаны»н 770, ягъни 1368/69 елларда язылган дип белдерергә ныклы нигез бар.

Димәк, шагыйрь XIV йөз урталарында яшәп иҗат иткән; әмма аның ничә яшьтә икәнлеген әсәрдәге мәгълүматлардан чыгып билгеләү мөмкин түгел. Шулай да Хисам Кәтипнең 1340 еллар тирәсендә туганлыгы фараз кылып була.

Белгечләр «Җөмҗемә солтан дастаны»ның теле кыпчак булуын күрсәтәләр. Димәк, әсәр чыннан да Алтын Урда җирлегендә иҗат ителгән. Саклану даирәсенә килгәндә, ул Идел-Урал буйларындагы татарларда табылган һәм бүгенге көндә дә кульязма хәлендә галим археографларга очрап тора. Башка төрки төбәкләрдә күчермәләре бик сирәк, берәнсәрән генә очраштыргалый. Ә бу исә әсәрнең Казан татарлары арасында бик популяр булуы хакында сөйли һәм Хисам Кәтип Идел буенда туган вә яшәгән дип фараз кылырга юл ача.

«Җөмҗемә солтан дастаны» беренче тапкыр буларак 1881 елда Казан университетында бастырылган. Безнең көннәрдә исә кыскартылган рәвешендә 1963 елда «Борынгы татар әдәбияты» китабында һәм тулы килеш 1970 елда Казан университетында нәшер ителгән. Аның кульязмаларыннан берсе Кырым ханнарыннан Сахипгәрәй китапханәсендә саклану факты күп нәрсә хакында сөйли һәм идарәчел даирәләрнең аны кат-кат укуын күрсәтеп тора. Тагын да шунысы билгеле, Сахипгәрәй бу дастанны 1548/49 елларда Истанбулга җибәрү өчен госманлы телендә дә тәрҗемә иттерткән. Шулай итеп, «Җөмҗемә солтан дастаны» үз дәвере чикләреннән чыгып, халыкка хезмәт күрсәтүен һаман да дәвам иткән һәм сокландыргыч әдәби ядкәр буларак таралу даирәсен киңәйтә барган. Бу факт исә аның дөньяви, ягъни гомумкешелек өчен әһәмиятле булуы хакында сөйли. Үлемсез әсәрләр генә дәвер һәм дәүләт чикләрен үтеп чыгалар, яшәүләрен һаман да дәвам итәләр.

Дастанның авторына килгәндә, аның Хисам исемле булуына тукталып үткән идек инде. Ә менә Кәтип дигәне аның яки хан янындагы титулы, яки эш-шөгыле белән бәйле кушаматы булырга кирәк. Хисам Кәтип — суфи шагыйрь, ул үз иҗатында Әхмәт Яссәви һәм Сөләйман Бакыргани күтәргән идеяләрне алга таба үстергән, дини әдәбиятта таралган сюжетка корылган кешелек өчен кыйммәтле вә әһәмиятле булган фикерләрне күтәреп чыккан, Алтын Урда шөһрәт тоткан Чыңгыз хан тораннарыннан курыкмыйча: «Кани Чынгыз, кани Һүлагү — камуг?» — дип, Чыңгыз һәм Һүлагү ханнарның дәһшәтенә тәнкыйди рәвештә ишарә ясап узган. Җиһанда бар нәрсә вакытлыча гына, хәтта дөньяны яулап алучылар да, ди ул.

«Җөмҗемә солтан дастаны». Галимнәр бу әсәрне Италия шагыйре Алигъери Дентенең (1265-1321) «Илаһи комедия»се белән бер үк, уртак темага язылганнар дип баралар. Дөрес, болар икесе ике күләмдәге һәм дә икесе ике төрле иҗтимагый шарларда иҗат ителгәннәр. Бу як-

тан алар чагыштыргысыз. Әмма да идея-эчтәлек һәм тарихи әһәмиятләреннән чыгып караганда, әлбәттә алар бердәй, бер юнәлештә һәм, иң кызыгы, бер үк төрле нәтиҗәләргә килү өчен фикри этәргеч ясыйлар.

«Җөмҗемә солтан дастаны» фәнни әйләнештә шулай ук төрле-төрле исемнәр белән йортелә: «Җөмҗемә солтан», яки «Җөмҗемә Солтан», яки «Хикәяте Җөмҗемә солтан», яки «Дастаны Җөмҗемә», яисә «Җөмҗемә дастаны» рәвешләрендә. Безнең фикеребезчә ул, жанр үзенчәленген дә чагылдырган хәлдә, «Җөмҗемә солтан дастаны» исеме белән фәндә тотрыклы булып урнашырга тиеш. Һәрхәлдә әсәрдә автор үзе болай дип белдерә: «Җөмҗемә дастаны»н ишеткел сән»,— ди. Автор шигъри калып эчендә шулай язса да, аның теләгенә хилафлык китермичә, исемен тагын да яңгырашлы итеп, әсәрне «Җөҗемә солтан дастаны» дип билгеләү дөресрәк булыр.

Дастанның эчтәлегенә салынган сюжет, әйткәнебезчә, дини әдәбиятта, бигрәк тә хикәятләрдә еш очрый, суфичылар вә дәрвишләр аны үз фәлсәфәләрендә аңлатма сыйфатында телгә ала торган булганнар. Шагыйрьләрдән беренче булып бу сюжетка фарсы әдибе Фәридетдин Гаттар мөрәҗәгать иткән һәм «Җөмҗемнамә» поэмасын язган. Хисам Кәтип исә Гаттарның бу әсәре белән таныш булмаган һәм аннан файдаланмаган, бәлки чәчмә хикәятләрдән чыгып, үзе аерым дастан тудырган дияргә дә була. Әгәр дә Гаттар поэмасын белгән булса, традиция рәвешендә, сүз куәте өчен һичшиксез аны телгә алып китәр иде. Әмма бу чорда татар әдәбияты гарәп-фарсы әдәбиятларына иярү рәвешендә, нәзыйрәләр төзү юнәлешендә үскәнлектән, Ф.Гаттар поэмасына Хисам Кәтипнең нигезләнүен инкарь итеп булмый.

И, җиһан бакыйдыр, тигәннәр кани?
Ишетең дөнья эшен, белең ани:
Чөн бу галәм гакыйбәт юк булисәр,
Мондагылар һич бакый калмайисәр.

(*Сүзлекчә:* Бакыйдыр — мәңгелек; тигәннәр — диючеләр; кани— кая; ани — аны; чән — чөнки; гакыйбәт — ахырда, мәңгегә; юк булисәр — юк булучы; калмайисәр — калмаучы).

«Җөмҗемә солтан дастаны» шушы юллар белән башланып китә, шуннан соң Хисам Кәтип һәркемгә үлем киләчәген сөйли, аның пәгамбәрләргә дә, шаһларга да, баһадирларга да, каһарманнарга да килгән-

леген санап бара, моннан авторның теге яки бу тарихи шәхесләргә карата булган мөнәсәбәтләре дә сизелеп кала.

Һәрберсе бу җиһанны тоттылар,
Иллә, ишет, кем, соңында ниттеләр:
Киттеләр бер парә бүзгә чолганып,
Тәннәре үз каннарына болганып,
Монча төрлек мал вә нигъмәтен куеп,
Мөлкәте һәм тәхте, һәм бәхтен куеп.

Бу сүзләреннән соң Хисам Кәтип, хикмәтле сүз әйтү юнәлешендә, фикер йомгагы буларак, аңлатма рәвешендә нәтиҗә дә чыгарып куя:

Чөнки килдең дөньяга — китмәк кирәк,
Бар көчең йиткәнчә хәйр итмәк кирәк!

Ягъни, дөньяга кигәнсең икән, барыбер үләчәксең, шунлыктан үлем хакында да уйлап, дөньялыкта чагында башкалар өчен хәерле эшләр башкарырга тырыш, ди ул.

Дастанның башлангычы фәлсәфи эчтәлеккә ия. Автор бу җир йөзендә күп кешеләрнең сөякләре тузан булып ятар дип белдерә. Аларның кайсыларыдыр хан, әмир, солтан, бай, яки фәкыйрь хәлендә гомер сөргәндер:

Олуг, кечек, бай вә юксыл — билгесез.
Әмир, мескен, кол вә солтан — билгесез.

Әмма ахырда барысының да хәлләре бер үк сыйфатка килгән, һичберсе үлем тырнагыннан читтә калмаган.

Хисам Кәтип шушы фәлсәфәсеннән соң вакыйгаларны сөйләүгә кереп китә һәм моның үз сүзенә мисал буларак китерелгәнен белдереп куя: «Тыңла имде бу сүземгә бер мәсәл (мисал)», — ди ул.

Гайсә пәйгамбәр Шам җиреннән икенче бер илгә мөсафирлык кылып, сәфәргә чыга һәм бер сахрада гаҗәеп күркәм аланга очрый, монда саф сулар ага, кошлар оча-сайраша. Гайсә пәйгамбәр су буена утырып возу кыла, ягъни намаз уку алдыннан битен-кулын юа. Шул вакытта каршында бер сахра ташын күрә. Аның өстендә бер адәм башының сөяген тора:

Нә күзе калмыш, нә агзы-гәүдәсе,
Әгъзасында калмамыш һич нәрсәсе.

(*Сүзлекчә:* Нә — ни-нәрсә; калмыш — калган; агзы — авызы.)

Мәрьям ананың улы Гайсә пәйгамбәр бу тамашага аптырап карап тора һәм: «Күрмәдем мин йир йөзендә бонча баш», — дип белдерә. Ул гына да түгел, баш сөягенең алдында мондый гыйбарәләр дә язылган икән:

Бакты — язылмыш алтында ике хат;
«Кем, син, и баш, монча йөреп, монча ят!
Янә синдин моча эшләр кичисәр,
Соңра җаның кошы синдин очисар!»

(*Сүзлекчә:* Алтында — алдында; хат — язу; монча — бу рәвешле; кичисәр — узучы, кичәрләр; очисар — очучы, очар.)

Шушы язуны укыганнан соң Гайсә пәйгамбәр Аллаһы тәгаләдән бу баш сөяген яңадан дөньялыктагы хәленә китерүне үтенә, аның ниләр күргәнлеген үз авызыннан сөйләтергә тели. Дини әдәбияттан мәгълүм булганча, Гайсә пәйгамбәр үлекләрне терелтүче нәби сыйфатында мәшһүр саналган, шуның өчен дә суфи шагыйрьләр иҗатында ул иң беренче чиратта шул хәлендә күз алдына китерелә һәм аның образы терелтүче символикасы буларак файдаланыла.

Аллаһы тәгалә әмере белән Җәбраил фәрештә җиргә иңә һәм Гайсә пәйгамбәрнең үтенече кабул булганлыгы хакында хәбәр китерә. Бу баш сөягенең кемнеке икәнлеге белән бәйле сораулар алу башлана.

Андин ул баш Тәңре фәрманы белә,
Теле — теше юк икән, килде телә.

(*Сүзлекчә:* Андин — аннан соң; килде телә — телгә килде.)

Баш сәяге үзенең дөньялыкта күргәннәрен сөйли. Ул Җөмҗемә солтан исемле бер олуг мәлик булган икән, аның камил дәүләте, җәннәт белән тиңләшерлек яхшы сарае, арысланны буйсындырырлык кырык мең вәзире, унсигез мең мөхтәбәр бәкләре, ун мең җефете һ.б. күп санлы коллары аңа хезмәт иткәннәр, ул кәеф-сафа эчендә гомерен уздыр-

ган. Боларны сөйләтеп бетергәннән соң, Гайсә пәйгамбәр аның гүрдә күргән хәлләреннән хәбәрләр сорый, моңа каршы Җөмҗемә солтанның баш сөяге аһ ора, күзләренннән яшь чыгарып, сүзгә күчә. Тәхетендә утырган бу солтанның күзе бервакыт янындагы хатын-кыйрнакка төшә, ул аның белән кәеф-сафа кора башлаганда, яннарына бер фәкыйрь килеп, садака-хәер үтенә, әмма солтан аны куып чыгара. Ә бераздан күңеленә шик төшә.

Калды вәйран, ул күңелне япмадым,
Соңра күп эстәдем аны, тапмадым,—

дип аклана Җөмҗемә солтан.

Шушы хәлдән соң үзен сафландыру нияте белән солтан мунчага бара, өстенә бер тас су коя. Әмма башына бер шеш чыгып, төсе кача, бәлагә тара. Шуннан соң каты авырулары башланып китә. Вәзирләр авыруына дәва таба алмый гаҗиз булалар, Җөмҗемәнең хәле начарланганнан начарлана. Дөньялыктан алып китәргә аның янына Газраил ирешә.

Аны күрдем, кем, күземлә нагәһан:
Бер олуг сәхрә булмыштыр бу җиһан,
Чыкты бер сурәт, кем, алты йөзе бар,
Кан коелмыш таска биңзәр күзе бар,
Бере — астин, бере — өстин йөзләре,
Саг вә сулә, арткары һәм элгәре,
Мәшрикъ — мәгърип тотмыш ике канаты,
«Газраил» ирмеш Уган куйган аты,
Бер әлендә чәнгәл, берендә — кадәх,
Күрмәс ирмеш кичкән гомерендә фәрәх.

(*Сүзлекчә:* Күземлә — күз белән; нагәһан — көтмәгәндә; таска биңзар — тас кебек, таска охшаган; астин — астан; өстин — өстән; саг вә сулә — уң һәм сулда; арткары һәм элгәре — артында һәм алдында; Уган — Аллаһы тәгалә; әлендә — кулында; чәңгәл — сөңге; кадәх — шәраб савыты, рюмка; фәрәх — иркенлек).

Газраил фәрештә Җөмҗемә солтанның күкрәгендә сөңгесен китереп тери һәм аңа үлем шәрабен эчерә, бераз заманнан соң кабердә «терелә-чәген» белдерә. Вакыйгалар дәвамында укучы кабер газаплары хакындагы хәбәрләр белән очраша: башта гүр эченә Кирамән-кәтибин, ягъни

кешенең изге вә яман гадәтләрен язып баручы ике фәрештә кереп, кәфенен җыртып, кылган эшләрен яздырып алалар, төреп, муенына асып китәләр. Алардан соң Мөнкир белән Нәкир исемле газап фәрештәләре килеп, анан иманы хакында сорыйлар.

Сүзләмәдем ирсә, кагып тордылар,
Һәрберсе гөрзи берлә ордылар,—

дип аһ-зар итә Җөмҗемә солтан.

Моннан соң зобанилар ирешеп, аны тәмугның җиденче катына газапланыр өчен ташлыйлар, башта җәһәннәм шәрабен эчерәләр, солтанның җаннары көя, аннан кыйнап-сугып, тел очыннан тартып, сузып чыгаралар һәм муенына асып куялар. Җөҗҗөмә барча хәлләрне хәбәр итә, аннан соң, Гайсә пәйгамбәр үтенече белән, тәмуг хакында сөйли, җәһәннәм чоркырлары вакыйгаларына киңрәк тукталып үтә, мондагы хәрам ияләрен, халык арасында фетнә туыручыларны һ.б гөнаһлы кавемнәр хакында ачык аңлаешлы итеп сөйләп чыга. Сүзләрен тыңлаган Гайсә пәйгамбәр таңнар калып елый.

Җөмҗемәне бер чокырга ташлыйлар һәм анда утлы табутта утырталар. Моның эчендә ул өч солтан белән очраша, аларның ни өчен бу кадәр газаплар күрүен белешә. Үзен дә каты җәзалыйлар, шуннан соң гөнаһлары юылып, тәмуттан азат ителә.

Бу җиһандин кичмешен мең ел яшәп,
Янә түрт мең ел тәмуг, чиктем газап,
Имде йитмеш елдыр, кем, монда килеп,
Ошбу язида ятармын кортылып, —

(*Сүзлекчә:* Кичмешем — киттем; түрт — дүрт; йитмеш — җитмеш; ошбу язида — шушы далада; кортылып — корып-кибеп.)

дип белдерә солтанның баш сөяге Гайсә пәгамбәргә.

Җөмҗемә үзе Ильяс пәгамбәр чорларында яшәгән икән, әмма аның Тәңресенә, ягъни Аллаһы тәгаләгә ышанмаган, менә хәзер ул терелсә, ярлыкау сорап, Хак тәгаләдән гафу үтенер иде. Гайсә пәйгамбәр Аллаһы тәгаләдән Җөмҗемә солтанны кабат терелтүен үтенеп дога кыла, аның теләге кабул кылына һәм изге Гайсә үз юлы белән китеп бара. Ә солтан исә Кодсе иленә килеп, бер тау тишегендә, дәрвиш сыйфаты тотып, гыйбәдәткә егыла һәм яңадан да җитмеш ел гомерен Аллаһы

тәгаләдән дөньялыкта кылган языгы өчен гафу үтененеп үткәрә һәм мөэмин булып, ягъни иман кәлимәсе белән җаны чыга. Шушында вакыйгалар төгәлләнә һәм Хисам Кәтип үгет-нәсихәт белән әсәргә йомгак ясап куя:

Монча шаһлар, кем, җиһана килделәр,
Бәс, ишеттең, кем, анлар ни кылдылар,
Тапмас ирде кеше дөнядин морад,
Бәс калыр ирмеш җиһанда изге ад.

(Сүзлекчә: Монча — бу кадәр; җиһана — җиһанга; анлар — алар; бәс — шулай итеп; ад — исем).

Дастан авторның әсәрне язуы хакындагы мәгълүматлар бирүе белән тәмам була.

Йомгак: 1. Хисам Кәтип — 1368/69 елларда Алтын Урдада үлемсез «Җөмҗәмә солтан дастаны»н иҗат иткән шагыйрь. Аның тормыш юлы әлегә билгесез кала килә.

2. «Җөмҗөмә солтан дастаны» суфичылык идеяләренә корылган һәм кыпчак теле белән язылган, гуманистик идеалларны яктыртучы бөек әсәр. Ул фарсы шагыйре Ф.Гаттарның “Җөмҗөмнамә”сенә нәзыйрә булып санала.

СӘЙФ САРАИ
(1321–1396)

Сәйф Сараи урта гасырлар татар әдәбиятының иң мәртәбәле шагыйре һәм язучысы. Ул фарсы шагыйре Мөслахетдин Сәгъди Ширазиның «Гөлестан» китабын «Гөлестан бит-төрки» («Төркичә «Гөлестаны») исеме белән тәрҗемә иткән (фәндә аны назыйрә ысулы белән эшләнгән дип баралар), «Сөһәйл вә Гөлдерсен» һәм башка әсәрләрнең авторы. Галимнәр Сәйф Сараины турыдан-туры Идел буе, Сарай шәһәре белән бәйләнгән шәхес, диләр.

Сәйф Сараиның тормышын һәм иҗатын өйрәнү, бу хакта хезмәтләрен бастыруда, шагыйрьнең иҗат мирасын халыкка җиткерүдә профессор Х.Й. Миңнегулов төп һәм зур эшләр башкарды.

Тормышы. Сәйф сүзе гарәп теленнән «кылыч» мәгънәсендә тәрҗемә ителә, Сараи исә, шагыйрьнең тәхәллүсе буларак, аның кайдан икәнлеген белдереп тора. Борынгы заман әдипләры шул рәвешле яки

үзләренең туган шәһәр-авылларына, яисә ханнар алдында тоткан дәрәҗәләренә, яки инде торган төбәкләренә нисбәттә имза сайлап ала торган булганнар. Сәйф Сараи да, шул рәвешле, традициягә таяна, имзасының мәгънәле булуыннан иҗатында да файдалана һәм шигъриятендә дә аны образ-метафора сыйфатында куллана:

Кара кынга төшептер бу Сараи Сәйф бичара,
Ничек уттан чыкып төшсә кылыч баглы кара кынга, —

ди ул, ягъни исемен бу очракта кылыч мәгънәсендә кулланып, аңа символик эчтәлек өсти, үзен кылыч сыйфатында күзаллатып, кара кынга салынган, кертелгән итеп күрсәтә.

Сәйф Сараи үз исемен метафорик эчтәлектә башка урыннарда да куллана, кара тормыш авырлыгы, горбәтлек, җәбер-җәфада яшәү символы итеп, үзен шушы «кын» эчендәге «кылыч» итеп күрсәтә, югары зәвыклы әдип булып укучының күз алдына килеп баса:

Бу фәләк ни чөн мине даим кара кында тотар,
Бу атым Сәйф улдыгы чөнме кара кында тотар? —

(*Сүзлекчә:* Фәләк — күкләр тарафыннан бирелгән язмыш; чөн — өчен; чөнме — өченме; улдыгы — булганы.)

дип белдерә ул мәхәббәт шигырендә.

Авторның шушы рәвештә сүз уйнатулары, камил образлар бирүе кайвакыт әдәбият тарихы белгечләре алдында ике төрле уйларга урын калдыргалаган, ягъни ул үзен «Сарай кылычы» дип атаган, «Сарай» сүзе шуңа бәйле рәвештә генә файдаланылган дигән фикерне белдерүче галимнәр дә юк түгел. Әмма шагыйрь үзен күпвакыт әсәрләрендә Сәйф Сараи дип күрсәтә, шунлыктан бу мәсьәләне катлауландыру урынсыз булуы аңлашылып тора.

Бу «Гөлестан» багбаны ул әдип,
Кем, Сараи Сәйф ирер назмы гарип.

Яки:

Белер Сәйф Сараи гыйшык рәсмен,
Ничек, кем, белсә һәр остад кыйсмен.

(*Сүзлекчә:* Багбаны — бакчачысы, бакчасын караучы, ягъни язган кеше; назмы грип — чит-ят җирдә горбәтлек кичүче шагыйрь; рәсмен — хәлен, гадәтен; остад кыйсмен — остаз үз эшен , үз өлешен.)

Сәйф Сараиның туган җире — Камышлы шәһәрчеге. Ул шунда үскән, әмма бик яшьли Сарайга килгән булса кирәк, чөнки тәхәллүсен туган җиренә түгел, бәлки торган урыны белән бәйләгән ул.

Камышлы йорт бәнем туган илем иде,
Белең: горбәткә килтергән белем иде,
Килеп улдым Сарайда шигырь фидае,
Сарайның шагыйре — илнең гидае.

(*Сүзлекчә:* Бәнем — минем; белең — бел; горбәткә — чит-ят җиргә; улдым — булдым; шигырь фидае — шигырьгә бирелгән зат; гидае — дәрвише, сукбае).

«Ядкәрнамә» кульъязмасыннан китерелгән бу шигъри юллары авторның тәрҗемәи хәлен ачык итеп күз алдына китерергә ярдәм итәләр. Димәк, ул Сарай шәһәренә аң-белем эзләү максаты белем килгән һәм монда укып, зур әдип, шагыйрь сыйфатында җитлеккән. Бу хакта профессор Х.Й.Миңнегулов махсус монография һәм хезмәтләрендә дәлилләп язып та чыккан иде.

Камышлы йортка килгәндә, бу исемдәге торак пунктлары Идел һәм Әму-дәрья елгалары буйларында да бар. Көньяк Сүриядә дә Камышлы дигән зур шәһәрнең булуы географик карталарга күз салуга ук күренеп тора. Безнеңчә, шагыйрьнең бу “Камышлы йорт бәнем туган илем” дигәне Харәзм төбәгендәге, ягъни Әму-дәрья буендагы Камышлы шәһәре булырга кирәк. Чөнки шагыйрь үзенең “Сөһәйл вә Гөлдерсен” поэмасында Харәзм төбәге башкаласы Үргәнечне Аксак Тимер гаскәрләре юк итүгә бик ачынып яза, аны ватаны буларак атый. Бу аның туган туфрагы өчен хәсрәтләнүе билгесе.

Сәйф Сараи, галимнәр фикеренчә, 1321 еллар тирәсендә туган. Аның мәктәп еллары Сарай шәһәрендә узган. Ул вакытларда Алтын Урданың башкаласы булган Сарай шәһәре фән, әдәбият һәм сәнгать үзәгенә әверелгән. «Аз гына вакыт эчендә биредә күп санлы атаклы,

хөрмәт иясе затлар тупланды, хәтта андыйларның халык күп яши торган Мисыр өлкәләрендә дә бу хәтле җыелган юк иде», — дип язып калдырган галим, философ, тарихчы Мөхәммәд ибне Гарәпшаһ (1386-1450). Алтын Урда татарлары белән Мисырны буйсындырган мәмлүкләр дәүләте арасында Бәркә, Нугай, Үзбәк ханнар заманнарында ук гаҗәеп тыгыз һәм дустанә мөнәсәбәтләр урнашканлыктан, ике арада илчелекләр вә сәүдәгәр халкы йөреп торган. Идел буенда болганчык еллар җиткәч, сыеныр урын эзләп, күп кенә олуг затлар Мисырга киткәннәр. Ханнарның үзара тарткалашулары, һаман-һаман тәхет өчен талаш-сугыш оештыруларыннан Сәйф Сараи да гаҗизләнгән һәм Мисырга китеп барган. Монда да әдәби иҗат эшен ташламаган, 70 яшьтә булуына карамастан «Гөлестан бит-төрки» әсәрен тәрҗемә эшенә тотынган һәм аны тәмамлаган. Ә 75 яшендә, 1396 елда вафат булган.

Сәйф Сараи вафат булган вакытта шөһрәте вә даны таралган Алтын Урда дәүләте һәлак алдында тора, Аксак Тимернең һәм тәхет өчен теләсә нинди яманлыкка барырга әзер хәлдәге ханнарның үзара ызгыш-талашларыннан халык иза чигә, мәмләкәт иминлеген югалта.

Фәнни дәлилләүләрдән күренгәнчә, Сәйф Сараи мәмлүкләр дәүләтендә инша диванында сарай хезмәтендә тора, ягъни солтан каршындагы канцеляриядә эшли. Монда, аннан тыш, Алтын Урдадан килгән башка галимнәр дә хезмәт иткәннәр, шулар хисабыннан Рукнетдин Әл-Кырыми (1382 елда вафат), Мәхмүд Сараи (1374 елда вафат) олуг дәрәҗәләргә ия булалар.

1391 елда Аксак Тимер гаскәрләре Алтын Урданы талый, канга батыралар. Бу вакытта 71 яшендәге Сәйф Сараи, Мисырда яшәвенә карамастан, хәбәрне бик авыр кичерә. Шуның өчен дә «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанында шагыйрь Аксак Тимернең Үргәнеч шәһәренә һөҗүм итеп, аны җимереп ташлавын тәэсирле итеп тасвирлый:

Тимер Үргәнҗә тартып килде ләшкәр,
Күреп күз — гүр булып, колак калды кәр,
Кузытты җәң белән галәмдә туфан,
Акытты су тикин йир үзрә күп кан,
Игенче ивләре якылды утга,
Бодай саурылды, туфрак булды ботка.

(*Сүзлекчә:* Үргәнҗә — Үргәнеч шәһәренә; ләшкәр — гаскәр; гүр — сукыр; кәр — саңгырау; кузытты — кузгатты; җәң — сугыш; акытты — агызды; тикин — белән, тиң; үзрә — өстендә; ивләре — өйләре; якылды — ягылды, янды; саурылды — суырылды, коелды).

Димәк, Сәйф Сараи иленнән читтә яшәсә дә, һаман да изге ватан туфрагының именлеге өчен ут вә хәсрәт йоткан, туган җиренә басып кергән дошманга карата нәфрәтен шигырь юлларында белдерүне тиеш тапкан. Бу аның ватанпәрвар, ягъни патриот булуы хакында сөйли. Моның белән иҗатының тарихи әһәмияте дә үсә. Сәйф Сараи шигырьләрен укыганда авторның туган илен сагыну сагышы йөрәк түреннән бәреп чыккан урыннар белән еш очрашырга туры килә. Ул ватанына кайтыр иде, әмма анда сугыш, үтереш, талаш. Хәтта ни шөһрәт казанган солтанар, ханнар да тәхетләрен ташлап, Аксак Тимердән куркыпкачып, Мисырга килеп сыеналар, йөзләрендә — оят, бәгырьләрендә намус билгесе юк. Шундыйлардан берсе — Жалаерлар дәүләтенең солтаны, Багдад әмире, гомерен кәеф-сафада гына үткәргән Әхмәд солтан. Аның хакында Сәйф Сарай болай дип яза:

Күрең, ни гаҗәп җәфачы дәүран килде,
Кем, халкы җиһан күзендин ал кан килде,
Солтаны Гыйрак тәркитеп үз мөлекен,
Горбәткә төшеп, Мисырга миһман килде.

(*Сүзлекчә:* Күрең — күреп тор; дәүран — дәверләр; халкы җиһан — җиһан халкының; слтаны Гыйрак — Гыйрак солтаны; тәркитеп — ташлап; миһмен — кунак булып).

Әхмәд солтаннан шагыйрь сызлану катыш сарказм белән көлә, әмма үзенең чарасы юк, яше олы, ватаны ерак. Ул монда, читтә ватаны өчен хәсрәтләнеп, кайгылы яшь йотып, нәфрәт утында яшәргә мәҗбүр. Аның хәзер йорты да үзгә, яше дә башка.

Үсеп туфрагым үзрә нәйзәләр, бән ивдин айрылдым,
Ватандин бинишан улдым да, үзгә йортка әүрелдем,
Ничек миңа фәләк җәвр әйләде, кандай гөнаһым бар?!
Илаһа, әйлә кәм җәврең, бән илгә садыйк ул ирдем!

(*Сүзлекчә:* Үзрә нәйзәләр — өстендә сөңгеләр; бән — мин; ивдин — өйдән; бинишан улдым — билгесез булдым, мәхрүм калдым; җәвр әйләде — җәбер бирде; кандай — кайда, нинди; әйлә кәм җәврең — җәбереңне ким яса; садыйк — дус, тугрылыклы; ул ирдем — улы идем).

Сәйф Сараи илен уйлап шулай сагышлана, шушы рәвештә хәсрәтләре күңел түреннән шигырь-җыр булып кайнап чыга. Кайтыр иде, ватаны күкрәгендә — сөңгеләр, ягъни сугыш, үтереш.

Искә алып үткән мисаллардан күренгәнчә, Сәйф Сари борынгы татар әдәбиятының шигъриятендә әдәби яктан да, сәяси яктан да камил һәм сокландыргыч шагыйрь буларак күз алдына килеп баса. Аны, мөгаен, XX гасыр шагыйрьләреннән Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан белән генә янәшә куеп карарга мөмкиндер. Замандашлары да аның өстенлеген яхшы белгәннәр, шуның өчен дә аның белешләреннән булган билгесез бер шагыйрь Сайф Сараи хакында мондый юлларны иҗат иткән:

Сараи Сайф тик гариф җиһан эчерә күрең кани?!
Сыйфатын әймәгә белмәй йөрәкдин актарыр кани...
Аның шигъренең иншасын бикәнмәс кем булыр исә,
Мәгәр гаклы аның юктыр, яхуд тәнендә һәм җаны!

(*Сүзлекчә:* Гариф — акыллы, гыйлем иясе; эчрә — эчендә; күрең кани — кайда күрәсең; әймәгә — әйтергә; актарыр кани — канны актарыр; бикәнмәс — белмәс, аңламас, яратмас; яхуд — яки).

Сәйф Сараи үзе исә замандашларына карата бик таләпчән булган, бигрәк тә шагыйрьләр аның күз уңыннан читтә калмаганнар. Мәртәбәле вә лаеклыларын ул үз әсәрләрендә телгә алып, аларны олылап, шигырьләренә шигъри җавап-нәзыйрәләр дә язган, түбән дәрәҗәдәгеләрен көлке объектына әверелдергән. Хәтта үзен дә ул ай янындагы Зөһрә йолдыз белән тиңли, ягъни ай кебек бөек шагыйрьләр янында йолдыз сыман гына дип белдерә:

Җиһан шагыйрьләре, и гөлшани баг,
Кеме былбыл дорыр сүздә, кеме заг,
Кеме тутый бикин чәйнәр шәкәрне,

Кеме ләфзе белән үртәр дәрәзне,
Кемнең сүзләре мәүзини ширин,
Кемнең лаикы — тәшрифе тәхсин.
Кеме үзгәнең әшгарен мәнем дир,
Кеме мәгънә куеп, ләфзен төзәтер,
Кеме вәзнен бозып, сәнгать күзәтер?
Аларның уш бере Сайф Сараи,
Жиһан гарифларының хаки пайи,
Аны сән җөмлә шагыйрь кәмтәре бел,
Камәр йөзгә һәмишә Мөштәри бел.

(*Сүзлекчә:* Гөлшани баг — ал чәчәкләр бакчасы; дорыр — торыр, булыр; заг — карга, козгын; тутый — тутый кош, папугай; бикин — кебек; шәкәрне — шикәрне; ләфзе — сүзе; дәрәзне — яра җөен, йөрәк ярасын; мәүзини ширин — шигъри татлы сүз; лаекы — лаеклысы; тәшрифе тәхсин — яхшы диярлек; әшгарен — шигърен; мәнем — минем; вәзнен — үлчәмен, шигърен; уш — шундый; гарифларының — акыл ияләренең; хаки пайи — аяк туфрагы; сән — син; җөмлә — барлык; кәмтәре — кечрәге; камәр — ай; һәмишә — һәрдаим; Мөштәри — Юпитер, ягъни ай янында Зөһрә йолдыз дигән кебек).

Сайф Сараи үз заманында шигърияте беләν танылган олуг әдип булса да, аның иҗатын хәзерге көндә тулысы беләν белеп бетерүе авыр. Халык арасында мәшһүр саналып та, аның «Кыйссаи-Йосыф», «Сәйфелмөлек китабы», Әхмәт Яссәви хикмәтләре, «Бакырган китабы», «Кисекбаш китабы» һ.б. кебек киң таралыш тапкан кулъязмаларына очрамыйбыз. Табылган китаплары-тупланмалары да асылда Мисыр беләν бәйләнгән. Шунлыктан апны Алтын Урданыкы гына дип түгел, бәлки мәмлүкләр шагыйре дип тә белергә кирәк.

«Гөлстан бит-төрки» әсәре. Сәйф Сараи бу әсәрен Һиҗри беләν 793 елда, Милади беләν 1391 елда яза. Аны ул фарсы-таҗик классик шагыйре Шәйх Мөсләхетдин Сагъди Ширазиның (1204-1291) фарсы телендә язылган «Гөлстан»ына нәзыйрә буларак иҗат итә.

«Гөлстан бит-төрки» әсәренең баштагы бүлекләренең берсендә үк Сайф Сараи болай дип белдерә: «Элек яз көннәрендә беркөн, бөстан эчендә, гөлләр арасында берничә зариф *(акыл иясе)* галимнәр белә утырып, инша гыйлеменнән бәхәс кылып, әбйаты гарип вә әшгаре га-

җәип *(маҗаралы хикәятләр вә сокландыргыч шигырьләр)* укыдым исә, ул галимнәрнең олысы горуз гыйлеменнән бер мөшкел бәетнең тәкъдигын *(ритмын)* сөаль итте. Фил-хәл *(шул хәлдә)* җавабын ишетеп, әйтте: «И әдәбе гарип, сәңа бер муафикъ нәсыйхәтем бар. Кабул кылсаң, хәер булгай!» Әйттем: «Боерың!» Әйтте: «Шәех Сәгъди «Гөлестан»ын төрки тәрҗемә кылсаң, бер сәхибе дәүләт *(дәүләт иясе)* ир атына мисраг ядкәрең җиһанда калсын!» — дип.

Шушы сөйләшүдән соң Сәйф Сараи ниятләп һәм моңа җавап булárак әсәрне тәрҗемә эшенә керешә. Әмма ул турыдан-туры Сәгъдидән генә тәрҗемә итүне үзенә максат итеп куймый, бәлки чын мәгънәсендә иҗат эшенә чума. Аның теләге изге — күңелләрне сокландырырлык чәчәкләр бүләк итү:

Гөл теләсә хатыйрең тулы табак,
Бу «Гөлестан»ыннан уку бер вәрак.
Гөл җамалы берничә көндә кичәр,
Бу «Гөлестан» даимән күңел ачар.

(*Сүзлекчә:* Хатыйрең — күңелең; вәрак — сәхыйфә, бит, яфрак; җамалы — матурлыгы.)

Сәгъдинең «Гөлестан» әсәре 1258 елда язылган, ул төрле хикәятләр һәм шигъри парча, хикмәтле сүзләрдән төзелгән. Прозасы аерым ритмикага буйсындырылган, шунлыктан әсәрнең буйдан-буйга тәэсир көче дә арта бара. Шигырьләр белән хикәятләрне аралаштыру арасында әсәр чын мәгънәсендә «Гөлбакчага» әверелгән.

Сәгъдинең «Гөлестан»ы 8 бүлектән тора: I . Патшалар тормышы турында, II. Дәрвишләр әхлагы турында, III. Аз белән ганәгатьләнү хакында, IV. Эндәшмичә торуның файдасы, V. Мәхәббәт һәм яшьлек, VI. Зәгыйфьлек һәм картлык, VII. Тәрбиянең тәэсире, VIII. Сөхбәт әдәбе хакында. Традицион рәвештә һәр хикәят вә кыйссадан мәгънәви нәтиҗә ясалып, кыйссадан хыйсса чыгарылган. Автор халык авыз иҗатыннан да бик оста файдаланган.

Сәйф Сараи «Гөлестан бит-төрки» әсәрен дә шулай ук төзегән. Ике әсәрдә дә традицион рәвештә Аллаһы тәгаләне зурлау, пәйгамбәре Мөхәммәдне олылау белән башланып китә. Сәгъди үз әсәрен Шираз хөкемдары Мозаффаретдин ибне Зәнгигә багышлаган, Сәйф Сараи исә

«Гөлестан бит-төрки»не Мисыр әмире Бәтхас (Тәйхас) бәккә атап язган. Аермалар башлам вә йомгак урыннарында да шактый, алар хәтта берсе икенчесенә охшамаган дияргә кирәк.

Сәйф Сараи «Гөлестан бит-төрки»дә сигез төрки шагыйрен телгә алган һәм аларның шигъри әсәрләрен теркәп калдырган вә аларга нәзыйрәләр иҗат иткән. Мәүланә Казый Мөхсин, Мәүланә Исхак, Мәүланә Гимад Мәүләви, Әхмәд Хуҗа әс-Сараи, Харәзми, Габделмәҗид, Туглы Хуҗа, Хәсән углы. Аларның сигез газәле аша гына да нинди олуг шагыйрьләр икәнлекләре күз алдына килеп баса. Бу — Сәйф Сараиның әдәби даирәсе хакында да хәбәр итә. Хәсән углы дип имза куйган шагыйрь чыгышы белән Әзербайҗаннан булып, асыл исеме Шәйх Гыйззетдин Пури Хәсән Исфәрәйни. Ул фарсыча һәм төрки телдә язган. Фарсы телендәге шигырьләренә Пури Хәсән, төркичәдәгесенә Хәсән углы имзасын куйган. Габделҗәмид исә Кырым татары булып, әле XV гасыр башларында исән-имин шунда яшәгән, Йосыф-Зөләйха темасына багышланган «Мунисел-ушшак» дастанын иҗат иткән. Телгә алынган башка шагыйрьләр хакында әлегә нигезләнеп әйтерлек хәбәрләр табылганы юк, шулай да аларның Идел буе белән бәйле булулары да мөмкин.

«Гөлестан бит-төрки» әсәренең тулы кулъязмасы Голландиядә сакланып калган, аны Венгер галиме Й.Тори XX йөз башында тапкан, әмма бу табышын фәнни яктан җентекләп өйрәнмәгән. Беренчеләрдән булып Сәйф Сараи хакында тикшеренүләрне төрек галим Фуат Күпреле башлап җибәргән һәм аны мәмллүк шагыйре буларак тикшергән, 1950 еллар башында шулай ук төрек галиме Ф.Н.Өзлүк аның иҗатын җентекле тикшерү эшенә керешкән һәм Лейдан университетының китапханәсендә сакланып калган кулъязма нәсхәнең фотокүчермәсен Анкара шәһәрендә 1954 елда бастырып чыгарган.

Сәйф Сараиның бу кулъязмасы 372 сәхыйфәдән төзелгән, һәр биттә 13 юл, «мәмлүкләр нәсехе» белән яхшы итеп, авторның үзе тарафыннан Сирия ефәк кәгазенә күчерелгән. Бу нөсхәдән чыгып, Сәйф Сараи бик оста каллиграф булганлыгын әйтергә кирәк. Беренче сәхыйфәдәге төрле кул белән язылган фарсы, төрки телләрендәге шигъри парчаларга игътибар итсәк, китапның күп куллар аша үткәнлеген һәм популярлыгын белергә була. Кулъязманың икенче битендә Сәйф Сараи эре хәрефләр белән алты юллык хәбәр бирә һәм анда әсәрнең «Гөлестан» тәрҗемәсе икәнлеген, Сарай шәһәреннән килгән Сәйф тарафыннан

эшләнгәнлеген һәм дә Мисыр әмире өчен махсус багышланган булуын күрсәтә.

Кулъязманың 355-356 битләрендә 13 бәеттән торган шигырь бирелә һәм анда автор әсәрнең язылу датасын хәбәр итә.

«Гөлестан бит-төрки» белән танышып чыккач, анда Сәйф Сараиның үз иҗат җимешләре белән дә, башкларның әсәрләре белән дә очрашасың, шагыйрьнең тәрҗемәче буларак та зур фигура икәнлеген күрәсең, алар аша авторның шигъри осталыгына сокланасың, мисал өчен Сәйф Сараиның «Яз» шигырен күрсәтеп үтәргә мөмкин, мондагы тел байлыгы, образ вә метафоралар, җанлы сурәт күңелләрне биләп ала һәм шагыйранәлек бакчасына алып китә:

Я З

Янә киде яңа әшҗаре хилгат,
Бизәнеп багы-бөстан тотты зиннәт.

Ботаклар алды бөстаннан янә баҗ,
Чәчәкләрдән үренеп һәрбере таҗ.

Бәнәфшә буйнын игде гөлгә каршы,
Ачып гамбәр күзен сөмбелгә каршы.

Булып мотрип гөлестаннарда былбыл,
Кылыр мең төрле нәгъмә берлә голгол.

Янә фирдәвес әгъла тик булып баг,
Зөмрәд рәңен алды тигмә берлә таг.

(*Сүзлекчә:* Әшҗаре — агачлар; хилгат — кием, халат; багы-бөстан — гөлбакчалар; баҗ — өлеш, үрнәк; бәнәфшә — фиалка; буйнын — муенын; игде — иде; гамбәр күзен — кара күзен; мотрип — көйче, җырчы; нәгъмә — көй, моң; фирдәвес әгъләә — җәннәт каты; тик — кебек; бак — бакча; зөмрәд — зөбәрҗәт; рәңен — төсен, сыйфатын; тигмә — тигезлек; таг — тау.)

Сәйф Сараи оста лирик та, сәясәтче һәм фәлсәфә иясе шагыйрь дә. Аның шигъриятендә эчтәлек белән форма тыгыз үрелгән, эчке һәм тышы рифмалар, төгәл-камил ритм авторының идеяләрен укучы колагына тагын да үтемлерәк итеп китереп җиткерә.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны. Фәнни әдәбиятта аны «Ядкәрнамә» дип атап йөртәләр, чөнки ул шушы исемдәге кульязма эчендә кертелгән әсәр һәм анда, бу дастаннан тыш, Сәйф Сараиның вә Мәүләнә Исхак Харәзми, Туглы Хуҗа, Мәүләнә Әхмәд Үргәнчинең дә берничә шигъри әсәрләре урнаштырылган.

Кульязма нибарысы 14 Х 10 см. зурлыгындагы 12 сәхифәдән, ак ефәк кәгазьгә язылган, тышлыгы сакланмаган китаптан гыйбарәт. Аны Үзбәкстаннан Насрулла Дәүранов табып алган. Кульязма Әбул ибне Кадыйр тарафыннан Мисырда күчерелгән һәм ул үзе хакында да мәгълүматлар теркәп калдырган: «...Мән — Әбул ибне Кадыйр, ядкәрем калсын өчен, Аллаһыны яд итеп, Мисырга килеп, мөсафирлык ширбәтен эчәм. Мөшагыйрьләрнең әбйатларыннан *(әдәби әсәрләреннән)* күңелемә дөшгәннәрен шу йирә бититим *(күчерәм)*».

Димәк, Әбул ибне Кадыйр махсус рәвештә үз алдына төгәл максат куеп эш иткән һәм бары тик күңеленә охшаганнары гына кульязмага теркәп барырга кирәк тапкан. Тупланмага Туглы Хуҗа һәм Мәүләнә Исхак Харәзминең берәр газәле, Мәүләнә Әхмәд Үргәнчинең бер газәле һәм ике мәснәвисе урнаштырылган. Алардан соң Сәйф Сараи әсәрләре килә, өч дүртьюллык һәм ике икеюллык шигъри парчалары ахырында «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны урын алган. Кульязма 1398 елда төзелгән, Үзбәкстан җиренә Мисырдан хаҗга баручылар китергән, Камалхан Солтановта сакланып калган.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны 82 бәеттән гыйбәрәт һәм ул ике гашыйкның бер-берсен яратуы, мәхәббәт трагедиясенә багышланган, эчтәлеге белән тарихи вакыйганы яктырта торган әсәр. Ул, башлам һәм бетем өлешләреннән тыш, «Сөһәйлнең чаһта *(чокырда, зиндан коесында)* ятмышы», «Сөһәйлнең төш күрмеше», «Шаһ кызы Гөлдерсен Сөһәйлне күргәне вә уны сүвеп калганын бәяне», «Гөлдерсеннең, чаһга төшеп, Сөһәйл белән сүзләшкәне», «Сөһәйл белән Гөлдерсеннең чаһтан чыгып качканнары бәяне» бүлекләреннән тора. Дастан Чыгтай Урдасы гаскәр башы Аксак Тимернең Алтын Урдага каршы яу белән барып, изү-талау сугышлары алып баруын язудан башланып китә. Сәйф Сараи алдан ук Аксак Тимергә карата нәфрәтен белдереп куя.

Әйттем аглабән дәүрем җәфасын,
Бер ирнең кыйссасы, гаһде вафасын,—

(*Сүзлекчә:* Аглабән — елап; гаһде вафасын — вәгъдә тугрылыклыгын.)

дип яза автор, әсәрендәге каһарманга һәм Аксак Тимернең явына бәйләнешле рәвештә.

Автор сүзнең башында ук вакыйгаларның хакыйкать булуын сиздереп куярга кирәк таба. Сугышта Алтын Урда ханы Туктамышның Сөһәйл исемле улы тоткын хәлендә Аксак Тимер кулына төшә, әсир егет хәле күпләрнең күңелен кузгата:

Имәс әфсана, чын ошбу бетелмеш,
Бу чын, әфсана тик гыйшыкка йителмеш...
Сөһәйл алыпны илттеләр әсиргә,
Һәммә калды булып гажиз бу сергә.
Сипаһилар кылалмый калды чара,
Фәкать калдырды бу гамь дилдә яра.

(*Сүзлекчә:* Имәс әфсана — риваять түгел, әкият түгел; ошбу бетелмеш — бу язылганнар; әфсана тик гыйшыкка йитмеш — әкияттәге кебек мәхәббәткә җиткәннәр; сипаһилар — гаскәриләр; дилдә — бәгырьдә, күңелдә.)

Сөһәйл бик чибәр була, аның матурлыгы хәтта Йосыф пәйгамбәрдән дә өстен, йөз алы хәтта кызыл алмадан да күркәмрәк, сүзе-теле — татлы, үзен күрсә, хәтта Ширин дә аңа гашыйк тотар иде.

Сәйф Сараи әсәрнең каһарманын шул рәвешле сурәтли. Әмма егет җәбер эчендә калган, ул — әсир, газап чигә. Сөһәйлне бу хәлдә күргән кешеләр бар да аһ итәләр, һичкемдә аңа карата дошманлык хисе күренми. Егет өчен мондагы кешеләр вә гүзәл урыннар да сөенеч китерә алмый, йөзе кара көйгән, күңеле сулган:

Очрап этрафта кошлар, дәртле һәмраһ,
Булып мотрип гөлестаннарда былбыл

Кылыр мең төрле нәгъмә берлә голгол,
Башын игмеш, йитеп, алтын башаклар,
Башакларны игенчеләр машаклар.
Йийгар дан ил өчен шуннан игенче,
Ирер бар икмәкедин дур әленче.
Агачларда шәкәр тикин йимешләр,
Бу йирне: «Илләре оҗмах!» — димешләр.
Сөһәйл шул юл үзә бармакта гамькин,
Сүвнече — кара көйгән, күзе намгин,
Аның күңелендә сулгынлык һәмишә,
Күренмәс аңа гөзару набишә.

(*Сүзлекчә:* Һәмраһ — юлдаш, мотрип — җырчы; нәгъмә берлә — көй белән; игмеш — игән; машаклар — җыярлар; йийгар дан — җыяр икмәк; шәкәр тикин — шикәр кебек; үзә — өстеннән (буенча); бармакта гамькин — сагыш эчендә бара иде; сүвнече — сөенче; намгин — тонык; сулгынлык — сулганлык; һәмишә — һаман да; гөзару набишә — гөлбакча һәм агачлыклар.)

Сәйф Сараи монда хезмәт кешесенә, бигрәк тә игенчегә дан җырлаучы буларак күз алдына килеп баса. Бу да аның сәяси карашлары белән бәйләнгән һәм Аксак Тимергә каршы юнәлдерелгән фикерләре белән бәйле: Аксак тимер игенчеләрнең басуларын таптаткан, бодай урынына арпа игәргә мәҗбүр иттергән тиран.

Әсир төшкән Сөһәйлне зинданга ташлыйлар, аякларына-кулларына авыр чылбыр асып, агачка бәйләп куялар. Ул шул тирән биз-чаһта җәбер-җәфада калырга тиеш була. бу зиндан үлгән бәндә өчен генә түгел, тере ккешегә дә салкын караңгы гүр икән.

Көнәш дөнья йөзендин чаһка батты.
Өзелгән гөл тикин туфракта ятты, —

(*Сүзлекчә:* Көнәш — кояш; тикин — кебек.)

дип яза шагыйрь Сөһәйлнең бу газапларын образлы тел белән сурәтләп һәм фикерне тагын да конкретлаштырып.

Зинданда чагында Сөһәйл төш күрә, әмма шушы төшеннән курка кала һәм һушы китә. Имеш ул бер гөлбакчада йөри икән, ә анда пәри кызы, гүзәл зат, чәчәкләр җыя. Аны Сөһәйл күреп ала да сорау бирә.

Диеп аңа Сөһәйл: «Нә гөл торырсән?
Үзең гөлдән күрекле гөл ирерсән!
Нидер затың? Пәриме йә адәмзат?
Мәңа әйт, атыңны даим итәй яд,
Шөкерләр итәен Аллаһка мең бар,
Ки йиткерде мәңа сән тик көнәш яр!»

(*Сүзлекчә:* Нә — нинди; торырсән — буласың син; күрекле — күркәм; ирерсән — булырсың; итәй яд — күңелдә тотармын; итәен — итәрмен; сән тик — синең кебек; көнәш яр — кояштай яр:)

Сөһәйл мәхәббәттән исереп кала, ә гүзәл шунда газәл кебек йөгереп кача. Йөрәгенә төшкән сөю-гыйшык утыннан кабынып киткән егет исә кыз артыннан килә, әмма куып тота алмый, коега егылып төшә. Шунда Сөһәйл уянып китә һәм моның төш кенә булуын аңлап, күңеле тагын да хәсрәт йота.

Сөһәйлнең төш күрү вакыйгасыннан соң шагыйрь «Шаһ кызы Гөлдерсен Сөһәйлне күргәне вә уны сүвеп калганын бәяне» дигән бүлекне урнаштыра һәм анда кәеф-сафа коручы Аксак Тимерне сурәтли:

Үлән үзрә корылган хәймәдә шаһ
Зөфәрдин шат булып ятмышдә әгяһ.

(*Сүзлекчә:* Үзрә — өстендә; хәймәдә — чатырда; зөфәрдин — җиңүдән; әгяһ — хәбәрдар булып, уяу.)

Аның Гөлдерсен исемле бик чибәр кызы бар. Йөзе гөлдән дә матуррак, күңелендә гыйшык диңгездән дә тирәнрәк икән. Гөлдерсен үзенең кол кызлары, иптәшләре белән, ирләргә керергә тыелган урында кәеф-сафа корып ял иткәнендә Сөһәйлне зинданга китергәннәрен күреп кала һәм үзен-үзе тыя алмый, Кояш тирәли Җир ничек әйләнсә, ул да шулай Сөһәйл тирәли тәкатьсездән урап йөри, гашыйк була.

Сөһәйлне күрдею әйләнде бер тик,
Көнәш гирдендә йөргән мисле Җир тик.

(*Сүзлекчә:* Күрдею — күрүгә; гирдендә — тартуында, тирәсендә; мисле — мисалында.)

Сәйф Сараиның шушы шигъри юлларыннан чыгып, галимнәр Шәрыкта Җирнең Кояш тирәли әйләнүен инде күптән, Николай Коперникка (1473-1543) кадәр (Коперник бу теориясен XVI гасырның беренче чирегендә ачыклый башлап, 1530 елларда ахырына җиткерә) билгеле булган дип баралар. Сәйф Сараи исә бу галимнәрнең хезмәтләре белән танышкан һәм иҗатында образлы фикерләүдә бик уңышлы файдалана алган, дибез.

Гөлдерсен үзен гөл кебек, ә Сөһәйлне шушы гөлгә кунарлык былбыл итеп күз алдына китерә. Мәхәббәте артканнан-арта һәм егетне кыз, зинданга төшеп, йөзгә-йөз күрмәкче була. Икмәккә исерткеч сеңдереп, каравылчыга ашатырга да, йоклатып, егет янына керергә исәбе.

Алдагы бүлектән без Гөлдерсеннең ниятенә ирешкәнен беләбез. Икмәкне ашаган каравылчы йоклап китә, кыз тизрәк егетне күрергә ашыга:

Ни күрсен, кем, булып тупракта бихәл,
Сөһәйл ятыр, ташалмыш яңлы гөл ал.
Күреп Гөлдерсен, аглап хәлегә йөз,
Чаһ эчрә керде, куйды йөзенә йөз.

(*Сүзлекчә:* Тупракта — туфракта; бихәл — хәлсез; ятыр — ята; ташалмыш яңлы — ташланган төсле; аглап хәлегә йөз — хәленә йөз тапкыр елап, күп елап; чаһ эчрә — зиндан эченә.)

Сөһәйл дә кызны күреп ала, төштәгесен өнендә очратканына сөенә, үзенең мәхәббәтен аңлата. Алар инде күптән бер-берсенә гашыйк ярлар төсле сөйләшәләр вә сөешәләр. Шунда Гөлдерсен егетне моннан чыгып качарга һәм зинданда елап утырганчы, башка урында күңел ачсак, дөресрәк булыр иде дип өнди. Соңгы бүлек менә шушы хакта.

Алар куйды икесе юл сари пай,
Бакып торганда юлга зар сачып ай,

Берекеп китте гашыйклар озакка,
Эленмәй юл үзә куйган тозакка.

(*Сүзлекчә:* Сари — тарафына; пай — аяк; бакып — карап, багып; сачып — чәчеп; берекеп — берегеп, берләшеп; эленмәй — эләкмичә; юл үзә — юлга, юл буена.)

Ике гашыйк бер-берсенә тотынышып озак йөриләр. Әмма алар монда кала алмый, ничек тә качарга кирәк. Менә кояш эссесеннән тәмугтай кызган сәхра-чүлгә барып керәләр. Ашарларына бер телем икмәкләре, эчәргә сулары юк. Бу җирләргә хәтта кошлар да адашып очып килмиләр.

Йыкылды ташнә Гөлдерсен ачындин,
Күмәк кемдин килер чүл эчрә кемдин?
Сөһәйл барды табарга суга-данга,
Вә ли дәрман бирәлмәй калды җанга:
Ул ялгыз сәхра эчрә калды ялгыз,
Булып ташнә, корып калган тик йолдыз.

(*Сүзлекчә:* Йыкылды — егылды; ташнә — сусаган; ачындин — ачлыктан; күмәк — ярдәм; кемдин — кемнән; данга — икмәк кисәгенә; вә ли — әмма ләкин; бирәлмәй — бирә алмый; у — ул; тик йолдыз — үлән тамыры кебек.)

Гөлдерсен шул рәвешле чүлдә ачтан һәм сусаудан үлгәч, Сөһәйл үзенең ятканыннан башка яшәүнең мәгънәсен күрми һәм, үзенең күкрәгенә хәнҗәр кадап, һәлак була. Аның аһ оруыннан буран чыга, күкләрнең йөзе бозыла, өсләреннән туфрак күмеп китә. Алар шулай «бәхет»кә ирешәләр. Бу серне бары тик ялгыз чүл үзе генә белеп, башкалар сизенми калалар.

Болардан чыгып, Сәйф Сараи сүзгә йомгак ясый һәм шуны белдерә:

Хатын — садыйк, аны сүвгел, газиз ир,
Һәр агыр эштә һәм даим сәне дир,
Уңа дуст бул, уны сүвгел, күңел бир,
Аның сүз бәхредин гәүһәрләрен тир!

(*Сүзлекчә:* Садыйк — иптәш, дус; сүвгел — ярат; агыр — авыр; сәне дир — сине дияр, сине чакырыр; уңа — аңа; бәхредин — диңгезеннән; тир — җый.)

Шагыйрь шушы Сөһәйл белән Гөлдерсен мәхәббәтен Мәҗнүн һәм Ләйлә гыйшкына тиңли, әмма бу вакыйгаларның ялгансыз, чын-хакыйкать икәнлеген кабаттан тәкрарлап китә һәм бу язылган әсәренең илләр укырлык, тарихларга калырлык ядкәр булуына ышанычын белдерә, Аллаһы тәгаләдән Сарай шәһәрен золымнан коткарып калуын үтенә, шулай әсәр тәмамлана:

Йите йөз туксан алты, нәүрүз ае
Хатем итте боны Сайфи Сараи.

Димәк, әсәр нәүрүз аенда, ягъни март ахырында 796 елда язылып бетә. Ул Милади белән 1393 елга туры килә. Бу датадан күренгәнчә, Сәйф Сараи «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасын Мисырда «Гөлестан бит-төрки»не тәмамлаганнан соң өч ел үткәч иҗат иткән һәм бу дастаны белән дә халык арасында дан-шөһрәт казанган булып чыга.

Шуны аерым күрсәтеп узарга кирәк, Сәйф Сараи юктан гына үзенә тәхәллүс итеп Сараи имзасын алмаган. Ул гомере буена аңа тугрылыклы калган һәм Алтын Урда, ватаны өчен, аның саулыгын күзәтеп, ут йотып яшәгән. Бу ватанпәрвәрлек сыйфаты шигъриятендә дә чагылыш тапкан. Сәйф Сараи — бөек шагыйрь, аның мәртәбәсе шигъриятендә дә, камил сәясәтендә дә һәм башка замандашларына карата мөнәсәбәтендә дә чагыла.

Йомгак: Сәйф Сарай — 1321 елда Камышлыда туган, әүвәле Сарай шәһәрендә, аннары мәмлүкләр Мисырында яшәгән бөек татар шагыйре, «Гөлестан бит төрки» нәзыйрә китабының (1390-1391) һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1393) дастанының һәм күп кенә шигырьләрнең авторы. 1396 елда Искәндәриядә вафат. Ул тарихларга олуг фикер иясе һәм ватанпәрвәр шагыйрь буларак кереп калган.

МӘХМҮД БИНЕ ГАЛИ
(...–1360)

Алтын Урданың Насретдин Рабгузый дәрәҗәсендәге һәм дини дидактик проза өлкәсендә эшләүче галим-язучыларның икенче — әл-галимүр-Раббани вәл-гамилүс-сәмәдани әл-остадул-мотлак Мәхмүд бине Гали әс-Сараи вәл-Булгари вәл-Кәрдари, ягъни «камиллек дәрәҗәсенә ирешкән остаз, дин галиме Мәхмүд бине Гали Сараи һәм Болгар вә Кәрдар йортыннан».

Мәхмүд бине Галинең әсәре, Насретдин Рабгузыйныкы кебек, татарлар арасында сакланып калган һәм бу аның үзеннән соңгы дәверләрләрдә дә популярлыгы хакында сөйли торган факт булып тора. Мәхмүд бине Гали «Нәһҗел-фәрадис» («Аллаһы тәгаләгә ирешү юлы») китабының авторы. Галимә Фәнүзә Нуриева аның китабын 2002 елда бастырып чыгарды. Мәхмүд бине Гали һәм иҗатына җентекле анализ ясады.

Тормышы. Мәхмүд бине Гали әс-Сараи тумышы белән, үзе белдергәнчә, Болгардагы Кәрдардан булган. Әмма болгарларда Кәрдар дигән торак яки шәһәрнең булмавыннан чыгып, галимнәр аның тормышы Харәзм өлкәсендәге Кәрдар шәһәрчегенә бәйлиләр. Фәндә кабул ителгән фикер буенча, ул чорда күчмә кыпчаклардан Кордәр исеме белән танылган бер кабилә булган һәм ул кабилә тотрыклы рәвештә соңгы дәверләргә кадәр казакълар арасында яшәгән (Ә.Нәҗип). Харәзм җирлегендәге Кәрдар шәһәрчеге исә Алтын Урданың дини фәлсәфәсе һәм галимнәре үскән урыннарның берсе саналган һәм, галимнәргә ияреп, Мәхмүд бине Гали дә шушы шәһәрчектә берәр дин галиме гаиләсендә туган вә тәрбияләнгәндер дияргә мөмкин. Әмма ул вакытта, Мәхмүд бине Гали әс-Сараиның тәхәллүсендәге Болгари имзасын инкарь итәргә туры килә. Ә бу һич мөмкин түгел.

Авторның үзе хакында Болгари дип белдерүе мәсьәләсенә бәлки бүтәнчәрәк ачыклык кертеп буладыр? Мәсәлән, Болгар мәмләкәте элек-электән Харәзм төркиләре белән тыгыз бәйләнештә яшәгән, үзара галимнәр вә шагыйрьләрен алмашып торуларын бу төбәкләр хәтта Казан ханлыгы чорында да дәвам иттергәннәр. Мәхмүд бине Гали дә шул рәвештә Болгар йорты белән бәйләнгәндер диярга була. Әмма бу юл мәсьәләне тулысынча ача алмый. Аны бары тик Болгар илендә Кәрдар дигән торак яки шәһәрчекнең ачыклануы белән генә чишеп була.

Мәхмүд бине Гали Әс-Сараиның кайсы елда туганлыгы хакында мәгълүматлар юк. Шулай да без аның XIV гасыр башларында дөньяга килгәнлеген белдерә алабыз. Ә менә якшәмбе көн 1360 елның 22 мартында Сарай шәһәрендә үлгәнлеге төгәл билгеле, бу хакта «Нәһҗелфәрадис» әсәренең күчермәләреннән Истамбул нөсхәсе хәбәрләрне бүгенге көнгә кадәр китереп җиткергән. Бу нөсхә Сарай шәһәреннән чыккан, озак вакытлар мәмлүкләр Мисырында сакланып, соңыннан Истамбулның Яңа Җәмигъ мәсҗиденә вакуф малы буларак килеп кергән һәм галим Зәки Вәлиди тарафыннан 1928 елда өйрәнелгән.

«Нәһҗел-фәрадис» кулъязмалары Казан китапханәләрендә һәм С.Петербургта да бар. Кырым нөсхәсе дә Истамбул кулъязмасы белән бер үк елда табылган, әмма бүгенге көндә югалган санала. Болардан чыгып без әсәрнең таралыш даирәсе хакында фикер йөртә алабыз. «Нәһҗел-фәрадис» китабы Идел-Урал буйларыннан алып, Кырым һәм Мисырга кадәр мәмләкәтләрдә билгеле булган. Ләкин Урта Азия нөсхәләре барлыгы бүгенге көндә билгеле түгел, димәк, әсәр татарлар яшәгән төбәкләрдә генә популяр саналган.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрен Мәхмүд бине Гали Алтын Урда белән Җанибәк угылы Бирдебәк ханлык иткән заманда Сарайда иҗат иткән. Бу чорда Идел-Урал буйларында галим-голамәгә аерым һәм зур игътибар бирелгән, бигрәк тә дини-дидактик китапларга ихтыяҗ үсеп киткән. Шунлыктан авторның үз чорында ук әсәрләреннән күчермәләрне төзегәннәр. Мәхмүд бине Гали дә үз гомерендә үк олуг галим буларак танылып өлгергән булса кирәк. Юкса ул үзенә карата «әл-галимүр-Раббани вәл-гамилүс-сәмәдани әл-остадул-мотлак» дип әйтмәс иде, ягъни үзен «камиллек дәрәҗәсенә ирешкән остаз, дин галиме» димәс иде. Башкалар да аны шулай дип белгән, китабы шуның өчен дә киң таралыш тапкан.

Димәк, болардан гына да Мәхмүд бине Галинең Алтын Урданың Сарай шәһәрендә танылган дин галиме һәм мөдәррисе булганлыгы, мәдрәсә тотканлыгы ачыкланыла.

Иҗаты. «Нәһҗел-фәрадис» әсәрен Мәхмүд бине Гали Һиҗри ел исәбе белән 759 ел сәфәр аеның 8 көнендә, ягъни Миладп белән 1358 елның 20 гыйнварендә тәмамлаган. Сакланып калган кулъязма нөсхәләреннән берсе — Ялта нөсхәсе — Һ. 792 ел рабигыль-ахыр аенда, ягъни М. 1390 елның мартында Касыйм бине Мөхәммәд тарафыннан эшләнелгән. Истамбул нөсхәсе дә шулай ук Сарайда төзелгән һәм аны кү-

черүче Һ. 761 ел җумадиел-әүвәлнең алтысында, ягъни М. 1360 елның 25 мартында төгәлләнгән. Казан һәм С.Петербург нөсхәләре исә соңгырак дәверләрдә төзелгәннәр.

Фәндә беренчеләрдән булып «Нәһҗел-фәрадис» хакында Ш.Мәрҗәни 1885 елда хәбәр бирә һәм аны «Кыйссаи-Йосыф», «Кисекбаш китабы», «Нәсыйхәтес-салихин», «Бәдәвам», «Нәүрүз бәете», «Шәһри Болгар газилары бәете» белән бергә караган, Болгар әдәбияты истәлекләреннән исәпләнгән.

Әсәрнең кульязма нөсхәләре төрле күләмдә, Ялта кульязмасы 549 биттән тора, әмма тулы түгел, Истамбул нөсхәсенең зурлыгы 444 битлек. Татарстан Фәннәр академиясендә саклангаң кульязма исә 536 сәхифәдән тора һәм XVII гасырга карый дип исәпләнелә.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәре тулы килеш дүрт бабтан, ягъни 4 бүлектән төзелгән. Һәр бүлек унар фасылга, ягъни бүлекчәгә бүлгеләнеп бирелгән. Димәк, әсәр барсы кырык фасылдан гыйбарәт.

Беренче бабта Мөхәммәд пәйгамбәрнең тууыннан алып үлеменә кадәр булган тарихы сөйләнелә. Кереш өлешендә автор болай дип билгеләп уза: «Имде шәйхина вә сәидина (*шәехебез һәм юлбашчыбыз*) ... шәйхел-ислам вәл-мөслимен Мөхәммәд-шәех, йәссәрә Аллаһы (*Аллаһы тәгалә аңа җиңеллек бирсен*), бу китапка «Нәһҗел-фәрадис» дәю исем кылынды. Мәгънәсе — «Оҗмахларның ачык юлы» тимәк улыр, өмид ул торыр».

Моннан чыгып без Мәхмүд бине Гали белән янәшәдә Мөхәммәд-шәех исемле затның да булганлыгын белә алабыз. Ул исә язучының шәехе булдымы, әллә инде Сарайда Ислам дине эшен алып баручы җитәкче идеме, ачык кына билгеләү әлегә монда мөмкин түгел. Шулай да Мөхәммәд-шәехнең сәед һәм шәйхел-ислам дәрәҗәсен тотканлыгын аңлавы кыен түгел. Шушы рәвешле үк, Алтын Урда таркалгач, Казан ханлыгында дин эшләренә сәедләр җитәкчелек иткән. Сарайда да бу шулай булырга кирәк. Димәк, Мөхәммәд-шәех Сарайның XIV гасыр урталарында сәеде хезмәтен үтәгән һәм хан даирәсендә торган. Мәхмүд бине Гали дә аның якыннарыннан исәпләнгән һәм аның фатихасы белән язу эшенә керешкән.

Монда автор Мөхәммәд пәйгамбәрнең бер хәдисен искә төшереп үтә, аннан үзенең максатларын да укучыларга аңлатып уза: Мөхәммәд пәйгамбәрнең кырык хәдисен берәү яхшы белеп, аларны бүтәннәргә өйрәтә-аңлата икән, ул кеше галимнәр исәбендә санала, ә үлгәч, шә-

һитләр, ягъни Сират күперен вә Гарасат җәфаларын үтеп тә тормастан җәннәтле булучылар хисабына кертелә икән. Шушыңа нигезләнеп, Мәхмүд бине Гали бу китабының һәр фасылын бер хәдис белән башлап китә һәм ул хәдиснең эчтәлегенә бәйле рәвештә дини-дидактик, тарихи, фәлсәфи, этик һ.б. эчтәлекләргә нигезләнгән риваять вә хикәятләрне сөйли, алар аша хәдисләрнең мәгънә-эчтәлеген тирәнәйтә, мисаллар бирә, үз фикерләрен дә куәтли.

Икенче баб Мөхәммәд пәйгамбәрнең дүрт яраны: бер-бер артлы хәлифә булып торган Әбу-Бәкер, Гомәр, Госман һәм Гали сәхабәләргә багышланган. Монда шулай ук кызы, оныклары, дүрт мөҗтәһид, ягъни дин галимнәре хакында да риваятьләр сөйләнелә, хәбәрләр китерелә.

Әсәрнең өченче бабы изге гамәлләр хакында, анда гыйлем эзләү, ата-ананы хөрмәтләү, хәлал ризык ашау, яхшылыкка өндәү, яман эшләрдән тыю-тыелу, канәгатьлелек һәм сабырлык, исламның биш баганасы булган биш фарыз намаз, иман китерү, зәкят, ураза, хаҗ үтәү мәсьәләләре хакында.

Дүртенче баб белән китап тәмамлана. Монда Мәхмүд бине Гали кешеләр арасында күренгән һәм Ислам дине вә шәригате тарафыннан тыелган яман вә хурлыклы гадәтләр хакында яза. Болар: кеше үтерү, зина кылу, аракы эчү, тәккәбберлек, ялган һәм гайбәт сөйләү һ.б хәрам эшләрдән гыйбарәт.

Шулай итеп, әсәрнең соңгы ике бүлеге дини-фәлсәфи мәсьәләләргә багышланганнар һәм хәлал белән хәрамны бер-берсеннән аерырга өйрәтәләр, кешенең тормыш-көнкүреше белән турыдан-туры бәйләнгәннәр.

Алда күрсәтеп узганча, әсәр кырык хәдискә бәйле рәвештә кырык фасылдан тора һәм һәрберсендә бер хәдис китерелгәч, гыйбрәт вә аңлатма өчен, иллюстрация буларак берәр хикәят яки риваять сөйләнелә. Мәсәлән, «Шәех ибне Гыймран казый хикәяте». Монда юмартлык белән саранлыкның Ахирәт көнендә нәрсәгә китергәннәре сөйләнелә һәм саранлыкның хәвефкә төшерүе аңлатыла.

Ибне Гыймран исемле бер шәех мөсафирлар, мескен вә фәкыйррәләргә карата киң күңелле булып, аларны йортында ризыкландыра һәм тәрбияләп җибәрә икән. Әмма беркөнне аның өстәлендә һич тә сые калмагач, ул, казый алдына килеп, ярдәм үтенә. Казыйның аңа исе дә китми. Шуннан соң Ибне Гыймран бер яһүдине очратып, аңа хәлен

сөйләп бирә, ә бу кеше аңа кирәгенчә алтын бирә. Шәех, мөсафирларны сыйлагач, яһүдигә атап барчасыннан дога кылдыра.

Икенче көнне казый шөбһәле төш күрә, анда ул ибне Гыйммранга дәрвишләр сые өчен хәер-садакадан акча бирмәгәне өчен җәннәтсез калганлыгын белеп ала, әмма соң була.

Мәхмүд бине Гали бу хикәяте белән фәкыйрь һәм мескеннәргә ярдәм итүнең савабын белдереп, саранлыкны яманлый. Ә менә «Ата белән бала мәхәббәте турындагы хикәят»тә өлкәннәр һәм яшьләр мәсьәләсе күтәрелә.

Сахра-кырда улы белән атасы йөргәндә яннарыннан бер кош очып уза. Шунда, малае сорагач, әтисе кошның исемен әйтеп бирә. Кош алар тирәсендә җиде тапкыр күренеп, бала үтенгән саен, аның исемен атасы һаман белдереп бара, бер дә авырыксынмый.

Менә малай үсеп буйга җитә, әтисе картая. Алар тагын шушы сәхрада. Атасы тәҗрибә өчен улыннан беренче тапкыр бу кошның исемен сорый, теге җавап бирә. Әмма икенче тапкырында, картайдың, бер дә исеңдә тормый икән, бер әйттем бит дип, инде улы әтисен үпкәләтә. Шунда атасы улына серне ачып бирә һәм әйтә, мин сине тәҗрибә кылдым, шуның өчен генә сорадым, син әле бала чагында җиде кат сорап, җиде тапкыр җавап биргән идем, ә үзең хәзер, миңа икенче мәртәбә җавап бирергә тәләмичә, рәнҗеттең: «Мәгълүм булды, кем, угыл-кыз мәхәббәте ата-ана мәхәббәтенә йитмәс ирмеш, диде».

«Гадел көтүче кол хикәяте»ндә Ибне Гомәрнең бер көтүче колны тәҗрибә итүе сурәтләнә. Ибне Гомәр дөреслек белән яшәүче колның барлыгын ишетә дә, җәйләүгә килеп, аның белән очраша, бер сарыкны сатып бирүен сорый. Әмма бу кол каршы төшә. Ибне Гомәр, бу сарыкны бүре ашады дип хуҗаңа әйтерсең, миңа сатып бир, ди, тагын үтенеп. Кол бу сарыкларның үзенеке түгеллеген һәм сата алмаслыгын аңлатып бирә, барлык серләрне Аллаһы тәгалә күреп торганлыгын белдерә. Гомәр улына аның җавабы охшый һәм ул тәҗрибә кылып кына болай эшләгәнлеген әйтә, көтүчене һәм гарифлардан, ягъни акыл ияләреннән дип таный да, хуҗасыннан ул колны сатып алып, азат итә.

Бу хикәятләрдән генә дә күренгәнчә, Мәхмүд бине Гали Әс-Сараи гомумкешелек өчен зарури булган идеяларны күтәреп, дин аша тугрылык, ярдәмчеллек, башкаларга хөрмәт белән карау кебек һ.б. югары дәрәҗәдәге сыйфатларны яклап чыгучы язучы буларак күз алдына килеп баса. Әгәр дә бу вакытларда Алтын Урдада тәхет өчен сугыш, үза-

ра талаш, җәбер вә золым орлыкларының җитлегеп килгән чоры икәнлеген искә төшерсәк, Мәхмүд бине Галинең иҗаты тарихи әһәмияте ягыннан тагын да югарырак мәртәбәдә икәнлеген искәрергә мөмкин булыр иде.

Йомгак: Дини-дидактик проза өлкәсендә эшләгән Алтын Урданың мәртәбәле галим-язуыларыннан берсе — Мәхмүд бине Гали Әс-Сараи, ул 1360 елда Сарай шәһәрендә вафат булган һәм «Нәһҗел-фәрадис» исемендә дүрт бүлектән торган проза әсәре иҗат итеп калдырган.

«КИСЕКБАШ КИТАБЫ»
(XIII–XIV йөзләр)

Галимнәр тарафыннан «Кисекбаш китабы» XIV гасырга, ягъни Алтын Урда чорына нисбәт ителә, авторы билгесез санала. Әсәр беренче тапкыр 1846 елда Казанда басылып чыккан, аңа кадәр кульязма рәвешендә халык арасында киң таралыш тапкан. Октябрь инкыйлабына кадәр төрле наширләр тарафыннан кат-кат бастырып таратылган, элекке татар мәдрәсәләрендә уку дәреслеге сыйфатында файдаланылган. Ш.Мәрҗәнинең хәбәрләренә караганда, бу поэма Идел буеннан тыш башка төбәкләрдә очрамый, бездә генә таралыш тапкан борынгы ядькәр.

«Кисекбаш»ның 133-134 бәетләре мондый юллардан төзелгән һәм әсәрнең авторын билгеләргә ярдәм итә төсле:

Мәүланә Шәмсе Тәбризи ярына
Син тигергел гаҗизләр морадына,
Фәгыйләтүн, фәгыйләтүн, фәгыйләт —
Пишкадәм остазымның рухы шат.

Автор үзенең кем булуын, ягъни «Мәүланә Шәмсе Тәбризи яры» булуын шулай белдерә. Һәрхәлдә бу шигъри юллардан ул шулай аңлашыла. Моннан чыгып, «Кисекбаш»ның авторы әсәрен остазына, аның рухы шат булсынга багышлавын күрсәтеп үтәргә мөмкин. Ә кем соң ул Мәүланә Шәмсе Тәбризи?

Мәүланә Шәмсе Тәбризи (Шәмсетдин Тәбризи) яры — төрек шагыйре Җәлалетдин Руминың (1207–1273) псевдонимы. Ул 1244 елда фикер иясе, суфи Шәмсетдин Тәбризи белән очраша һәм алар, уртак

тел табып, озак кына фикер алышалар. Бу вакытта инде мөдәррис һәм шагыйрь буларак танылган Җәлалетдин Руми Шәмсетдин Тәбризинең дөньяга һәм дингә карашларына соклана, шушы тәэсирләреннән соң иҗатында яңа этап башланып китә. Мәснәвиләрен, газәлләрен һәм касыйдәләрен, дастаннарын «Мәүланә Шәмсе Тәбризи яры» имзасы белән яза башлый.

Җәлалетдин Руми әсәрләрен асылда фарсы телендә язган. Төрки телдә бөтенләй дә иҗат итмәгән дип белдерүче галимнәр дә бар. Аның әсәрләренең төрки теленә тәрҗемәләре дә шактый.

«Кисекбаш китабы» колофонында “Мәүланә Шәмсе Тәбризи яры» дип белдерелүдән чыгып, бу дастанны Җәлалетдин Руми язган дигән фикергә этәрә. Әмма галимнәр аның әсәрләре җыентыкларында мондый әсәр очрамый дип баралар, фарсы телендә дә бу әсәр юклыгын белдерәләр.

«Кисекбаш китабы»ның татарлар арасында таралыш тапкан кулъязмаларыннан кайберләрендә «Мәүланә Шәмсе Тәрази яры» диелгән. Шуңа таянып, галимнәр «Кисекбаш»ны Шәмсе Тәразига нисбәт итәргә омтылалар. Әмма «яры» сүзе белән нишләргә? Борынгы кулъязмаларның хаталы күчерелү очракларына игътибар итсәк һәм Шәмзе Тәрази дигән шәхеснең тарихта билгесез икәнлегеннән чыгып эш итсәк, беренче версия үз көчендә калганлыгын аңларбыз.

Төрки телдәге һәм татар мәдрәсәләрендә уку китабы булып йөргән «Кисекбаш китабы»ны Җәлалетдин Руминың «Кисекбаш кыссасы»на нәзыйрә сыйфатында барлыкка килгән. Халык тарафыннан күп мәртәбәләр шомартылып, яттан сөйләнеп, хәтергә ышану аркасында, яттан «күчерелеп», бу әсәрнең күп төрле вариантлары язылган. Шулай итеп, бу дастан XIII гасырда, 1249–51 еллар тирәсендә кыйсса буларак Җәлалетдин Руми тарафыннан язылган һәм халкыбыз арасында таралыш алган дип белдерә алабыз.

«Кисекбаш китабы» татар галимнәре тарафыннан шактый өйрәнелгән, тел тарихын тикшерүчеләр дә, әдәбиятчылар да бу поэманы XIV гасырга да кайтарып калдыралар. Әмма аның монгол яуларына кадәр үк халык арасында билгеле булып, телдә йөргән булуы вирсиясен дә әйтәләр. Әгәр Җәлалетдин Руми «Кисекбаш кыйссасы»н 1250 еллар тирәсендә генә язганлыгы версиясенә таянсак, димәк, бу әсәр монгол яуларына кадәр үк барлыкка килгән дия алмыйбыз.

«Кисекбаш» әсәре Алтын Урда чорында киң таралыш тапкан, моның өчен сәяси-иҗтимагый шартлар уңай йогынты ясаганнар, аннан соңгы дәверләрдә дә татарлар арачсында бу китап яратылып укылган. «Кисекбаш» поэмасының беренчел авторы Җәлалетдин Руми түгел дигән фикерне яклаучылар белән килешсәк, ул вакытта әсәрне язган кеше бу китабын остазына, ягъни Шәмсе Тәбризигә (ярар, Шәмси Тәразига булсын) багышланган дигән версия өстен чыга һәм шагыйрьнең XIV гасыр башларында яшәп иҗат иткәнлеге дөреслеккә туры килә дип карала ала. Кызганыч, әмма әлегә күпчелек галимнәр шушы фикерне яклыйлар.

«Кисекбаш» поэмасы Аллаһы тәгаләне, пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһис-сәламне искә төшереп, укучыны Ислам диненә, ягъни «Мостафаның җәмгатенә» чакыру белән башланып китә. Кайбер кулъязма һәм ташбасма китапларда Мөхәммәднең могҗизасыннан шагыйрьнең вакыйга сөйләргә җыенганлыгы белдерелә:

Хак ядыны кылды делем, сөйлим,
Мостафа могҗизатын шәрхәйлим.

(*Сүзлекчә:* Хак ядыны — Аллаһының исемен; делем — телем; шәрхәйлим — аңлатыйм.)

Әсәрнең кайбер вариантларында «Хак ядыны» урынына «Хак яры» дип бирелгән, шулай ачыктан-ачык хата ясалган һәм мәгънә бозылуга китергән.

Алга таба әсәрдә болай языла һәм:

Сүзләгәнем бер хубы изге дастан,
Кем, күңелләр шады кылаин дустан.
Дөньяда хубы-хуб эшләр күп торыр,
Һич моның тик бере тәкый юк торыр, —

дип асыл эчтәлеккә керешә шагыйрь.

Әмма кайбер басмаларда бу юллар юк, алар урынына икенче төрле бәет килә:

Ултырыр, ди, Мостафа дүрт яр илә,
Утыз өч мең сәхабә җөмлә белә.

Шушы рәвешле нөсхәләрнең төрлечә булулары күчереп йөртелү вакытларында кыскартылу яки, сәхифәләрнең төшеп калып, бозылган вариантларны китап төзүчеләрнең файдаланулары аркасында икәнлеген белдереп үтәргә була.

Әсәрнең Казан басмалары, бигрәк тә 16 биттән торган 1846 елгы Казан университеты чыгарган китаплардан күчереп эшләнелгәннәре төзегрәк һәм тулырак. Алда китереп үтелгән юлларга кадәр күрсәтелгән ошбу басмада Гали сәхабәгә дан җырлаучы берничә бәет китерелә:

Тәңре әйтер: «Арысланымдыр ул Гали,
Ул — гали, ул — сәхи, ул — вәли!
Ул Галинең ирлегене сыналым!» —
Назым берлә бер хуб шәрхен кылалым.

(*Сүзлекчә:* Ул гали — ул бөек; сәхи — юмарт; вәли — дәрәҗә иясе (шәех дәрәҗәсеннән узган, әүлиялеккә ирешеп килә торган суфи); сыналым — сыныйм әле; хуб шәрхен кылалым — яхшы аңлатмасын сөйлим.)

Бу басма берникадәр татарчалаштырылган, төзүче аңа каләм керткән. Чөнки ташбасма һәм аерым кульъязмалардан алып күрсәтелгән бәет монда башкачарак бирелгән:

Хак яды кылса — бу телем сүзләгәй,
Мостафаның могҗизатын шәрхәйләгәй.

Утыз өч мең сәхабә белән әңгәмә корып утырган Мөхәммәд пәйгамбәрнең якты айдай йөзенә яраннары карап, сүзләренә колак тотып торган вакытларында алар каршына елап бер Кисекбаш килә:

Гәүдәсе юк, бер гаҗәеп баш ирер,
Шәһид ирер, ике күзе яшь ирер.
Ни гәүдәсе, ни азакы, ни иле,
Бер Кисекбаштыр, һаман сүзләре теле.

(*Сүзлекчә:* Ирер — булыр; азакы — аягы; иле (әле) — кулы; вар — бар.)

Бу Кисекбаш ак сакаллы һәм күзне камаштырырлык нурлы йөзле икән, кем аңа караса, күзләре чалына. Бу баш Мөхәммәд пәйгамбәр каршына килеп, зар-зар елый, йөзен туфракка ора. Пәйгамбәр, аны күреп, куркарак төшә, шунда Гали сәхабә — Тәңренең Арысланы — аяк үрә торып, каршы килә. Башны күтәреп, Мөхәммәд галәйһис-сәлам янынарак китерергә исәбе, әмма ничә кеше көч-куәт күрсәтеп карасалар да, аны урыныннан бер мыскыл да кузгата алмыйлар.

Хәйран калды, Галинең исе китәр,
Ул Баш әйтер: «Йа Рәсүл, Гали нитәр?
Котынымы сынаер Гали миңа,
Әйтел, Изгел бирмәсен зәхмәт аңа!
Гали тик һәм мең Гали булыр ирсә,
Барча бер булып миңа килеп ирсә.
Барчасы булып мине күтәрмәгәй,
Зәррә-мыскал йиремдин тибрәтмәгәй.

(*Сүзлекчә:* Котынымы — көченме; әйтел — әйт; Изгел — Аллаһы тәгалә; зәррә — бөртек тә.)

Бу Баш бик хикмәтле булып чыга. Ул Калгаи Зәрриндә, ягъни Алтын калада (кайбер басмаларда: Калган Нури — Нури каласы) гомерен үткәргән Шәех-Габдалла исемле (ә бу мәгълүмат ташбасма вариантта гына бар) суфи икән. Җир йөзендә атка атланып йөрсә, күкләр катына могҗиза белән ирешеп, адәми сурәттә фәрештәләр арасында була, «Иseme–Әгъзам» догасын укып, Муса галәйһис-сәлам белән намаз кыла, Хозер һәм Ильяс пәйгамбәрләр белән галәм гизә. Әмма көннәрнең берендә аның сөекле улын Дию ашаган, ә хатынын коега алып төшеп киткән. Менә шуннан икән Шәех Габдалланың бар хәсрәте. Мөхәммәд пәйгамбәрдән бу Кисекбаш шулай итеп шәфкать үтенә һәм ярдәм бирүен сорый. Шунда Гали алга чыга һәм Исламның Зөлфекарь кылычы белән Диюнең башын чабып, бу затның хатынын азат итәчәген белдерә. Мөхәммәд пәйгамбәр Галине, үлеп калуын теләмәгәнгә, анда бармаска өнди. Әмма Аллаһының арсланы саналган Гали сәхабә бармый каламы соң. Дөлдел атка атлана, Зөлфекарь кылычны бәйли һәм юлга

чыга. Артыннан Хәсән белән Хөсәен уллары һәм утыз өч мең сәхабә елап озата киләләр.

Гали белән Кисекбаш икәүдән-икәү генә калып, юлны дәвам итәләр. Дөлдел ыргылып чаба, Кисекбаш — Коръән укый, гүяки канатлы, бик тиз бара, тау-ташлардан тәгәрәп-тәгәрәп китә.

Алар җиде көн вә төн киләләр. Шунда бер сәхрага ирешәләр. Коены эзләп табалар. Мең биш йөз колачлык арканны төбенә ташлыйлар, очын кое авызына бәйләп куялар. «Исеме–Әгъзам» догасын укып, җиде көн вә төн буе Гали сәхабә кое төбенә төшә, сигезенче көнендә генә аягы җиргә тия. Бераз хәл алгач, эзләнеп, бер тимер капка күрә, Аллаһы тәгалә исеме белән аны ватып ача:

Тартты, кубарды, күрде олуг сарай,
Бер хатын ултырмыш ирде йөзе ай.
Йөзе күрке сарайга нур әйләмеш,
Тәнренең гыйшкы җанга кәр әйләмеш.
Намаз укыр ул Ахирәт хатыны,
Аһ итәр, күккә чыкар һәм төтене.

(*Сүзлекчә:* Ултырмыш — утыра иде; кәр әйләмеш — мөнәсәбәт, тәэсир итәр; чыкар — чыгар.)

Бу хатын Кисекбашның сөеклесе булып чыга. Тагын да бер сарайны Гали күреп ала, анда биш йөз мөселман тоткында ята икән. Көн дә Дию аларның бишесен ашап бара, инде шул рәвешле биш йөз кешенең башына җиткән. Алар Гали сәхабәдән ярдәм үтенәләр. Монда Мөхәммәд пәйгамбәр могҗиза белән булып киткән һәм тоткын мөселманнарга котылачакларын белдергән икән. Бу хәбәрдән Гали таң-гаҗәпкә кала һәм диюне үтерергә юнәлә.

Гали чөн, кем, керде ул дәм сарайа,
Диюне күрде, охшар ул манарайа,
Бармаклары охшар адәм гәүдәси,
Мең яшендин кичмеш ирде ул гасый.
Гөмбәзә охшар иде аның баши,
Кылмамыш гомрендә ул хәер эши.

(*Сүзлекчә:* Чөн — чөнки; дәм — мизгел; сарайа — сарайга; манарайа — манарага; гасый — бозык; гөмбәзә — гөмбәзгә; кылмамыш — кылмаган.)

Дию йоклап ята икән. Гали аны оеган хәлендә үтерергә теләми, кычкырып карый, әмма Дию уянмый. Икенче мәртәбәсендә тау-ташлар тетрәрлек итеп тавыш бирүеннән соң гына айнып, дүрт ягына карана башлый Дию. Авызыннан утлар чәчә. Мин әле үзем сине табып, үтерергә ниятләгән идем, сине монда кем китерде, дип аваз сала, тотып ашыйм, Мәккә-Мәдинәне йотам, ди. Кулына гөрзи-чукмар алып, Галигә суга, аның төзеннән җиргә батыра. Әмма батыр куркып калмый, таш өстенә сикереп менә. Дию аның исән булуына гаҗәпсенә. Гали аңа иман китерергә, «бармак күтәрергә» киңәш итә, әмма Дию теләми. Шуннан Аллаһының Арысланы кылычын айкап җибәрә һәм аны үтерә, ишектән көтелмәгәндә күп кенә диюләр агылып кереп, Галигә ташланалар.

Өч йөз дию үлтерде ул көн Гали,
Тәңренең Арсланыдыр ул шаһ вәли.

Диюләр чигенә һәм качып бетәләр. Гали сәхабә мөселманнарны тоткынлыктан коткара, Диюнең малын аларга өләшә. Алар күтәрә алганча байлык җыялар, әмма кое төбеннән чыга алмыйлар. Шунда Гали сәхабә Җабраил фәрештәне чакырып дога кыла, ул, килеп, аларны, канатына алып, чыгарып куя. Барысынында исән-имин котылганың Мөхәммәд пәйгамбәр белеп тора һәм сәхабәләр белән каршы алырга килә. Барчасыда сөенешәләр. Кисекбаш та күренә. Гали аны кулына күтәрә. Мөхәммәд галәйһис-сәлам дога укый һәм Кисекбаш яңадан егет хәленә кайта. Улының коры сөякләрен Дию ашамый калдырган икән. Аңа да Хак тәгалә җан кайтара, бүләге буларак халат-чапан тапшыра. Әсәр шулай тәмамлана.

Эчтәлеге белән «Кисекбаш» поэмасы татар халкының «Таң батыр» әкиятенә тартым, ләкин алар бер-берсен турыдан-туры кабатламыйлар. Шулай да Таң батырның падишаһ кызларын коткарырга коега төшүе, дию белән сугышу урыннары, тез тиңентен җиргә чумулары һ.б. моментлар үзара туры киләләр һәм халык иҗаты белән аваздашлыгы хакында сөйли торган фактлар буларак аңлашылып торалар. Әгәр дә

без Урта гасырлар татар поэзиясендә дини риваятьләр вә легендаларны шагыйрьләрнең файдалану факты белән очрашсак, фарсы һәм гарәп әдәбиятында киң таралган сюжетларга мөрәҗәгать итүләрен күрсәк, «Кисекбаш» әсәрендә бөтенләй башка очрака тап булабыз. Бу — фольклор сюжетының әдәбиятка килеп керүе. Шуның өчен дә «Кисекбаш» поэмасын галимнәр баштарак халык иҗаты әсәре сыйфатында йөреп, соңыннан китап рәвешендә теркәлгәнлеген версия буларак яклап чыгалар.

«Кисекбаш китабы»на нигезләнеп, 1908 елда бөек татар шагыйре Г.Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын иҗат иткән һәм борынгы сюжет нигезендә үз чорының көлкеле сатирик планда ачып биргән.

Йомгак: 1. «Кисекбаш китабы» борынгы татар әдәбиятының иң камил ядькәреннән берсе һәм эчтәлеге белән татар халык иҗатына аваздаш. Аны әүвәле Җәлалетдин Руми 1250 еллар тирәсендә тудырган. Төрки телгә нәзыйрә буларак күчерелеп, татар халык язма әдәбияты җәүһәрләренең берсенә әверелгән.

2. «Кисекбаш» — әкияти-героик әсәр. Татар мәдрәсәләрендә уку-укыту әсбабы буларак борынгы вакытлардан ук файдаланылган.

АЛТЫН УРДА ТАРКАЛГАН ЧОРДА ӘДӘБИЯТ

XIV гасырның ахырында Алтын Урда таркала башлый. Берьяктан, мәмләкәтнең үз эчендә башбаштаклык көчәя бара, шуның аркасында үзара ызгыш-талашлар аерым мирза вә кенәз-ханлыклар арасында гына түгел, бәлки олуг хан даирәсенә дә үтеп керә, икенче яктан, Алтын Урда белән Чыгтай дәүләте арасында электән килгән каршылык тагын да кискенләшеп китә, идарә башына утырган Аксак Тимер сугыш сәясәтен алып барырга керешә. Һулагү хан заманнарында ук яман аты мөселманнар арасында таралган шушы Чыгтай ханлыгының идарә башлыгы тиран хан Ислам дөньясын бозыклыкта гаепли һәм үзен аларны чын мөселманлыкка ут вә кылыч белән кайтарачак олуг шәхес сыйфатында күрсәтә башлый. 1388 елда Алтын Урданың Үргәнеч шәһәренә гаскәр белән килеп, аны талау һәм җимерү максаты белән сугыша. Җиңелгән каланы сугышсыз бирелмәгәне өчен җир белән тигезләтә, өстен сөрдереп, арпа чәчтерә. 1395 елда дәһшәтле кансыз гаскәрләре Идел-Урал буйларын талый, Алтын Урданың данлыклы шәһәрләрен җимерә. Туктамыш ханга каршы мәмләкәт эчендәге мирзалар да кушыла, Сарай тәхетен саплап калу олуг хан өчен авырлаша. Идегәй мирза Аксак Тимер ягына чыгучыларның берсе була, үзе дә аңламыйчадыр, ватанына һәлакәт китертүче сыйфатында эш йөртә, халыкны талата, мәмләкәтне җәбер-золымга күмә. «Идегәй дастаны» шушы чорларда иҗат ителә, татар халкы шушы әдәби иҗатында үз тарихын һәм тарихи шәхесләренә карата булган мөнәсәбәтен буыннарга бәян итеп калдыра. Татар белән татарның якага яка алышып сугышуы «Идегәй дастаны»нда болай сурәтләнгән:

Иртә булды, кич булды,
Калын сугыш эш булды.
Көн тотылып, чаң булды,
Ике чирү бер килеп,
Ике Иделнең арасы
Икесенә тар булды.
Аттан тояк калмады,
Баштан колак калмады,
Тапталып яткан үлекнең

Исәбе-саны булмады.
Сансыз татар — кара яу
Якадан якага алышып,
Берсенә-берсе капланып,
Теш-тырнагын актарып,
Бугазга-бугаз чәйнәшеп,
Ни булганын белмәде.
Кайсы башын актарды,
Кайсы җирдә капланды,
Кич булганда шул булды —
Һәр ике як аз калды.

(*Сүзлекчә:* Калын сугыш — каты сугыш, күп гаскәр белән барган сугыш; чаң булды — караңгылынды; чирү — гаскәр.)

Мәмләкәт эчендәге үзара тарткалашу вә сугыш бер дә яхшыга китерми, Европа һәм Азия дәүләтләрен үзенең шөһрәте белән тетрәндереп торткан Сарай тәхете вә Алтын Урда ханлыгы кан эчендә кала, таркала, җимерелә. «Таш өстендә таш калмый». Империя шушы рәвештә һәлакәт таба. Аксак Тимер яуларыннан соң, Идегәй мирзаның башбаштаклыгы ахыры шул була, ил тәмам таркалып бетә, халык ярлыланып, җәбер вә җәфа эчендә кала. «Бозык» мөселманнарны кабат «иман»га китүче Аксак Тимер, киресенчә, гаепсез халыкка золым һәм фәкыйрьлек кенә калдыра, бар җыйган малларын һәм байлыкларын талый вә талата, яшьләрне-картларны колыкка куып алып китә. Бу тиранга карата халык күңелендә нәфрәт кала.

Сарай тәхетенең иң соңгы олуг ханы Туктамыш 1404 елда Идегәй гаскәрләре белән сугышып, шунда һәлак ителә. Бу вакыйгалар хәзерге Мордовия территориясендә, Темников (Төмән) шәһәреннән ерак түгел урында була. Шуннан соң Алтын Урда тәмам какшый һәм аның элеккеге дан-шөһрәте телләрдә генә сөйләнергә кала, ил кабат җыела алмый. Кавказ, Дагыстан, Кырым, Төмән, Мәскәү, Әстерхан, Касыйм, Нугай мирзалыклары кебек ханлыклар һәм кенәзлекләр барлыкка киләләр. Һәрберсе үз сәясәтен алып бара башлый.

Аксак Тимернең Алтын Урда өстенә гаскәр белән йөргәнен, Үргәнеч шәһәрен һәлак иткәнен үз күзләре белән күреп нәфрәтләнгән шагыйрь Әхмәт Үргәнче, бүтән әдипләр кебек сыену урыны эзләп, Ми-

сыр мәмлүкләренә качып китә һәм гомеренең соңгы елларын шушында үткәрә. Иҗаты белән Мисыр эчендә дә ул дан тоткан булса кирәк. Юкса, үз чорының олуг шагыйрьләреннән саналган Сәйф Сараи кебек, камил вә оста каләм ияләре белән бергә «Ядкәрнамә» җыентыгына (1398) кертелмәс иде.

Әхмәт Үргәнченең яшәгән еллары фән өчен мәгълүм түгел. Аны кыпчак ыруыннан, XIV йөзнең икенче яртысында һәм XV гасыр башларында Үргәнеч һәм Мисырда гомер иткән дип галимнәр өйрәнә. Сакланып калынган «Тормыш — куркулы төш», «Ошбу әбйат җиһангир Тимерләнггә язылмыш ирде» дигән шигырьләреннән чыгып, затлы каләм иясе икәнлеген күрсәтеп үтәргә кирәк. Ул үзен «Тормыш — куркулы төш» әсәрендә тормышны яратучы, гамь утында янып-көюче, вәхшәтнең дошманы, юксыллар хәсрәтен йотучы итеп белдерә. Илдә тынычлык бетү аркасында аның күзләре «сукырайган», ягъни, моннан шул аңлашыла, ул күп елаган, канлы яшьләр түккән. Бары туган илендә «тынычлык гөле сачылгач» кына аның «сукыр» күзләре ачылачык, ягъни ул елаудан туктаячак.

Әхмәт Үргәнче — ватанпәрвәр шагыйрь, әмма иленнән куылырга мәҗбүр ителгән, җәбер-золымнан газапланган зат. Шуның өчен ул тормышны кукулы төш итеп күз алдына китерә. Әсәр безгә менә шул хакта сөйли. Гаделлек орлыгын изгән тираннар, илне талап, гаепсез-гөнаһсыз каннарны түгәләр.

Фәкать гушымда юксыллар фөгане,
Күренмәс золму-вәхшәтнең туганы,
Күренмәс булганына күңел хуштыр,
Хәят имәс бу хәят, куркулы төштер! —

(*Сүзлекчә:* Гушымда — колагымда; фөгане — аһ-зары; золму-вәхшәтнең — золым-вәхшәтнең; туганы — кара кошы, ерткыч кошы.)

дип белдерә Әхмәт Үргәнче, җәбер-золымнан качып киткәнен уйлап, боларның инде артта калуына күңеле белән тынычлангандай. Әмма аның өчен мондый тормыш яшәү була алмый, илен сау итеп күрәсе килә аның.

«Ошбу әбйат җиһангир Тимерләңгә язылмыш ирде» шигырендә исә Әхмәт Үргәнче әрнеп-сыкрап Аксак Тимергә нәфрәтен белдерә һәм,

халыкка китергән казалары өчен, Аллаһы тәгалә аны тәмугка салсын дип тели. Чөнки күпме кешеләрне елаткан ул, алар Җәйхун белән Сәйхун тулып агардай канлы яшьләр түкәннәр, аһ-зарлары күкләргә кадәр ашкан. Әмма болар өчен тиран җавапсыз калырга тиеш түгел, барыбер җәзасын күрәчәк ул, сарык көтүен буучы бүре ничек көтүче таягына очраса, башкалар өстенә күтәргән кешенең ташы ничек үз аягына төшсә, шул рәвешле Аксак Тимер дә җәһәннәмгә олагачак әле.

Үргәнчә иктерсәң арпа, үнеп сәлм чыкады,
Һәр башакның даныдан сиңа үлем чыкады.
Зәһәр салган ашымыза ахыр үзе эчәде,
Кара туфрак үзә үзгә кара кәфен печәде, —

(*Сүзлекчә:* Үнеп — уңып; сәлм — алабуга; чыкады — чыкты; даныдан — бөртегеннән, ашлыгыннан; зәһәр — агу; эчәде — эчте; үзә — үзенә; печәде — кисә.)

дип автор, галәм бу тираннан котылгач, «дөньяда дуслык, гаделлек шаһы калыр»ына ышанычын белдерә.

Аксак Тимернең Алтын Урданы изеп-талавы халык арасында шулкадәр көчле нәфрәт уяткан ки, хәтта бу вакыйгалардан соң күпме еллар узса да, татар язучылары-шагыйрьләре моны исләренә төшергәннәр. Казан ханы шагыйрь Мөхәммәдәмингә (1469–1518) нисбәт ителгән шигырь дә тарихи язмаларда сакланып калган. Шул әсәре «Гыйкап» («Үч алу») дип атала. Ул Әхмәт Үргәнче шигыре белән уртак яңгыраштa килеп чыккан, гүяки аның дәвамы буларак та тәэсир итә:

Чыкты Һиҗрәтдин җиде йөз илледә,
Төште галәмгә хараплык зилзилә.
Үзе — аксак, гаклы — ахмак, фетнәдә
Золымыны изһар кылды һәр йирә.
Күп голамә вә мөшәихләр шәһит
Булдылар һәм дине Ислам нур илә.
Дарел-Ислам фетнәсендин, бел гаян,
Булды вәйран, акты яшьләр хәүфилә.
Ни җавап бирер Хода кашында ул —
Сораса Аллаһ шиддәтү-гыйкап илә?

Йа Илаһым, әйдә ул бәндәңне сән
Ахирәттә залимү-Җәһил илән.

(*Сүзлекчә:* Һиҗрәтдин җиде йөз илледә — Милади белән 1350 елга туры килә; хараплык зилзилә — харап итүче җир тетрәү; изһар кылды — күрсәтте; йирә — җиргә; бел гаян — ачык бел; булды вәйран — җимерелде; хәүфилә — хәвеф-хәсрәт белән; кашында — каршында; сорса — сораса; шиддәтү-гыйкап — каты җәза; залимү-Җәһил илән — Әбу-Җәһил залим белән.)

Аксак Тимер кебек тираннар Ислам дине дошманнарыннан булган Әбу-Җәһил белән бергә тәмуг җәзасын күрәчәкләренә ышаныч белдерә шушы рәвешле Мөхәммәд Әмин хан. Моннан чыгып без аның никадәр гаделлеккә вә иминлеккә омтылучы хөкемдар икәнлеген дә күзаллыйбыз.

Алтын Урда шагыйрьләреннән бу урында *Бәркә Фәкыйһ* иҗатына да махсус тукталып үтәргә кирәктер. Ул Котбның «Хөсрәү вә Ширин» дастанын күчерүче хаттат та. Аның Алтынбога исемле Алтын Урда арестократы хезмәтчесе икәнлеге мәгълүм. Алар мәмлүкләр Мисырның Искәндәрия шәһәренә килгәннәр.

Бәркә Фәкыйһның тормыш юлы тулысынча мәгълүм түгел, шулай ук аның туганлыгы, кайчан вафат булганлыгы да билгесез. Ул ислам дине буенча да китаплар төзү, тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән. 1383 елда «Хөсрәү вә Ширин»не күчереп бетергән һәм аңа өстәмә буларак үз шигыри үрнәкләрен дә теркәп калдырган һәм иҗатын күз аллау өчен бераз мәгъләмат калдырган. Аның тулы исеме — Бәркә ибне Бәракиз ибне Кандуз ибне Идегү Кыпчакый. Моннан чыгып, без аның кыпчак нәселеннән, атасының исеме Бәракиз икәнлеген беләбез. Фәкыйһ — аның тәхәллүсе, ягъни дини кануннар белгече дигән мәгънәне белдерә һәм шөгелен күрсәтеп тора. Юкка гына шәригать китаплары төзү белән шөгельләнмәве дә шушы имзасы ярдәмендә ачыклана. Ул Мисыр мәмләкәтенә гаскәри хезмәт, «тәҗрид өчен» килгән. Мәмлүкләр үзләре дә сугышчы коллардан чыканнар һәм тәхетне яулап алганнан соң да, димәк, кыпчак кабиләләреннән гаскәрләрен туплауны дәвам иткәннәр икән.

Бәркә Фәкыйһ үзе хакында шигырендә болай яза:

Килеп Искәндәргә тәҗрид өчен,
Алаен тип кяфердән мөэмин үчен...
Атагым ма Бәркә Фәкыйһ тип анчак,
Үзем мөэмин вә мөслим ма аслым кыпчак.

(*Сүзлекчә:* Тәҗрид өчен — сугышка; алаен тип — алам дип; атагым ма — исемем дә; анчак — анда, шул чакта; аслым — асылым.)

Алтын Урда чоры мәхәббәт шагыйрьләреннән XIV гасырның *Туглы Хуҗа, Габделмәҗит, Мәүләнә Казый Мөхсин, Мәүләнә Гыймад Мәүләви, Әхмәт Хуҗа Сараи, Мәүләнә Исхак, Хәсән углы, Хәйдәр Харәзми* кебек шәхесләрнең дә булганлыгын һәм шактый кызыклы мәртәбә иясе әдипләр икәнлекләрен дә атап үтәргә кирәк. Алтын Урда да үзенең шагыйрьләре һәм галимнәре белән дан тоткан. Әмма күбесенең иҗатын бүгенге көндә тулысынча өйрәнү һәм барлау кирәк әле. *Насретдин Рабгузый, Мәхмүд бине Гали* кебек язучылар белән бергә, ул чорда *Котб, Харәзми, Хисам Кәтип, Сәйф Сараи* кебек олуг дастан һәм поэма авторлары да яшәгәннәр һәм тарихыбызда тирән эз калдырып киткәннәр. Күбесенең иҗат ядкәрләре талау сугышлары аркасында юкка чыгарылган. Берән-сәрән генә булса да кайбер әсәрләре мәмлүкләр Мисырына барып ирешү аркасында исән калган. Идел буенда сакланып, ничәмә-ничә еллар аша бүгенге көнгә килеп ирешкән Хисам Кәтипнең иҗатын да исебезгә төшерсәк, татар халкының үз тарихына һәм әдәби ядкәрләренә карата булган мөнәсәбәте хакында да сүз кузгату урынлы булыр иде. Борынгыдан килгән әдәби ядкәрләрне барлау һәм өйрәнү, аларны саклау — һәркемнең изге бурычы. Аларны юкка чыгару — үзеңне-үзең хәтерсез итү белән бер. Әдәбият ул халыкның күңеле, бәгырь түре. Әдәбият ул мәдәниятнең иң югары билгесе һәм аның сыйфат дәрәҗәсе.

Алтын Урда әдәбияты шәхесләргә һәм әсәрләргә иң бай тарихи чорыбызның берсе. Шушы ядкәрләребездән чыгып, тарихыбызның да никадәр олуг һәм мәртәбәле булганлыгын күз алдыбызга китерә алабыз. Мәхмүд бине Фәттах әс-Сараи (775/1373 елда вафат) кебек олуг галимнәр Алтын Урда, Сүрия, Каһирәдә мәктәп-мәдрәсә тоткан, шагыйрь Танбага әҗ-Җуали Галәэтдин бине Гатаулла (747/1343 елда вафат) үзенең таланты белән күпләрне сокландырган, тиңдәшсез төрки шагыйрь булып исәпләнгән. Болар тарихлардан билгеле, әмма җитәр-

лек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән һәм иҗатлары барланмаган әле. Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк, Алтын Урда чоры шактый кызыклы һәм бай әдәби дәвер, бу — мәмләкәтнең мәдәни үсеше шактый югары булганлык хакында сөйли торган төп фактларның берсе.

ХАНЛЫКЛАР ЧОРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ
(XV–XVI йөзләр)

XIV гасыр ахырыннан башланып киткән үзара тарткалашу һәм таркаулык XV гасыр башында Алтын Урданы һәлакәткә китерә, ул төрле ханлыкларга тәмам таралып, элеккеге мәгърурлыгын вә көч-куәтен югалта, аның байлыгы таратыла, хәерчеләнә бара. Сарай шәһәре һәртөрле баскынчылар өчен талау объектына әверелә. Аның каравы Дагыстан, Әстерхан, Кырым, Себер ханлыклары аякка тагын да ышанычлырак баса башлыйлар. Шушы вакытларда Казан ханлыгы да күтәрелеп китә. Моны Сарай хөкемдары Олуг-Мөхәммәд хан белән бәйлиләр. Әмма шунысын онытырга кирәкми, Урта-Идел, Казан-Болгар тирәләре электән мөстәкыйльлектә яшәгәннәр, шулай да бу тулы бәйсезлек түгел, бәлки икътисади яктан алга китү аркасында барлыкка килгән үз тормышы белән гомер итү рәвешле генә булган. Мәскәү кенәзлегенә дини тормыш үзенчәлекле, ягъни христианлык нигезенә корылу аркасында, аларда мөстәкыйльлек рухи яктан Казанга караганда шактый өстен дәрәҗәгә күтәрелгән һәм алар тәхет бүлешә башлаганда гына Сарайны исләренә төшергәннәр. Казан-Болгар йорты исә рухи дөньясы белән, ягъни ислам динендә торуы ягыннан Сарайга тыгызрак бәйләнгән, аңа үзен ирекле тоюы өчен рухи мөстәкыйльлектә яшәмәве комачаулык иткән. Тәхеттә Чыңгыз нәселеннән булган шаһзадәләр утырганмы, әллә инде Болгар заманнарыннан ук килгән нәсел идарә иткәнме, бу сорауга ачык җавап бирү әлегә мөмкин түгел. Шулай да Р.Фәхретдинов, борынгы кулъязмаларга нигезләнеп, Болгар тәхетендә Галибәк хан утырганлыгын, ул чорларда Казанның хәрабә хәлендә торганлыгын фараз итә.

1437 елда Кечек-Мөхәммәд Сарай тәхетендәге Олуг-Мөхәммәд ханга каршы яу белән килә, аңа куштан мирзалар да кушылалар һәм җиңүгә ирешәләр. Олуг-Мөхәммәд Сарайдан чыгарга мәҗбүр була, хатыннары, балалары һәм өч мең кешесе белән Литвага кушылган Белов шәһәренә килеп урнаша, тәхетен кабат кайтарып алырга тели. Әмма Мәскәү кенәзе Василий III аңа гаскәр күтәрә, Олуг-Мөхәммәд солых үтенә, руслар кабул итмиләр, сугышырга мәҗбүр итәләр.

Олуг-Мөхәммәд Тимерхан бине Тимер-Котлыг хан бине Тимер-Мәлик хан бине Рус хан чарасыз кала. Тәһарәтләнеп, агач күләгәсендә ике кат намаз чыга, аннан соң сугыш атына атланып, бер мең чамасы

гаскәре белән 40 меңлек урыс сугышчыларына каршы көрәшкә күтәрелә һәм, алар арасына коткы салып, җиңүгә ирешә. Бу вакыйга 1438 елның 5 декабрендә була.

Шушы җиңүеннән соң ул Идел ягына кайта һәм, Казанга килеп, монда тәхет кора, шәһәрне хәрабәдән күтәрә, үзенә чирмеш-чуашларны куша. Казан 1439 (һ.842) елда икенче тапкыр аякка баса.

Олуг-Мөхәммәд хан Василий III күрсәткән яманлыкларны гафу итми һәм Мәскәү өстенә сугышлар белән йөреп тора, Түбән Новгрод җирләрен үзенә буйсындыра, 1445 елның язындагы бер сугышында Василий III аның кулына әсир төшә, әмма солых һәм ясак түләтү шарты белән аңа 1 октябрьдә ирек бирелә. Болгар ханы дип үзен атап йөрткән Галибәк гаскәрләрен тар-мар итеп, ханлыгын тагын да ныгыта. Шулай да озак яшәми, 1446 елда вафат була. Ул Сарай тәхетендә 17 ел, Казанда 8 ел ханлык итә. Аның идарә иткән елларыннан башлап Казан ханлыгы ныклап оеша һәм Мәскәү кенәзлеге өчен беренче куркынычка әверелә.

Казан шәһәре мәдәният һәм мәгариф үзәкләренең берсенә әйләнә һәм гүяки Сарайның олуг мәртәбәсе аңа күчә, шул ук вакытта тәхет өчен көрәш кебек «яман авыруы» да шушы дан-шөһрәт белән бергә ияреп килә.

XV гасырдагы татар әдәбиятын бар тулылыгы белән күз алдына китерүе авыр. Ул чорда Мәҗлиси белән Сайади кебек шагыйрьләр яшәгәнлеге билгеле. Аларның әсәрләре Идел буенда киң таралыш таба.
XVI гасырда Казан ханлыгында әдәби хәрәкәт югары үсеш ала. Мөхәммәдьяр, Колшәриф, Касыйм Шәех исемле шагыйрьләрнең иҗатлары рухи байлыкка әверелә. Алар үзләре дә легендар шәхесләр булып чыгалар һәм гасырлар буена татар халкы күңелендә болар хакында төрле риваять һәм хәбәрләр сакланып килә.

Татар әдәбиятында Казан ханлыгы чорында да дини-дидактик рух, суфичылык юнәлеше дәвам итә. Бу сыйфатланышлар мәхәббәт дастаннарында да нигез рәвешендә сакланалар һәм шагыйрьләр үзләрен чын мәгънәсендәге суфи итеп күрсәтелләр, иҗатларында моны кат-кат тәкрарлыйлар.

Касыйм Шәехнең сакланып калган һәм «Бакырган китабы»на кертелгән бердән-бер газәленнән чыгып, аның көчле лирик булганлыгын билгеләп үтә алабыз. Колшәриф иҗатында дини-дидактик эчтәлек өстенлек тоткан, бу үзенчәлеге аның Казан ханлыгында хөкүмәт соста-

вында булуы, сәед хезмәтен алып баруы белән дә аңлатыла ала. Бу яктан Мөхәммәдьяр иҗаты да аңа аваздаш.

Казан ханлыгының оешуы электә булган Болгар дәүләтчелегенең әдәби-гыйльми шөһрәтен кире кайтаруда һәм күтәрүдә ярдәм иткән. Бу хакта Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд «шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг» дип яза. Шулай итеп,1439-1440 елларда Казан шәһәре хәбәрләрдән күтәрелә һәм Казан ханлыгының башкаласына әверелә. Монда фән, әдәбият, сәнгать үсеше өчен мөмкинлекләр ачыла.

МӘҖЛИСИ
(XV йөз ахыры – XVI йөз башлары)

Фәндә Мәҗлиси XV гасыр ахыры XVI йөз башларында иҗат иткән шагыйрь дип аңлатыла. Тарихка ул үзенең «Сәйфелмөлек» әсәре белән кереп калган һәм татар халкының электән яратып укылган авторларның берсенә әверелеп киткән. Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф»ын халык ничек үз күрсә һәм иманы кебек кадерләп сакласа, Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» дастаның да шулай ук күңеленә якын иткән, буыннан-буынга күчереп, бүгенгегә китереп җиткергән. Ә кем соң ул Мәҗлиси? Кайда туган? Кайда яшәгән һәм иҗат иткән?

Тормышы. Фәнни әдәбиятта Мәҗлисинең Харәзм якларыннан булганлыгын тәкрарлыйлар. Аның эзләре Көнбатыш Себер, Җаек буйларында да табыла.

Хивада (Харәзм) Мәҗлиси Гобәйдулла хан һәм аның улы Габделгазиз хан сарайларында хезмәт иткән. Аны Мәүланә Мәҗлиси дип атап йөрткәннәр. Ул телгә оста вә маһирлыгы белән аерылып торган. Сагышлы-борчылу йөзле, әмма мәҗлесләрдә катнашырга ярата икән. Үзенең туган якларын еш исенә төшерәче, гарип, ягъни иленнән аерылган дәрвиш буларак та белгәннәр аны.

Мәҗлисинең шигырьләре Бабур ханга да таныш булган. Хәбәрләргә караганда, Мәҗлиси үзенең бер касыйдәсен Бабур хан каршында мәҗлестә сөйли һәм, ханның күңелен кузгатып, аны таң-гаҗәпкә калдыра. Бабур хан, күңеле утыргач: «Мөхәммәд Салих бу шигырен нәрсә өчен язгандыр?» — дип сорый һәм, касыйдәдә телгә алынган Мөхәммәд Салих исеменнән чыгып, әсәрнең авторы да ул булса кирәк дигән ялгыш

фикергә килә. Ханның бу сүзләреннән соң Мәҗлиси, шигырь Бабур хан күңеленә хуш килде булса кирәк, дип уйлый һәм: «Бу робагыйны мин язган идем, йомшаклыгымнан Мөхәммәд Салих исеменә шөһрәт китердем»,— дип җавап бирә.

Мәүланә Мәҗлисинең бу сүзләреннән Бабур ханның кинәттән ачуы кабара һәм үзенә дошман кешене шигырендә мактаганы өчен шагыйрьне катил итәргә әмер бирмәкче була. Әмма, аннары ниятеннән кире кайтып: «Шигыреңә җиде мең тәңкә бирермен дип карар кылган идем, кан бәясенә учлап кал инде!» — дип ачуланып, мәҗлесеннән Мәҗлисине кудыртып чыгара.

Моннан соң аларның очрашканнармы-юкмы, ул хакта хәбәрләр сакланмаган. Һәрхәлдә Бабур кулына Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» әсәре кергән дип уйларга кирәк, чөнки аның бу әсәре Бабур хан төзегән Бөек Монголлар дәүләтендә кулдан-кулга укылып йөртелгән, соңыннан моңа галимнәр дә игътибар иткәннәр.

«Сәйфелмөлек» әсәренең «Мөнәҗәт» бүлегендә Мәҗлиси үзе хакында берникадәр мәгълүмат биреп уза. Анда ул үз тормышы һәм әсәрен язу сәбәпләрен аңлатып китә.

Мөсафир ирдем дилгири поргайши,
Мөсахипларымыз әманендә тәшвиши.
Юк ирде һәм нишанем гайре аһым,
Ходa булып әйтте дилдари шаһым.
Хыялда аның шәме сәхәр-гяһ,
Йөрәгемдин кан агып, йөз налә-аһ,
Фиракыңда күзем яше корымай,
Йөрер ирдем кичә-көндез оемай...

(*Сүзлекчә:* Ирдем — идем; дилгири поргайши — тормыштан күңеле бизгән; мөсахипларымыз — якын дусларыбыз; әманендә — иминлегендә; тәшвиши — хәсрәтләнгән; нишанем — билгем; гайре аһым — аһ-зардан гайре; дөлдари шаһым — юатучы шаһым; сәхәр-гяһ — иртәкичә; налә-аһ — аһ-зар; фиракында — аерылу утында; корымай — корымый; оемай — йокысыз.)

Алга таба:

Ки нагәһ беркөнне җанан юлыкты,
Бу мескен бәндәгә солтан юлыкты.
Күреште чу җан килеп җисме берлән.
Ки сорды бәндәне бу исме берлән.
Диде, кем, Мәҗлиси, хәлең ничектер,
Фирак утыда әхвәлең ничектер?
Тута бирдем, ачып күрде аны яр,
Укыды, ачылды у багы-гөлзар.
Чу күрде назме пакъ төрки телле ул,
Мәне диваныгра күрсәтте бу юл.
Салып башымга йөз төрлек бу сәүдә,
Төшеп күңелгә мең төрлек гауга,
Чыкарды куеныдин бу дастанны,
Нә дастан ул, мәгәре бер бөстанмы?
Элчендә йөз нәмән гөлләр ачылган,
Ләтафәт бәхредә гөлләр сачылган.
Гайрел-баблар элчендә бисьяр,
Колак тотсаң, гаҗәеп сүзләре бар.
Диде: Кем, Мәҗлиси, бикәри торма,
Ки мән шагыйрьмен диеп лафы орма.
Әгәр булса һөнәр әлеңдә — күрсәт,
Ки бу дәфтәрне төрки телгә төзәт.
Боерды, кем, «Гөлү-Нәүруз» назымен,
Аңа мизан кылыбән назм кылаен!
Чу ярлыг әйтте-салды, китте,
Күңел бу бәхрегә төште-батты.

(*Сүзлекчә:* Нагәһ — көтмәгәндә; җанан — җанаш, җан дус; чу — шул; җисме — тән; сорды — сорады; фирак утыда — аерылышу утында; әхвәлең — хәлләрең; тута — дәфтәр; у — ул; багы-гөлзар — чәчәк бакчасы; чу — шунда; назме пакь төрки — саф төрки (телле) шигырь; мәне — мине; диваныга — сарай хезмәтенә; сәүдә — файда; чыкарды — чыгарды; нә — нинди; бөстанмы — бакчамы; элчендә — эчендә; нәмән — төрле; ләтафәт — хикмәт; бәхредә — диңгезендә; гайре баблар — төрле бүлекләр; бисьяр — бик күп; бикәри — файдасыз; әлендә — кулында; мизан — үлчәү; ярлыг — ярлык, әмер; бәхрегә — диңгезенә.)

Бу тәфсилле юллардан күренгәнчә, Мәҗлиси – мөсафир ул, үз иленнән аерылган, ышанычы Аллаһы тәгаләдә генә икән. Менә аңа җан дусты юлыга һәм, хәлен белешеп, аннан бер дәфтәр кабул итеп ала. Дәфтәрдә саф төрки телдә шигырь бар икән, җитмәсә ул гөлбакча кебек күркәм, ди. Менә бу җан дусты, солтан, куенынннан Мәҗлисигә «Гөлү-Нәүруз» дастанын чыгарып тоттыра һәм аны төрки телгә төзәтеп бирергә әмер итә дә китеп бара. Шагыйрь шушы хыял белән яши башлый, әсәрне язуга тотына.

Бу солтан кем? Автор аны Мәхмүд солтан, ди. Мәҗлиси белән аның арасында булган вакыйгалар күз алдына килеп баса. Алар якын дуслар да булып чыга.

Ул вакытларда солтан титулын йөртү госманлы төрекләренә хас күренеш, Кырым һәм Әстерхан җирлегенә дә үтеп керергә мөмкин, әмма Урта Азиядә хан титулы кулланылган, Бабурга карата да солтан титулы кулланылган булырга мөмкин. Тагын да бер сорау туа торган урын бар. Монда автор белдергән Мәхмүд солтанны Олуг-Мөхәммәд ханның улы, 1445 елдан Казан ханы Мәхмүд (?–1467) дип тә уйларга нигез бар. Билгеле булганча, «Гөлү-Нәүруз» дастанының авторы — Урта Азияле шагыйрь Лотфи (1366 елда Һиратта туган, Дәһикәнарда фәкыйрь тормыш белән яшәгән, берничә дастан авторы), әсәре төрки телендә язылган. Ә төрки дастанны Мәҗлиси өчен кабат төркигә төзәтү кирәк булыр идеме икән? Фарсы яки гарәптән тәрҗемә итсә, бер хәл булыр иде. Димәк, «Гөлү-Нәүруз» дигән вакытта, Мәҗлиси Лотфиның «Гөлү-Нәүруз» дастанын күз алдында тотмый, бәлки монда сүз башка авторның бүтән телдәге, яки фарсыдагы, я гарәпчәдәге әсәре хакында бара дип уйларга кирәк.

Алга таба Мәҗлисидән «Сәйфелмөлек» дастанын каян алганлыгы хакында укып белергә мөмкин. Ул аны фарсы телендәге нәсердән тәрҗемә иткән икән. Ул нәсер «Гөлү-Нәүруз» исеме белән булмадымы дигән сорау туа. Җавап бирүе кыен. Чөнки андый исемдә Сәйфелмөлек сюжетына язылган әсәрнең барлыгы билгеле түгел. Ә сәйфелмөлек сюжеты исә «Мең дә бер кичә» («Әлфү ләйлә вә ләйлә») тупланмаларына кертелгән, аерым-аерым парчалар, экиятләр рәвешендә дә кульязмалары таралган булырга мөмкин.

«Сәйфелмөлек» әсәре Мәҗлиси авторлыгында татарлар арасында кульязма сыйфатында киң таралыш тапкан, 1807 елда Казанда ул бе-

ренче тапкыр бастырылып чыгарылган һәм шуннан соң да күп мәртәбәләр дөнья күргән.

Мәүланә Мәҗлисинең тормыш юлы әлегә кадәр тәмам мәгълүм түгел. Күп кенә галимнәр аның Бабур чорында яшәвен һәм иҗат итүен билгелиләр. Аларга иярсәк, димәк, бу шагыйрь XV гасырның ахырларында XVI йөз башларында гомер иткән. Мәүланә Мәҗлиси дигән исемне үзенә мәҗлесара кеше булганы өчен казанган дип тәкрарлаучылар дә килешергә була. Аның Мәҗлес дигән торак яки шәһәр исеменә нисбәттә алынуы да мөмкин. Андый исемдәге шәһәр, мәсәлән, Дагыстанда хәзер дә бар. Әгәр дә туган төбәге белән бәйле Мәҗлиси тәхәллүсен алса, тумышы белән шуннан булмадымы икән дигән сорау урынлы була. Әмма без аны шулай дип раслый алмыйбыз. Данлыклы дин галимнәре Мөхәммәд-Бәкер Мәҗлисигә (1627–1699) яки аның укытучысы һәм этисе Мөхәммәд-Таки Мәжлисигә шагыйрь Мәүланә Мәҗилисинең катнашы юк дип уйларга кирәк.

«Сәйфелмөлек» әсәреннән чыгып караганда, Мәҗлиси күз алдыбызга олуг һәм мәртәбәле шагыйрь буларак килеп баса. Ул телнең тәмен белеп, вакыйгаларның агышын тоеп, кызыклы һәм мавыктыргыч итеп яза, шуның белән меңнәрнең күңелен яулап ала белә.

Иҗаты. Инде билгеләп узылганча, Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» әсәреннән тыш башка язмалары сакланып калмаган дип исәпләнелә. Шул ук вакытта дастанның язылган елы да мәгълүм түгел. Фәндә аны XVI гасыр башларында язылган дип саныйлар.

Әсәр авторның традицион рәвештә Аллаһы тәгаләгә дан җырлавыннан башланып китә. Әмма шагыйрь мактау белән генә канәгатьләнеп калмый, бәлки үзенә гашыйк уты салуны һәм шулай сөендерүне үтенеп болай ди:

Ходая, Мәҗлисигә гыйшык уты сал,
Ки гыйшык шәмгыдин раушан кыл әхвәл.

(*Сүзлекчә:* Шәмгыдин — шәменнән, утыннан; раушан кыл әхвәл — хәлләремне нурландыр).

Бу шагъри юллары Мәҗлисинең суфи- диндар булуын раслап торалар.

Алга таба автор Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның яраннарына багышлап шактый гына озын касыйдә язып уза, аңа өстәлеп бер «Мөнәҗәт» килә, монда тагын үз хәлен сөйләүне кирәк таба. Болардан соң мәхмүд солтан белән бәйле вакыйгалар сөйләнелеп үтелә:

Риваять кылды ривай асыл сүзне,
Күреп солтан Мәхмүд нәхуш үзене.
Кичә көннәр гаҗәеп итәр булды,
Газары әргавани хайран булды.
Бар иде алдыда ике вәзире,
Ләтафәт берле юк ирде назыйре,
Диде солтан: «Әшүфтәдер мән,
Беләә алмам ничек өлфәттәдер мән
Мәгәр бу госсади сәүдаи булдым,
Бу сәүдә берлә һәм шәйдаи булдым.
Кылың бер кыйсса пәядә нали,
Укып андин замана сөенәли.
Ки мән ишеткән булмагаймын аны,
Ки галәмдә белмәгән булгаймын аны!»

(*Сүзлекчә:* Ривай — хәбәрләр, хикәят сөйләүче; нәхуш үзене — күңелсез үзен; газары әргани — йөзе алсуланып; алдыда — алдында; ләтафәт — хикмәт, киң күңеллелек; назыйре — охшашлыклары; әшүфтәдер мән — кайгыда мин; ничек өлфәттәдер — нинди халәттә, мөнәсәбәттә; госсадин — кайгы-сагыштан; сәүдаи — үзенә бикләнгәнлек, төшенкелеккә бирелү; шәйдаи — мәхәббәттән акылын югалтучы; пәядә нали — күз яшен агызырлык; заманна сөенәли — берара сөенерлек; ки мән — һәм мин.)

Вәзирләреннән шушы рәвешле Мәхмүд солтан бер кыйсса таләп итә һәм, шуны тыңлагач, күңеле утырыр дип уйлый. Алар аңа бер-бер артлы йөз кыйсса тәкъдим итеп карыйлар, әмма солтан боларның берсен дә кабул итми, вәзирләрне зинданга салдыра. Болар ябылуда яткан вакытта дөньяның кайсы якларында тансык хикәятләр барлыгын берәүдән ишетәләр һәм солтан Мәхмүдтән үзләрен шунда җибәрүен үтенәләр.

Вәзирләр ул тарафларны йөреп кайталар. Солтан бу хикәятне кабул итәрме икән дип, аны курка-курка сөйлиләр. Кыйсса аңа бик охшый һәм ул аларга яхшы тун (кием) бүләк итә, күп төрле нигъмәтләр бирә, һәммәсен сөендерә.

Шушы вакыйгаларны сөйләгәннән соң, Мәҗлиси бу вәзирләр китергән кыйссаның фарсы телендә булганлыгын әйтеп уза һәм төрки телгә аны тәрҗемә иткәнлеген яза:

Вә ли у нөсхә фарсы вә нәсер,
Ирер садә хикәят сәррәһум кыср.
Кылыптыр Мәҗлиси бу сүзе пәрваз,
Укысаң, кылыр җан кошыны пәрваз.

(*Сүзлекчә:* Вә ли — һәм дә, әмма; у — ул; фарсы вә нәсер — фарсыча прозада, нәсер; садә хикәят — күңелгә ягымлы хикәят; сүзе — сүзне; җан кошыны пәрваз — җан кошын канатлы итәр.)

Авторның бу бүлекләрдә телгә алынган солтаны реаль шәхес түгелме дигән урынлы сорау туа. Солтан Мәхмүд дип кемне әйтә соң ул? Төрек солтаннанмы, әллә инде Казан ханнарыннанмы? Һәрхәлдә Казан тәхетендә Мәхмүд исемле хан утырган, Олуг-Мөхәммәд уларыннан булып, 1446-1464 елларда идарә иткән. Мәҗлиси сөйләп киткән вакыйгалар да аның белән бәйләнгән дип фараз итәргә мөмкин. Ничек кенә дисәк тә, автор бу бүлекләрне юкка гына язмаган һәм солтан Мәхмүдкә китерелгән ул хикәятне төрки теленә тәрҗемә итәргә алынуын белдергән. Моннан чыгып, Мәҗлисинең Казан җирлегендә иҗат иткәнлеген дә фараз кыла алабыз.

«Сәйфелмөлек» әсәре сюжетка сюжет кысаланып язылган. Шул ук вакытта бер вакыйгалар бетеп, икенчеләре башланып китү генә түгел, бәлки бер-берсенә әллә ни бәйләнеше булмаган, үзләренә аерым сюжет корылмалары да бар. Солтан Мәхмүд турындагы бүлекләр, авторның үзенең хәлләренә караган урыннар һәм әсәрнең каһарманы Сәйфелмөлек вакыйгалары — болар барсы да аерым-аерым, мөстәкыйль сюжетлар, әмма бер-берсен ачыклап килүләре белән бөтенлек тудыралар һәм кысалы дастанны формалаштыралар.

Мәҗлиси үзенең шигъри күңелен былбыл белән чагыштыра. Шул күңел сандугачы тоткынлыкка элэгә һәм читлектә елап, кыйссаны сөйли башлый.

Җиде икълим-тарафны үзенә буйсындырып тоткан Мисыр падишаһы Гасыйм ибне Сафуан бар икән, ул Сөләйман пәйгамбәрнең динешәригатендә, ди. Бу хөкемдарга инде җитмеш (яки йөз җитмеш) яшь икән, әмма баласы юк. Аңа тәхетен калдырыр өчен бер угыл кирәк. Гасыйм ибне Сафуан хәсрәткә кала һәм диван каршына чыкмас була.

Бу халәттә егълап кырык көн шаһ,
Кичә-көндез дога белә чигеп аһ...
Булыбән гөл йөзе чөн кәһребарик,
Сачы йөзгә төшеп черкән гидадик.

(*Сүзлекчә:* Егълап — елап; чөн — чөнки; кәһребарик — сары якут төсендә; сачы — чәче; черкән гидадик — шакшырган теләнченеке кебек.)

Шушы рәвешкә төшеп хәсрәтләнгән солтанны юатырга дип вәзирләре киңәш-табыш кылалар һәм аның янына керәләр, тәхетенә яңадан утыруын үтенәләр, юкса фетнә булыр дип белдерәләр. Аларның киңәше белән солтан үз янына мөнәҗҗәм-йолдызчыларны җыйдыра да язмышын юрарга боера: малае булырмы-юкмы? Болар фал ачалар. Йәмән солтанының кызына өйләнсәң, Аллаһы тәгалә үзеңә бер угыл бүләк итәр дип белдерәләр. Моны ишетеп, падишаһ бик тә сөенә һәм тиз ара яучыларны зур бүләкләр белән кыз соратырга җибәрә.

Йәмән солтанының исеме Баригыль-Гасыр икән. Гасыйм ибне Сафуан аны бик олылап, күкләргә чөеп мактап хат яздыра. Моны укыгач, Йәмән солтаны каршы килми, Аллаһының тәкъдире дип кабул итә.

Кыз бик тә күркәм, ханнарга лаек зат, исеме — Җәмилә. Автор аны сурәтләгәндә шигъри осталыгын һәрьяклап файдалана, йөзен гөлчәчәккә, буен нәзек гөлгә тиңли. Кызны күргән һәркем гашыйк булачагын, үлеләрнең терелэчәген яза:

Буе нәзек, кәле хәдди кәмали,
Ләтафәт бөстанының вә нәһали.
Йөзе гөлбәрг, агызы гончә ирде,

Терелер ирде гаиш дик дәмидин,
Вә ли ахры үләр ирде гамидин.

(*Сүзлекчә:* Кәле хәдди кәмали — бар сызыклары камил; ләтафәт бөстанының — нәфислек гөлбакчасының; нәһали — үсентесе, сабагы; гөлбәрг — гөлчәчәк таҗы; агызы — авызы; гончә ирде — яңа ачылып килүче чәчәк бутоны иде; гаиш дик — тере кебек; дәмидин — аһ итеп; вә ли — һәм дә; ахры — ахырда; гамидин — гаменнән).

Төрле уен коралларын уйнатып, Йәмән солтаны кызын Мисырга озата бара. Күп кешеләр Җәмилә өчен күз яшен коя. Гасыйм ибне Сафуан, кызның китерелүен ишетеп, каршы алырга торып чаба. Ара юлда алар очрашып кавышалар. Гүя җәннәт сакчысы Ризван фәрештә оҗмах шәмен яндырган кебек булып китә, шаһ шушы Җәмиләгә гашыйк икәнлеген яшерә алмый.

Икәүлән яндаши ултырды чауши,
Төшеп солтанга бәчтә ташы чауши.
Өзеп шәфтәлүләрне ләбләредин,
Алып ак алманы гәбгәбләредин,
Замани ултырып нәзарә кылды,
Күңелдин кайгыны аувәрә кылды.
Мәхәббәт шаукы шаһ күңелгә төште,
Түшәге салды, ойкы вакты булды.
Күрең, гончә ачылды шаһ илендә,
Алып киленне, кылыр зәвкъ кулында.
Кушылды ике җанан хуш мөнасип,
Дорре нисьян мөдәфгә булды галип.

(*Сүзлекчә:* Яндаши — янәшә; ултырды — утырды; чауши — дәртләнеп; бәчтә ташы — җенси якынлык ташы; замани ултырып — бераз вакыт утырып; нәзарә кылды — карап торды; аувәрә кылды — куды, төзәтте; ойкы — йокы; илендә — кулында; дорре нисьян — яшерен энҗе; мөдәфгә — кабырчыкка, кашыкка; галип — тоткын.)

Җәмилә белән Гасыйм солтанның озакламый угыллары туа, аңа Сәфелмөлек исеме бирәләр. Атасы үз янына йолдызчы-мөнәҗҗәмнәрен

җыйдыра һәм малайның язмышын юрарга боера. Сәйфелмөлекнең бәхет йолдызын карап, аның галәмне йөреп алачагын, күп кан күрәчәген, күп авырлыклар үтәсен беләләр, әмма ахырда ул үз дигәненә ирешәчәк икән.

Менә шушы рәвештә автор Сәфелмөлекнең язмышын алдан ук билгеләп куя һәм шуның белән укучы күңелендә чыннан да шулай булырмы дигән сорау тудыра, кызыксыну уята. Шушы рәвешле Сәйфелмөлекнең тарихы башланып китә. Шаһ Гасыймның Хәмид исемле вәзиренең дә Сәгыйть исемле улы дөньяга килә. Ике сабый бергә тәрбияләнеп үсәләр һәм бер-берсенә якын, аерылмас дусларга әвереләләр.

Солтан аларга бик затлы итеп сарай төзетә, аны гөлбакча эчендә бизәп-зиннәтләп ясыйлар. Шагыйрь бу бакчасарайның ни рәвешле булганын аерым бер бүлек кысасында сурәтли. Сәйфелмөлек шунда кәеф-сафа корып, рәхәттә яшәп ята.

Менә аңа балигълык яше тула. Көннәрнең берендә әтисе Гасыйм ибне Сафуан улын үзенә чакыртып ала, Сәйфелмөлеккә затлы тун (кием) белән йөзек бүләк итә, вәзирнең улы Сәгыйтькә дәрәҗәле исем, ат бирә. Егетләр моңа бик тә сөенәләр һәм, сарайларына кайтып, бәйрәм ясыйлар, күп итеп шәраб эчәләр, исерешәләр. Шунда Сәйфелмөлек затлы киемне киеп карамакчы була. Төрелгән киемне сүтеп җибәрә. Аның арка ягында төшерелгән кыз сурәтен күреп, Сәйфелмөлек аңа гашыйк була.

Мәҗлиси ул сурәттәге кызны шигъри буяулар белән оста итеп тасвирлый, үзенең затлы каләм иясе икәнлеген тагын бер кат дәлилли:

Бар ирде тунда бер сурәте кеше,
Буй-башдин аяга вә диле кеше.
Йөзенә бакса — гүя ул көләдер,
Аны күргән саен җаны көядер.
Ирер рәңе рухы гөлбәрк тере дик,
Ләбе ләгъле аның ширин шикәр дик...
Кашы йәй дик корылып ук атарга,
Аны күргәндә юк сабыр итәргә...
Буе гөлнең нәһале дик игелер,
Булыр холка сачы гүя чигелер.
Нәһале сәрви дик чөн кадмәүзүн,
Ләбе ләгъле, теше чөн дорре мәкнун.

Күзегә баксаң, күзе сөзелер,
Буе нәзек — мәгәр биле өзелер.

(*Сүзлекчә:* Сурәте кеше — кеше сурәте; аяга — аягына кадәр; диле кеше — җанлы кеше; рәңе рухы гөлбәрк тере дик — төсе-кыяфәте гөлчәчәк кебек тере; ләбе ләгъле — кызыл якут ирене; ширин шикәр дик — татлы шикәр кебек; йәй дик — җәя кебек; нәһале дик — сабагы кебек; игелер — иелер; холка сачы — бөдрә чәче; нәһале сәрви дик — яшь сәрби агачы кебек; чөн кадмәүзүн — чөнки төз буе; чөн дорре мәкнун — чөнки ак энҗе; күзегә — күзенә; сөзелер — текәлеп карар.)

Сәйфелмөлек шушы сурәткә гашыйк була һәм аның иреннәреннән үрелеп үбә, мәхәббәттән сыкрап, аһлар орып елый башлый.

Егетнең эче кайнар казан кебек кайный, йөзе сула, йокысы кача. Иртәгесен дусты кат-кат сорап карый, әмма Сәйфелмөлек сәбәпне әйтми. Бу хәлне ишеткән әти-әнисе дә кайгы-хәсрәт утында калалар, сораштырып карыйлар, әмма сәбәпне алар да белә алмый.

Сәгыйть, үтенеп, Сәйфелмөлектән серне чишүен сорый, белгәч, ул да кызның сурәтен күреп соклана. Ул гүзәлнең исеме Бәдигыль-Җамал икән, Шәһбал кызы, торган урыны — легендар Ирам багы, Ирам бакчасы.

Сәгыйть бу хәбәрне солтанга җиткерә. Шуннан Гасыйм ибне Сафуан шаһ тун һәм йөзекнең үзенә ничек килеп кергәнен бәкләренә сөйли. Аларны Сөләйман пәйгамбәр аңа атап калдырган икән. Диюләр китереп тапшырганнар. Шаһ, тундагы сурәтне күреп, заманында үзе дә андагы гүзәлгә гашыйк булган, әмма ул кызның әлегә дөньяга тумаганлыгын белешкәч аның кенә күңеле тынычлана. Яшь чагыннан өйләнмичә калу сәбәбе дә менә шушының белән бәйләнгән булган икән.

Гасыйм ибне Сафуан бәкләрен җыеп киңәшә һәм дөньяның дүрт тарафына сурәттәге кызны эзләтеп кешеләр җибәрергә була. Аларга бер ел вакыт бирә. Илчеләр киткәч, Сәйфелмөлекнең дә күңеле тынычланып кала һәм элеккечә кәеф-сафада гомерен үткәрүне дәвам итә.

Бәдигыль-Җамалны эзләп киткән илчеләр бер елдан соң кире әйләнеп кайталар, әмма берсе дә кыз хакында хәбәр китерми, андый кешене вә илне белүчеләр юк икән. Моны ишетеп, Сәйфелмөлек тагын сагыш эчендә кала, ахырда үзе эзләп китәргә уйлый һәм атасыннан рөх-

сәт үтенә. Солтан аңа ризалык бирә, дүрт йөз көймә ясаттыра, аларга ризык, гаскәр һәм һәртөрле кирәк-яраклар тутырттырып, озата чыга.

Барча халык елап кала. Автор Сәфелмөлекне лачын белән, аның әтисен читлектән тутый кошын очырган кеше белән тиңли. Шаһзадә йөз чура-коллары белән кәеф-сафа корып, Кытай мәмләкәтенә таба юнәлә. Анда килеп җиткәч тә, ярга төшеп, чатырлар кордыра. Халык курка кала. Барсы да алар хакында сугыш белән килгәннәр дип уйлыйлар. Илчеләр аша Сәйфелмөлек кемне эзләп йөргәнлеген сөйләп бирә. Кытай императоры белән очраша. Халыктан Бәдигыль-Җамал хакында белешәләр. Аны белүчеләр табылмый, бары тик бер карт кына Ирам багының Катыйнә шәһәрендә икәнлеген вә анда бер ел барырга кирәклеген әйтеп бирә. Барча көймәләр белән Сәфелмөлек шунда таба юнәлә. Әмма күкләр бу эшкә көнчелек кылалар, диңгез шаулый, туфан кубарыла һәм көймәләре белән һәммәсе су төбенә китәләр.

Каян баксаң, күзегә ил күренмәс,
Илек салсаң, судин үзгә орылмас.
Орынышып халаикың уйныйдыр,
Мәгәр гүя Кыямәтнең көнедер.
Орынып бер-берегә һәм ватарлар,
Көймәләр, сынып, ил-суга батарлар,
Диделәр, кем, ушал дүрт йөз көймә
Барысы сынды, калмады тәмамә.
Чу булдылар фәна дәрья төбендә,
Күренмәс һичнамә дәрья йөзендә.

(*Сүзлекчә:* Күзегә — күзгә; илек — якорь; судин үзгә — судан башка әйбер; халаикың — халыкларың; ушал — шушы; тәмамә — тәмамы; чу — чөнки; фәна — үлем; һичнамә — һичнәрсә.)

Автор шулай туфан вакыйгасын сөйләп уза. Сәйфелмөлек коллары белән чоңгылда төшә, монда күз яшьләрен коялар, аннары, аннан чыгып, зенки-негрлар кулына тоткын булып төшәләр.

Бу зәнкиләр кан эчүче, кеше ашаучылар икән. Арадан тугызын утта кыздырып ашыйлыр, шәраб эчып, кеше ите белән ризыкланып, болар бәйрәм итә. Сәйфелмөлек белән ике иптәшен зәнкиләр падишаһы үз

кызына җибәрә. Боларны китерүгә, зәнки падишаһы кызының егеткә күңеле төшә.

Күреп шаһзадәне, кыз булды гашыйк,
Барыны күрде бу үзенә лаек.

Бу падишаһның кызы, Сәйфелмөлек янына барып, аны үзенә караткачы була. Китерүче зәнкиләрне җибәргәч, ясана-бизәнә башлый. Мәҗлиси кызның бу хәлен җөпләп-җөпләп сурәтләргә керешә:

Йөзегә сөртебен әүвәл өпәнеч,
Кара йөзгә кара зөлфен куеп печ.
Кара күмер кашыга сөрмә тартып,
Калын кирпеч белә йөзен акартып,
Буены күрсәңез — мисле манара,
Әгәр агзыга баксаң — мисле гарә.
Кара аргамычны кылып чу сач баг,
Куеп начак буенга чу аны чаг,
Кара өй төңлеген әшһаб кылыбән,
Кара чикмәндин чәшбәндә кылыбән,
Кылып бер иске кыснакны беләзек,
Салып ничә кызыл сагырдин өзек.
Чу филнең тырнагы дик тырнагына
Кызыл белән бояды мисле хына,
Йөрер булса, йөрер тивә йөрешен,
Көләр булса, көләр айган көлешен.
Аның һәр имчәгедер мисле сәкка,
Йөресә, өне килер сәкка-сәкка.
Ябылып филе дик ике колагы,
Салынып тивә дик астын дудагы.
Колакларыга салыбән салыначак,
Асырга урныга суган-сарымсак...
Аның һәрбер күзе мисле өзәнге,
Колаклары мәгәр иске тобынгы...
Бу сурәт берлә кылыр ни хыялый,
Йөзем гөлдер, буем тәза нәһали.
Ки бу галәмдә бер мән дик сыным юк,

Пәриләр гашыйктыр, һич гамем юк.
Күрең, мән дик сыным бармы дөньяда?
Мине күрсә, булыр шаһзадә бәндә.

(*Сүзлекчә:* Йөзегә — йөзенә; өпәнеч — кершән, пудра; зөлфен — бөдрәсен; печ — тигезләп, кисеп; кашыга — кашына; гарә — тау тишеге; армагыч — үрмәкүч; чу сач баг — шунда чәч бавы; начак буенга — озын муенына; чаг — чак, асып; әшһаб — саргайтып; чәшбәндә — чәч тасмасы; кыснакны — кыскычны; сагырдин — саранчадан; тивә — дөя; айган — шакал, сыртлан; сәкка — чиләк; сәкка-сәкка — шакышокы; филе дик — фил кебек; астын — аскан; дудагы — ирене; асырга — алка; тәза нәһалы — төз талчыбык; мән дик сыным — минем кебек сын-кыяфәт; бәндә — кол.)

Зәнки кызы, шушы рәвештә хыялланып, Сәйфелмөлек янына керә һәм аны һичшиксез гашыйк иттерәсенә ышана. Әмма егет, моны күрүгә, куркынып, һушын җуя. Падишаһ кызның янындагы кол хатыннары, ул сине күреп, матурлыгыңа сокланудан аңын югалтты, дип сөйлиләр. Зәнки кызы егетне үбәргә итә.

Шаһзадә хисләрен яшерми, кызны яратмаганлыгын әйтә. Зәнки кызының моңа ачуы килеп, Сәйфелмөлеккә авыр газаплы эшләр йөкли, җәберләү аша үзенә каратмакчы итә. Башта куллары кабарганчы ярма тарттыра, хәйлә кылып туктатмакчы булса, кыйната. Ә көндезләрен утын ташыттыра, кичләрен ат карата. Сәйфелмөлек ничә еллар буена шулай күп җәфалар күрә. Әмма кыз аны үтертергә теләми, хәтта кайвакыт, шундый фикергә килеп, әмер бирсә дә, шаһзадәнең йөзен күреп, гыйшкы сәбәпле ул юлга бармаска мәҗбүр, мәхәббәте комачаулый.

Сәйфелмөлек иптәшләре белән моннан качарга уйлый. Алар, утынга баргач, сал ясыйлар һәм кичләрнең берсендә качып китәләр. Яңадан бер утрауга килеп чыгалар. Монда эт башлы, кеше бәдәнле затлар яши икән, үзләре арысланнар кебек ажгырып торалар. Мәйнүн дип йөртәләр аларны. Өчесен дә тотып алып, падишаһларына китерәләр. Мәйнүн шаһы адәм затыннан икән. Гоман шәһәреннән шаһ улы. Гомерен диңгезләрдә йөзеп үткәргән һәм ахырда бу утырауга килеп эләккән. Мәйнүннәр аны падишаһлары итеп куйганнар, кире кайтарып җибәрмәгәннәр. Әгәр дә адәм затыннан үзләренә хан таба алмыйлар икән, ул

вакытта барчасы һәлак булачак, ди. Шулай итеп, Сәйфелмөлек тә аларның падишаһы сыйфатында күтәрелергә тиеш икән.

Эт башлы мәйнүннәрнең олуг ханы үзенең кызын Сәйфелмөлеккә кияүгә алырга боерып хәбәр бирә. Егет чарасыз кала. Аңа кызны китерәләр.

Күрең Сәйфелмөлекнең хәлене сез,
Китерделәр аның алдыга бер кыз.
Бакар шаһзадә бу кызның йөзегә,
Киек дик сискәнеп һәрдәм үзегә.
Күрер бу кыз мәликзадә йөзене,
Киек дик эт мәгәр текте күзене.

(*Сүзлекчә:* Бакар — багар, карар; дик — кебек; һәрдәм — һәрвакыт; текте — текәде.)

Әсәрендә автор Сәйфелмөлекнең кичергән җәфаларын тәфсилләп сурәтли, шуның белән укучының күңелен кузгата.

Сәйфелмөлек бу кыздан курка кала, Гоман шәһәреннән килгән шаһка да зарланып карый, әмма файдасы чыкмый, соңыннан качып китәргә мәҗбүр була.

Дәрьяда йөзеп, алар кабат бер утрауга килеп чыгалар. Төрле җанварлардан күп кенә бәлаләр күреп, моннан да китүргә мәҗбүр булалар. Тагын бер утрауга очрыйлар.

Кич булуга, бу утрау тирәсендәге дәрья суы утлар белән чолгана һәм ул гүяки гөлбакча кебек балкый. Сәйфелмөлек һәм иптәшләре бу хәлдән курка калалар. Таң ата, бу гаҗәп утлар бетә. Болар ул утрауны да ташлап китәләр. Башкасына килеп чыгалар. Җимешләре бик бай урыннар икән. Монда бер елга якын яшиләр, кая барырга да белмиләр. Сәйфелмөлек сагыш утында кала, аһ-зар итә, хәсрәтеннән үзен-үзе белештермичә, сал агачына барып утыра һәм диңгезгә карап, уйда кала. Ул арада салы урыныннан кузгала һәм диңгез-дәрья эченә кереп китә. Утрау күзеннән югала. Сал агачлары таралып, егет суга чума. Шунда бер бүрәнәне тотып, аңа ябыша. Аллаһы тәгаләдән ярдәм үтенә. Һәм менә күктә бер олы кошның очканын күрә. Бу кош Сәйфелмөлекне эләктереп алмакчы була, әмма тырнагына каптыра алмыйча, агачның

бер башына килеп утыра. Егет, форсаттан файдаланып, шунда аягына ябыша. Кош аны үз оясына күтәреп китерә.

Сәйфелмөлек бер аждаһага тап була. Ул егет шулай кош балаларын ашап китә икән. Аның белән сугышып, Сәйфелмөлек җиңүгә ирешә. Аждаһаны үтерә. Тау-таш араларында арыслан-юлбарыслар белән сугышып йөри. Күзеннән күп кайнар яшьләрен түгә. Бер далага килеп чыга. Анда бер сарай күреп, шунда таба юнәлә.

Сарайда йоклап яткан кызга очрый. Уята алмый. Баш астына куелган алтын тактаны алып, моннан чыкса, кыз уянып китә, кире керсә, ул тагын йоклап китә. Бу хәлгә аптырап калган шаһзадә алтын тактаны тышка ыргыта, шуннан соң кыз йокысыннан айный һәм Сәйфелмөлектән курка кала. Алар үзара аңлашалар.

Мәликә исемле кыз икән бу. Бәдигыль-Җамалның сөт карендәше. Алар бергә тәрбияләнеп үскәннәр. Әмма Мәликәне Дию урлап киткән. Үзенә хатыны итеп алмакчы. Әмма кыз риза түгел. Шунлыктан ничә еллар шушы хәлендә тоткынлыкта ята. Дию каядыр чыгып китсә, Мәликәне сихер тактасы белән йоклата да, үз эше белән йөри. Шаһ кызы, аннан котыла алмыйча, азат булуына бөтен өметен өзеп, язмышына буйсынырга әзер.

Диюләрнең иле-йорты Кылзум суы төбендә икән. Мәликәне урлап качкан Дию үзе диюләр солтанының угылы, исеме — шаһ Әсвад. Бәдигыль-Җамал исә — пәри кызы, этисе — Шаһбал Шаһрух, диюләр белән сугышучы мөселман, ди. Бу диюнең җаны дәрья төбендәге бер чокырда, сандык эчендә. Шунлыктан аны һичкем үтерә алмый, бары тик Сөләман пәйгамбәрнең мөһерле йөзеген шул суга орсаң, хикмәт белән сандык аннан чыгарылып, Дию һәлак булачак икән. Шунлыктан Мәликә үзенең кайчан да булса Диюдән азат ителәчәген күз алдына да китермичә, Сәйфелмөлеккә тизрәк китәргә киңәш итә. Әмма шаһзадә үз кулында Сөләйман йөзеге барлыган белдерә. Алар бергә китәләр. Артлырыннан куа чыккан Дию, йөзекне Сәйфелмөлек диңгезгә ташлауга, күкләргә каннары чәчрәп һәлак була. Әмма Сәйфелмөлек белән Мәликә, кая барырга белмичә, дәрья эчендә шактый гомерләрен уздыралар.

Автор аларның газап вә җәберләр күрүләренә һәрдаим озаклап туктала һәм тәфсилле хәбәрләр бирә, шуның белән гариплек, ягъни илйорттан аерылуның нинди авыр сынауларга салуын белдерергә омтыла. Бу аның суфичылык идеяләрен һәм идеалларын өстен куярга омты-

лышыннан да килә. Әсәр дини юнәлеш ала, мәхәббәт дастаны гына түгел, бәлки дини эчтәлектәге поэма буларак та игътибар үзәгенә күтәрелә.

Мәликә белән Сәйфелмөлекне утраудан сәүдәгәрләр алып китәләр. Менә алар Ирам багына кайтып ирешәләр һәм, аларны күргәч, туган-тумачаларының барчасы да бу хәбәрдән сөенә. Мәликәнең атасы Сәрәндил шәһәренең падишаһы икән, ул аларны каршы ала.

Барысы да бәйрәм итәләр. Әмма кызының сафлыгына Мәликәнең әнисе шик белдерә. Шуннан Мәликә барсын да аңлатып бирергә мәҗбүр була:

Тәфәккер кылмаңызлар — сөтдин акмын,
Тәкәллем кылмасыннар — сөтдин пакъмын.
Тәнемгә тигмәде күңләкдин үзгә,
Бу колым тотмады һич йиңдин үзгә.
Йөземгә тигмәде гайре бурнәчәк,
Ләбем ирде һәмишә гончәдин пакь.
Һәмишә габгабем рималы баглыг,
Мәгадәм ирде үлгән кеше яңлыг.
Кылың бавәр бу мескенең сүзене,
Күзем күрмәс ирде намәхрәм йөзене.

(*Сүзлекчә:* Тәфәккер — фикер, уй; тәкәллем — гайбәт; тигмәде — тимәде; күңләкдин үзгә — күлмәктән башка; йиңдин үзгә — җиңнән башка; бурнәчәк — бөркәнчек; ләбем — иренем; бәмишә — һәрдаим; гончәдин — чәчәк таҗыннан; габгабем — ияк астым; рималы баглыг — якам төймәләнгән каплаган; мәгадәм — кире кайтыр; бавәр — ышаныч; намәхрәм — туры карарга тыелган, гөнаһсыз.)

Мәликәнең шушы рәвешле җавап бирүеннән соң барчасы кабаттан сөенәләр, борчулы уйлардан күңелләрен азат итәләр. Мәҗлиси махсус рәвештә бу вакыйганы сурәтләп бирә һәм кызның намусы белән бәйле әхлак мәсьәләләрен өстен чыгара.

Сәйфелмөлек дусты Сәгыйтьне исенә төшерә, аны сагына. Әсәрдә алга таба шушының белән бәйле вакыйгалар башланып китә. Автор бу урында егетнең такмаклап елавын сурәтләп уза һәм сүзләрнең кабатланып баруы белән шаһзадәнең хәсрәтен үтемле итеп тасвир кыла.

Хәтта Бәдигыль-Җамалга гыйшкын да Мәҗлиси бу кадәр үк тәфсилле сурәтләми кебек. Аның сәбәбе авторның мәхәббәттән дуслыкны, ирләрнең үзара берсен-берсе суфиларча якын күрүләрен өстен куюыннан килә дияргә була.

Җан дусты Сәгыйтьне сагынып, Сәйфелмөлек бу рәвешле такмаклап елый:

Саләм, и яр вә җани миһербани.
Сәлам, и миһербани җавидани.
Сәлам, и кот, рухи рәвани,
Сәлам, и дилбәри җаны җиһани.
Сәлам, и миһербани дилнәвазым,
Сәлам, и бөстаны сәрвиназым.
Сәлам, и лалә руи гөлгезарым,
Сәлам, и кот багы нәваниһалым.
Мәңа сәнсез бу эчкәннәр кызыл кан,
Мәңә сәнсез ачыг ирер сөчек җан.
Мәңа сәнсез газап ирер бу рәхәт,
Мәңа сәнсез йөрәктә мең җәрәхәт.
Мәңә сәнсез хәрам ирер бу сөхбәт,
Мәңа сәнсез мөсибәттер мәгыйшәт,
Мәңа сәнсез мәгыйшәтләр мәшәкать,
Мәңә сәнсез бу сохбәтләр чук михнәт.
Сәнең хәлеңне белмәдем, и дус,
Сәнең кайгыңдин айрылмадым, и дус.

(*Сүзлекчә:* Җани миһербаным — миһербанлы җаным: җавидани — гомер бакый; рухи рәвани — чыгар җаным; дилбәри җаны җиһани — сөекле җан-җиһаным; бөстаны сәрви — гөлбакчаның зыйфа буйлы агачы; лалә руи — лалә йөзле; гөлгезарем — гөлбакчам; кот багы — күңел бакчасы; нәваниһалым — якты гөлем; мәңа — миңа; сәнсез — синсез; ачыг — ачы; сөчек — татлы; мөсибәттер — бәхетсезлек; мәгыйшәт — яшәеш; чук — күп; сәнең — синең.)

Мәликә шаһзадәнең бу сүзләрен ишетеп килә, сагышларын тарату өчен аңа ауга чыгарга киңәш бирә. Сәйфелмөлек аның киңәшен тота.

Ауга барган җирендә Сәгыйтькә охшашлы берәүне күрә һәм аны сараена илтергә әмер бирә.

Бу кеше чыннан да Сәгыйть булып чыга. Аны тотып алалар һәм, төрле җәзалар күрсәтеп, зинданга ябып куялар, чөнки Сәйфелмөлек ни өчен бу егетне тотарга кушканын әйтмәгән.

Гариплекдин яман эш бармы икән,
Гарипкә миһербан эш бармы икән, —

дип белдерә Мәҗлиси, Сәгыйтьнең газапларга калганлыгын сурәтләп, һәм үзе хакында болай ди:

Гариптер Мәҗлиси, азары кылман,
Сынык күңлен тәкый әфкари кылман.
Әгәр һәркем гарипнең күңлен алыр,
Табар ахыр, савабымыздин алыр.

(*Сүзлекчә:* Азары кылман — зарлы кылма, интектермә; әфкари — фикерле, уйлы; савабымыздин — савабыбыздан).

Аудан кайткан Сәйфелмөлек, исеренә төшергәч, Сәгыйтьне таләп итә. Аның туфракка болганган чәч-башын күреп аһлар ора, алар берберсен танып елашалар. Икесе дә бер үк юллар йөреп, бер төрле җәбер-җәфаларны күргәннәр икән һәм менә Сәгыйть, дусты Сәйфелмөлек хакында ишетеп, бу шәһәргә килгән. Алар сарайда торып калалар.

Мәликәнең азат булуын ишеткәч, Бәдигыль-Җамал аның хәлен белешергә килә. Алар сөенешеп елашалар. Мәликә аңа Сәйфелмөлек белән күрешергә киңәш итә, әмма Бәдигыль-Җамал теләми, ачулана. Бервакыт Мәликә йоклап китә.

Сәйфелмөлек чура-яраннары белән мәй эчеп, күңел ачып утыра икән. Бакчага чыккан Бәдигыль-Җамал шаһзадәнең чатырына килә, егетне күреп гашыйк була, һушыннан китеп егыла. Бакчага йокыдан айнып чыккан Сәйфелмөлек шунда Бәдигыль-Җамалны күреп ала һәм алар кавышалар.

Моннан соң бер-бер артлы вакыйгалар тезмәсе уза. Мәликә, Сәйфелмөлек белән сөйләшеп, Бәдигыль-Җамалга аны кавыштыралар. Бу хәлне ишеткән инәкәсе, ягъни сөт анасы, Сәйфелмөлекне кызның олуг

анасына, ягъни әтисенең әнисенә алып бара, ул аны Шаһбалга китерә. Бераз вакытка Ирам бакчасында калдырып тора. Үтеп баручы диюләр Сәйфелмөлекне танып алалар. Алар шаһзадәне күптән эзләп йөргәннәр икән. Кылзум падишаһының улы Әсвадны үтергәне өчен һәлак итәргә исәпләре. Сәйфелмөлекне Кылзум төбендәге зинданга салалар.

Бу хәбәрене ишеткәч, Бәдигыль-Җамал елый. Әтисе киявен коткарырга гаскәр кубара. Диюләр белән пәриләр канга батып сугышалар. Кылзум шаһы җиңелә. Сәйфелмөлекне азат итәргә мәҗбүр була.

Шаһзадә белән Бәдигыль-Җамал туй итәләр. Автор бу вакыйгаларны каһарманнарының мәхәббәт хисләре белән бәйләп яза. Сәйфелмөлек теләгенә ирешә, күңеле тынычлана.

Кичә-көндез кочаклашмак-сөйләшмәк,
Илекләрен тотышып һәм үбешмәк.
Морадыга йитешеп күңле тынды,
Фәләк, күреп, оятдин буйны сынды, —

(*Сүзлекчә:* Илекләрен — кулларын; йитешеп — җитеп; фәлак — күкләр; буйны сынды — буе сынды, буйсынды.)

дип яза Мәҗлиси бу вакыйгалар хакында.

Сәйфелмөлек, сөйгәне Бәдигыль-җамал белән кавышканнан соң, дусты Сәгыйтькә Мәликәне ярәштерә. Алар да, морадларына ирешеп, мәхәббәт белән кавышалар һәм яратышып тора башлыйлар. Әмма алар әлегә, ни кадәр генә үзләрен бәхетле сизмәсеннәр, туган илләреннән, эти-әниләреннән еракта икән. Сәйфелмөлек Мисыр иле һәм этиәнисе хакында уйлый, кайтып аларны күрәсе килә. Аның бу сагышын барысы да аңлый. Очкыч тәхетләр китереп, гашыйкларны шунда утырталар һәм Мисырга илтәләр.

Җәмилә белән шаһ Гасыйм, улларының кайтканын ишетеп, каршы алырга йөгерәләр. Очрашалар, Сәйфелмөлек һәм Сәгыйтьне сөйгәннәре белән бергә күреп, һәммәсе дә сөенәләр, олы туйлар була. Шуның белән «Сәйфелмөлек» әсәренең сюжеты тәмамлана.

Җәфа чикми кешегә рәхәт булмас,
Әгәр көймәс утынга чушы булмас.
Чу диһкан чикмәсә җөвре-җәфасын,

Йимешләрен кеше күрмәс вафасын.
Ходая, барчага лаек юлыктыр,
Мәхәббәт юлында садыйк юлыктыр.
җиһанда җәберләр гашыйк өчендер,
Вә ли белгел: улар лаек өчендер.

(*Сүзлекчә:* Чушы — төтене; чө — чөнки; диһкан — игенче; җөвре-җәфасын — җәбер-җәфасын; садыйк — якын дус; вә ли — һәм дә; улар — алар.)

Алга таба Мәҗлиси бу әсәрен язуы турында һәм үзе хакында мәгълүматлар китерә, әмма үзенең кемлеген, тәрҗемәи хәленнән канәгатьләнерлек тулы хәбәрләр бирми. Шунда «Сәйфелмөлек» дастаны тәмамалана.

Йомгак: 1. Мәҗлиси фәндә XV гасыр ахырында һәм XVI йөз башыларында яшәп иҗат иткән олуг шагыйрьләрнең берсе дип исәпләнелә. Аның тормышы Идел буйлары һәм Урта Азия белән бәйләнгән, диләр. Әсәрдә телгә алынган Мәхмүд солтан белән Казан ханы Мәхмүдәк икесе бер шәхес булса кирәк. Бу мәсьәлә алга таба тикшеренүләрне таләп итә.

2. «Сәйфелмөлек» дастаны мәхәббәт сюжетына корылган, кысалы кыйссалар төркемендә карала торган, суфичылык идеялары белән ныгытылган шигъри әсәр.

САЙАДИ
(XV–XVI йөзләр)

Татар халык теленә «Таһир-Зөһрә дастаны» дип кергән, кайвакытта «Таһир белән Зөһрә кыйссасы» дип аталып йөртелгән данлыклы «Дастаны Бабахан» яки «Бабахан дастаны» әсәренең авторы — Кылыч Сайади. Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» дастаны кебек үк эчкерсез мәхәббәт вакыйгаларына багышланган булуы белән тарихи-әдәби әһәмияткә ия.

Тормышы. Сайадиның кайда, кайчан туганлыгы, биографиясе фәнгә хәзергә кадәр мәгълүм түгел. Моның сәбәбе гыйльми чыганакларның җитәрлек кадәр өйрәнелмәвеннән һәм дә авторның борынгы кульязмалары табылмавыннан гына шулай. Әмма киләчәктә фән үсеше боларга тулы ачыклык кертер дип ышанырга кирәк.

Сайадины XIV гасыр ахыры, XV йөз башы шагыйрьләре хисабына да кертәләр, XVI гасырның беренче чирегенә дә кайтарып калдыралар. Аның иҗатында Кол Гали, Котб, Мәҗлиси кебек авторларның әсәрләрендәге каһарманнар да телгә алына, сөю-сәгадәт мәсьәләсе Көнчыгыш әдәбиятлары традициясендә мифик дәрәҗәгә җиткерелә, шул ук вакытта дини юнәлеш тә саклана, фикерләвендә суфичылык идеологиясе дәвам иттерелә.

Шагыйрь хакында башка мәгълүматлар табылмау сәбәпле, без аның «Дастаны Бабахан» әсәренә таянып, аз булса да тормышы хакында белем туплый алабыз. Дастанның башлангыч өлештә китерелгән мөнәҗәтеннән күренгәнчә, Сайади гомерен ялгызлыкта үткәргән, аның балалары булмаган. Ул бу хакта ачынып яза:

Адәмнең баласы фәрзәнд имеш, дирләр бу дөньяда,
Минең, кем, юктыр фәрзәндем, корык тәнмен ки, җаным юк!
Кешенең булса фәрзәнде, аның эшләре самандыр,
Минең мөлкемдә, и дуслар, ки бер җан җиһаным юктыр.
Сайади сәр нобәһандыр, догасы дәрткә дәрмандыр,
Эчемдә йөз мең армандыр ки, бер фәрзәнд җаным юктыр.

(*Сүзлекчә:* Мивәсе — җимеше; фәрзәнд — бала; дирләр — диләр; корык тәнмен — буш-коры тән мин; самандыр — тыныч, имин; сәр нобәһандыр — изгеләр, серләрне белүчеләрнең шәехе, башлыгы; армандыр — көчле теләк; фәрзәнд җаным — бала җаным).

Авторның шушы рәвешле үз трагедиясе белән әсәрендә сурәтләнелгән геройларның хәлен тәңгәл куюы укучының алдан ук күңелен кузгата, бу охшашалык әсәрнең идея-эчтәлеген ачыклауда әһәмиятле роль уйный башлый. Моннан чыгып, хәтта авторның ни өчен бу әсәрне язуга керешүен дә күзалларга мөмкинлек туа: димәк, шагыйр үзенең баласын да, әгәр дә ул туа икән, Таһир һәм Зөһрә төсле итеп белергә тели, әмма аларның язмышы трагик булмаячак, чөнки Сайади өчен бала — үз җаны белән бер, аны кимсетә, аңа бәла китерә алмый ул.

Татар тарихы өчен бу трагедияне Шәехгали хан һәм аның хатыны Фатыйма ханбикә кичергәнлеге яхшы мәгълүм. Моны искә алганда, мөгаен «Дастаны Бабахан» Касыйм җирлегендә барлыкка килгәндер дигән фараз күңелгә килә.

Кол Гали, Мәҗлиси һәм Кылыч Сайадиларны бер үк әдәби мәктәп юнәлешен тотучылар итеп карарга кирәк. Бу, шул ук вакытта, тема берлегеннән дә килергә мөмкин. Дини эчтәлек белән үтәдән-үтә сугарылган үгет-нәсыйхәт шигъриятендә дә нәкъ шундый күренешкә тап булабыз. Димәк, тема һәм эчтәлек үзенә бәйле сурәтләү чараларын да таләп итә икән.

Сайади «Дастаны Бабахан» әсәрендә татар атамасын аерым халыкка карата куллана. Татар шәһәре, татар иле, татар ханы рәвешендә вакыйгаларны конкретлаштырып, автор үзен дә шул кавем вә йорт кешесеннән булганлыгына басым ясап күрсәтәдер дигән фикер туа. Әмма бу очракта татар дип белдерүе кайсы халыкка карый? Аксак Тимер гаскәрләрен дә татар исеме белән йөрткәннәр. Татар кабиләсенең Нух пәйгамбәр улы Яфәснең балаларыннан булганлыгы да риваятьләрдән мәгълүм. Борынгы Җиде-Су (Баласагун) төркиләрнең татар исемен йөртеп, бу төбәкләр дә Татарстан рәвешендә аталганлыгы тарихлардан мәгълүм факт икәнлеген искә төшереп үтәргә кирәк. Әмма, гасырлар үтеп, шушы ук кушаматны без инде башка урында, Идел-Урал, Кырым, Көнбатыш Себер, Алтай җирләрендә сибелеп яшәүче төркиләр өчен үзаталыш сыйфатында күрәбез.

Татар исемен сәлҗүкләр, госманлылар, гарәпләр, руслар Чыңгыз белән тиңләштереп күзаллауны XIV гасыр ахырыннан башлыйлар. Әмма алар бу атама астында моголларны да күз алдында тотканнар. XV гасыр ахырларында Урта Азия төркиләрен татар дип бик сирәк атаганнар, ә бу исем Кырым, Казан, Себер, Әстерхан төркиләре аталышы сыйфатында тотрыклы булып урнаша башлаган һәм ул атама аларга ябышып калган. Алтын Урданың төп халкын кыпчаклар тәшкил иткәннәр, шунлыктан бу дәүләтне икенче төрле исемдә дә, ягъни Дәште-Кыпчак, Кыпчак Даласы рәвешендә дә атап йөрткәннәр. Шулай итеп, татар дигән вакытта урта гасырларда асылда кыпчак кавемен күзаллаганнар диярге мөмкин. Халкыбыз арасында, риваять буларак, бу дастан вакыйгалары электән таралган булырга тиеш һәм автор, моны яхшы белгән диярге ныклы җирлек бар. Димәк, бу әсәр элгәре халкыбыз тарафыннан иҗат ителгән, фольклор вариантында йөргән һәм Кылыч Сайади аны шигырьгә салучы әдип буларак танылган.

Турыдан-туры халыкыбыз тормышыннан алынган вакыйгалар белән борынгы вә урта гасырлар чоры әдәбиятыбыз бик мактана алмый. Гарәп һәм фарсыдан кергән сюжетлар шактый күп булса да, халыкның

үз иҗатына таяну күренешен олуг дастан дәрәҗәсендәге әсәрне без беренчеләрдән булып Сайади иҗатында очрашабыз. Моннан тагын да бер фикергә куәтләү таба алабыз: автор һичшиксез татар халык иҗаты белән якыннан таныш булган, төрки-татар телен яхшы белгән, шуңа күрә дә тиңдәшсез әсәр иҗат итә алган.

Саяд шәһәре Әму-дәрья буенда урнашкан, ул Харәзм төбәгенә карый. «Дастаны Бабахан» әсәренең авторы үзенә әдәби тәхәллүсне шул шәһәр белән бәйләнеше булган өчен Сайади дип алмадымы икән дигән версия дә фәндә тотрыклы урын алып тора.

Иҗаты. Сайадиның «Дастаны Бабахан»ы — Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәт вакыйгаларына багышланган шигъри дастаны, аның сакланып калган иң тулы нөсхәсе 1703 бәеттән гыйбарәт. Аны Бибигамбәр күчермәсе дип йөртәләр. Ул кульязма 1818 елда Куян авылы Йосыф мулла кызы Бибигамбәр тарафыннан күчерелгән, Петербургның Шәрыкны өйрәнү институты кулъязмалар бүлегендә саклана. Төпләнмәнең ахырында «фи вактил-гасри тарихыл-Һиҗрәти 1414» («Һиҗри тарихы белән вакыт гасыры 1414») дип куелган. Әмма бу дата аңлашылып җитми, чөнки Һиҗри белән күрсәтелгән бу 1414 ел Милади гасыр исәбендә 1993 нче елда гына иреште. Шушы «Һиҗри белән 1414 ел» дигәне хәзерге көнгә кадәр фәндә чишелмәгән мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә.

«Дастаны Бабахан» кулъязмалары әле бүгенге көндә дә табылгалап тора.

Айа дуслар, ишетең бер хикәят,
Эчендә сүзләре бар биниһаять.
Бабахан дигән әүвәл бер шаһ бар ирде,
Аның шәһренең шәһре Татар ирде, —

(*Сүзлекчә:* Айа — ай-һай; биниһаять — чиксез; шәһренең шәһре — шәһәренең шәһәре, иленең башкаласы).

дип әкияти тасвирда башланып китә дастан.

Бу Бабахан бик гайрәтле булып, дошманнарын һәрдаим җинеп килгән, баһадирлары да күп икән, Аллаһы тәгалә дә чын яры, аңа дусты икән. Әмма ханның бер хәсрәте бар: баласы булмау аркасында күп елый ул. Баһир исемле вәзир һәрвакыт ханның киңәшчесе, кайгы хәс-

рәтен уртаклашучы икән. Бабаханның хәсрәте аның хәсрәтенә, Бабаханның кайгысы аның кайгысына әверелә.

Икәве шул әләмдә егълады күп,
Күзене яше берлә йөзен юып.

(*Сүзлекчә:* Әләмдә — рәнҗүдә; егълады — елады; күзене — күзенең.)

Хан кебек үк Баһир вәзир дә бала тели. Күп кенә догалар вә мөнәҗәтләр укып, юунып, йокыга тала һәм төш күрә: имеш, Бабахан белән бергә Хода тәгалә каршына киләләр. Аларның теләкләрен Аллаһы кабул кыла.
Бу төшен вәзир шунда ук хана барып сөйли, Бабахан урыныннан чәчрәп куба һәм сөенеченнән Баһирның кулыннан тота, үбә.

Диде солтан: «Хода фәрзәнде бирсә,
Аның берлә күңел хөрсәнде булса,
Угыл булса — икәве дус булсын,
Икәве бер тән, бер бүст булсын.
Икәве бер-бериләрегә мәхрәм,
Ки булсыннар бу шәһәр эчендә мәрһәм.
җгәр кыз булсалар, булсын дөкәнә,
Бер-берегә булгайлар жанакә!»

(*Сүзлекчә:* Фәрзәнде — бала; хөрсәнде — канәгать; бүст булсын — сөекле булсын, яратылсын, сөелсен; бер-бериләргә — бер— берсенә; мәхрәм — төрле җенестән; мәрһәм — ир белән хатын; дөкәнә — тигез-тиң; җанакә — җан дуслар.)

Бабахан шушы рәвешле шарт куя, икесе дә моның белән килешәләр, хан аңа сүз бирә һәм менә аның баласы туа. Сайади, ай-көн үтеп, гончә-чәчәк тажы ачылды, шаһ сөтенә эүҗе-мәрҗән чәчелде дип, шагыйранә рәвештә вакыйгаларны тасвир итә. Бабаханның кызы гаҗәеп чибәр булып туа, халык аны шуүга күрә Зөһрә исеме белән атый.

Үзе гөл дәк иде, агызы — гончә,
Ки күргән җан бирердәй сөйләгенчә.

Ләбе ләгыль, теше дорданә ирде,
Ки күрсәң — торфә бер җанәнә ирде.
Йөзенең кызылы җәннәт гөле дәк,
Рухы мисле Ирамның былбылы дәк.
Каләм дәк кашы, йөзе мисле әнвәр,
Күзене раушаны манәндә гәүһәр.
Кыя бармак белән җанын аладыр,
Кеше күрсә, үзен утка саладыр.

(*Сүзлекчә:* Дәк — кебек; агызы — авызы; гончә — ачылып килүче чәчәк; күргән — күрүче; ләбе ләгыль — ирене кызыл якут; дорданә — ак энҗе; торфә бер җананә — гаҗәеп бер гүзәл; мисле — мисал, гүя; мисле әнвәр — нур чыганагы төсле; күзене раушаны — күзенең нуры; манәндә — гүя ки; кыя бармак — үткен бармак.)

Сайади Зөһрәнең гүзәллеген шушы рәвешле сурәтли һәм укучы күңелендә аңа карата мәхәббәт хисләрен уята. Бу бала һичшиксез бәхетле булырга тиеш, чөнки гүзәл затка кайгы-сагышлар тиң түгел кебек. Әмма... әмма кызның атасы Бабахан солтан, хан кызы шаһзадәләргә генә лаеклы дип, вәзире Баһирга биргән антыннан кире кайтырга ниятләп куя һәм болай уйлый:

«Угыл бирсә аңа, бер фикер итәрмен,
Ятимдер ки, башыга мән йитәрмен!»

Шулай итеп солтан сүзеннән кире кайта, вәзирнең улы туса, башына җитәргә дип күңеленә беркетә.

Баһирның бик тә матур, Мөхәммәт пәйгамбәрнең йөз нуры чагылган чибәр улы дөньяга килә. Исемен Таһир дип куялар, яхшы-яхшы сөт аналарына тәрбиягә тапшыралар. Әмма, улына биш яшь тулгач, атасы үлеп китә. Ә хан бу хәбәрне ишетеп сөенә.

Ки Баһирның вафатын белде ул шаһ,
Диде ки: «Бу ирер кодрәте Аллаһ!»
Үз-үзедин әйтер: «Шаһ ирермен,
Ки бу татар илегә хан ирермен!»

Бабаханның асылы нинди булуын шулай автор ачып бирә, аның күңел каралыгын күрсәтә. Ул әгәр дә вәзиргә, ягъни кара угылына кода булса, аннан хакан иле көләчәк икән. Менә ул шушы «бәла»дән котылган. Автор хан авызыннан «хакан иледин тартгым әһанәт» («хакан иленнән хурланам») дип сөйләткәндә Бабаханның кечек ханнардан булганлыгын ассызыклап үтә. Димәк, вакыйга олуг ханга буйсынган ханлыкларның берсендә бара. Алтын Урда да шул рәвештә административ яктан олуг ханлык вә кечек ханлыклардан торган, олуг хан, яки хакан мәмләкәт белән идарә иткән, кечек ханнар аерым төбәк, ханлыкта үз фәрманнарын йөрткәннәр. Мәгәре шулай булгая, димәк, Бабахан кечек ханнарның берсе саналып, тарихи шәхес тә булып чыгарга бик мөмкин.

Таһир белән Зөһрәне бер үк мәктәпкә укырга бирәләр. Алар монда Коръән өйрәнә, әмма күп вакыт бер-берсен күзләп утыралар, мәктәп аларның шигырь яза торган урынына әверелеп китә, Зөһрәгә атап Таһир бер газәл укый һәм үзенең мәхәббәтен белдерә. Зөһрә дә сөю утында көя башлый, бу хәлләрне барча халык белеп тора. Көннәрнең берендә Таһирга бер диндар хатын очрый һәм гарипләр догасына колак салуны үтенә. Таһир ашык (туп) уйнап килә икән, ул аны бу диндар хатын ягына очыра һәм ашык аңа барып тия. Шунда Таһирга ул гарибә хатын Зөһрә белән шаярырга куша, минем белән уйнама, ди. Аның ни өчен алай дип әйткәнен Таһир белергә тели, әмма хатын әйтми, үз әнисеннән сорарга куша.

Таһир өенә кайта, кыздырылган бодай ашыйсым килә дигән сәбәп белән әнисеннән ашлык куырта. Ул тагын да, синең учыңнан кабасым килә, дип белдерә. Әнисе кыздырылган бодайны учына ала. Таһир хәйлә уйлап куйган икән. Кайнар бодай бөртекләрен учлаган әнкәсенең кулы пешә һәм гарибә хатын күздә тоткан серләрне улына сөйләп бирергә мәҗбүр була, әмма, Зөһрә — хан кызы, син аңа тиң була алмыйсың дип үгетли.

Шуннан соң Таһир сагышка чума, мәктәпкә барып, кулына тамбур тотып, мәхәббәт шигырьләрен укый башлый. Шуннан остасы аңа киңәшләрен бирә, бары тик Зөһрә аркасында гына тынычлыгың югалсын, ди. Ә Зөһрәгә исә Таһир хәлен белешергә куша. Алар икесе дә гашыйк утыннан көяләр. Таһирга карата булган сөю хисләрен яшерә алмаган Зөһрә дә шунда газәл укый.

Менә ике яр күркәм бакча почмагында очрашалар. Таһир үз әнисеннән ишеткән хәбәрне Зөһрәгә сөйләп бирә, мәхәббәтен аңлата һәм соңыннан бер газәл укый. Аңа җавабында Зөһрә, әтием антыннан кире кайтса да, мин сүздән чыкмыйм, дип белдерә һәм үзләрен Ләйлә белән Мәҗнүнгә тиңли.

Аларның шушы рәвешендә утырганнарын бакча эчендә бакчачы күреп ала һәм Бабаханга әләкләргә йөгерә, газәл әйтеп, солтанга хәбәрне җиткерә. Моны ишетүгә, хан Таһирны чакыртып кеше җибәрә. Үзен дәшүләренә каршы Таһир Зөһрәне бакча гөле белән тиңли һәм үзен былбылы дип белдерә, үзара гашыйк җаннар икәнлеген тәкрарлый. Шунда Зөһрә сөйгәненә атасын барып күрергә һәм хәлләрдән хәбәр бирергә киңәш итә. Таһир аңа күнә һәм, Бабахан каршына колы кебек йөгереп килеп, кулын күкрәгенә куеп, бәндә кебек баш иеп тыңлап тора.

Бабахан сорды Таһирдин сөален,
Бу һәм белгәнене бирде җавабын.

(*Сүзлекчә:* Сорды — сорады; сөален — соравын.)

Солтан шушы сөйләшүдә Таһирның Зөһрәгә тиң түгеллеген белдерә, кызын — падишаһ, аның колы булуын егеткә танырга киңәш итә.

Бабахан каршында егет җавап тота һәм әтисе Баһирга солтанның нинди вәгъдә биргәнлеген сөйли, сүзенең ахырында бер газәл укый, анда үзенең йөрәк серләрен падишаһка белдерә:

Бу җодалык хәсрәтендин йөрәгем кандыр, шаһым,
Безгә — хәсрәт, сезгә — һәмдәм рәхәте җандыр, шаһым.
...Хасыйле гомрең ирер, белдек, бу Зөһрә назәнин,
Суырдык аның ләбләрен, ләгъле Бәдәхшандыр, шаһым.
Падишаһым, яр илән эчтек бу һәмдә бадәне,
Хаһи үлтер, хаһи көйдер, җаны корбандыр, шаһым...

(*Сүзлекчә:* Җодалык — аерылышу; һәмдәм рәхәте җандыр — җан рәхәте юлдаш; ләбләрен — иреннәрен; ләгъле Бәдәхшандыр — Бәдәхшан якуты; илән — белән; һәмдә бадәне — кайгы шәрабын; хаһи — теләсәң; үлтер — үтер; җаны корбандыр — җаным корбан.)

Солтан каршына Таһирның әнисе шаһ Хубан килә, ул да ханнар нәселеннән икән. Бабаханга улын кимсетмәвен үтенә һәм ире Баһирга шушы ханның биргән сүзен искәртә. Шуннан соң бер газәл әйтә, гомернең тиз үтүчән икәнлеген сөйли, Таһир белән Зөһрәне аермавын үтенә, мәхәббәт дастаннарында макталган Ләйлә белән Мәҗнүн, Сәгыйть белән Мәликә, Сәйфелмөлек белән Бәдигыль-Җамал, Хөсрәү, Фәрһад, Вамык, Йосыфлар язмышын искәртә.

Әмма хан аның сүзенә колак та салмый, Таһирдан ничек булса да котылырга уйлый. Сандык ясатып, егетне шунда бикләтә, әнисенең һәм Зөһрәнең, бәкләрнең аһ-зарларына күңел бирми, игътибар итми, үтенечләрен тыңламый, дәрьяга ыргыттыра. Таһир, газап вә җәберләр күреп, сандык эчендә йөзеп барганда, аны ике кошка күреп алалар һәм аны үз оялары торган җиргә күтәреп очалар, агач башында эленгән хәлендә калдыралар. Егет шунда язмышының авыр булуына тагын Аллаһыга зарлана, ярдәм үтенә, җилдән Зөһрәгә сәлам җиткерүен һәм хәленнән хәбәр бирүен үтенә.

Менә яз китерүче җил исеп куя. Таһир, кош оясында тоткын булуга караганда, дәрья эчендә йөзеп йөрүне өстенрәк күреп, сандыкны суга төшерүен җилдән сорый. Көчле җил күтәрелеп, кош оясы торган агачның башын идерә, сандык кабат дәрьяга килеп төшә һәм йөзеп китә.

Багдад падишаһының Маһым исемле бик чибәр кызы бар икән. Ул төш күрә. Төшендә ул шаһзадә белән сөйләшеп утыра, аннан кай тараф егете булуын, нәселен, кемнең яры икәнлеген сораштыра. Егет аңа җавабында үзенең Таһир исемле булуын, Татар шәһәреннән мөсафир икәнлеген, әмма монда килүем сиңа җәбер-җәфа гына китерәчәк дип белдерә.

Маһым йокысыннан уянып китә, елый, тәрбиячесенә төшен сөйли. Юраган вакытта тәрбиячесе бу егетнең чыннан да киләчәген, әмма Маһымның күңеленә газап салып китәчәген аңлата. Таһирның яшәгән җире Багдадтан Көнчыгыш тарафында икән.

Сандыктагы Таһирны дәрья Багдад тарафына китерә һәм падишаһның бакчасы янына чыгара. Монда аны кызлар күреп алалар һәм тоталар. Сандыкны беренче булып падишаһның кече кызы Шәһри күреп, апаларына әйтә, Маһым аны чыгырырга кирәк, ди. Җиһангиз исемле кызның арада чәче бик озын икән. Сандыкны аның толымнарына бәйләп тартып чыгаралар. Йозагын ваталар. Маһым шунда аһ итә:

Күрәр — төшендә күргән маһы пикәр,
Йөзе багның гөле, ләбләре шәкәр.

(*Сүзлекчә:* Маһы пикәр — гүзәл, ай шикелле нурлы; багның — бакчаның; ләбләре шәкәр — иреннәре шикәр).

Кызлар барсы да Таһирның матурлыгыннан таң калалар һәм аның сандыкка ничек килеп кергәнен, кайдан килгәнен сорыйлар. Ул барысын да аңлатып бирә:

Кулымны һәм аягым бәгладылар,
Мәне гамь уты эчрә дагладылар.
Алып китте алар мине күтәреп,
Ки бер мәнзилгә куйды мине илтеп.
Шуны белдем ки, сандыкка салып,
Мәне ташлап суга, үзләре калып,
Күзем ачтым ирсә, бер яхшы сандык,
Ки йите алма, үзгә нимә шәй юк.
Аның кашыда һәм йите йотым су,
Мәни бичара колның кыйсмәте бу.

(*Сүзлекчә:* Багладылар — бәйләделәр; мәне — мине; эчрә дагладылар — эченә мөһерләделәр, яптылар; мәнзилгә — урынга; йите — җиде, җитлеккән; үзгә нимә шәй — башка әйбер; кашыда — янында, каршында; мәни — минем кебек; кыйсмәте — өлеше, язмышы.)

Таһирны Багдадта бик олылап каршы алалар һәм аңа туй әзерлиләр, никахлап Маһымга өйләндерәләр.

Менә кыз белән егетне бергә калдырып китәләр. Маһым шунда Таһирга ни өчен кияүгә чыгуын аңлата, ул, аны күреп, намусын югалткан, гашыйк булган, шуның аркасында халыкта бик күп гайбәтләр таралган икән.

Әмма Таһир сөеклесе Зөһрәне оныта алмый, аны гыйшык уты көйдерә. Шунлыктан ул Маһымга синең белән җиде ел торырмын, аннан китәрмен дип белдерә, араларына үткен кылыч куеп ята. Кайчан алар-

ның тәннәренә тәннәре якын килсә, Таһирның Зөһрәгә булган мәхәббәте урталарына керә.

Маһым сабыр итәргә мәҗбүр. Алар кыз һәм егет килеш калалар, әмма бу серне һичкемгә белдермиләр. Шулай гомерләр үтә.

Таһир да, Зөһрә дә һаман бер-берсен сагыналар, көйләп шигырьләр укыйлар. Ул арада баласын югалту хәсрәтененнән Таһирның әнисе Хубан үлеп китә. Зөһрә, аның җеназасына килеп, мине ялгызымны калдырып киттең, дип елый.

Зөһрә мәхәббәт сагышыннан этисен һәм әнисен оныта. Әмма көннәрнең берендә аны этисе солтан чакырта. Кызның аны кертәсе дә килми, мондый хәлләрдән соң мин аның каршына ничек барыйм, үтерсен мине, ди. Бабахан, бу сүзләрне ишетеп, кызын үзенең имчәк карендәше Карабаһадурга ниятли һәм, егетне чакыртып, аңа Зөһрәне димли. Карабаһадур моңа бик сөенә.

Әмма кыз бу хәбәрдән кайгы-хәсрәттә кала, Мәҗнүн кебек диванага әверелә. Һаман да күңеленнән Таһирның сурәте китми. Аны эзләтергә бер җырчыны җибәрә, ул, шәһәрдән-шәһәргә күчеп, мәхәббәт хакында базарларда касыйдәләр сөйләп йөри. Ахырда Багдад шәһәренә килә. Монда бәйрәм икән. Шаһзадәләр арасында Таһир да бар. Зөһрәдән килгән җырчы халык алдында:

«Бар микән миндәй гашыйк булган кеше,
Көлгә әйләнеп йөрәге янган кеше,
Бу шәһәрдә торып калган мосафир,
Гариплектә миңа юлдаш булыр кеше», —

дип җырлый. Моны ишетеп, Таһир аның янына килә.

Алар, бер-берсеннән сораштырып, кемнәр булуларын белешәләр. Таһир аннан Зөһрә хакында хәбәрләр ишетә. Кочаклашып елыйлар. Таһир китәргә шаһтан рөхсәт ала. Маһым сыкрап булса да ризалык бирә. Зөһрәдән килгән җырчы, Шәһригә өйләнеп, Багдадта кала, Таһир ялгызы гына Татар шәһәренә кайтып китә.

Көттергән кавышу көннәре килеп җитә. Зөһрә белән Таһир очрашалар һәм кичне бергә уздыралар, максатларына ирешәләр.

Хәзан вакыты иде, гөлләр ачылды,
Сәдәфдин дорре-мәрҗәннәр чәчелде,—

(*Сүзлекчә:* Хәзан — көз; дорре-мәрҗәннәр — энҗе-мәрҗәннәр.)

дип белдерә шагыйрь, аларның мәхәббәтен сурәтләп.

Зөһрә бу серен инакәсенә, ягъни тәрбиячесенә сөйли, бу хакта аның белән киңәшә. Ул Зөһрәнең теләген кабул итә һәм, дөрес эшләгәнсең, ди. Көндезләрен Таһирны үзләрендә качырып тота, кичләрен Зөһрә белән кавыштыра. Шул рәвешле егет сөеклесе сараенда сандыкта качып яши. Әмма аны бер мәкерле карчык күреп ала һәм аңа комачау итәргә уйлый, Таһирдан үзе белән йоклауны таләп итә. Шуннан соң егет аңа нәсыйхәтләр сөйли.

Бу хәлне белгәч, Зөһрә, иптәш кызларын һәм сарай хезмәтчеләрен чакыртып, бәйрәм-туй ясата. Кәеф-сафа коралар. Бабахан, бу хәлне ишетеп, кызым Зөһрә сөеклесе Таһирны оныткан икән дип сөенә. Әмма соңыннан хакыйкатьне белеп ала һәм золымга күңеле авыша, бер-бер яманлык эшләргә җыена. Каршында булган бәкләре аннан Таһир белән Зөһрәне кавыштыруын үтенәләр, гөл сабагын каерма, диләр.

Бабаханның боларга да ачуы килә һәм аларны, муеннарын кылыч белән чабарга, дип куркыта.

Таһирны тотып китерәләр. Солтан аның башын кисәргә боера. Мәйданга халык җыела, анда Таһирны китерәләр. Зөһрә дә йөгереп мәйданга чыга. Шагыйрь бу урында ике гашыйкның күз яшьләре аралаш сөйләшкәннәрен укучы күңеленә үтемле итеп бәян итә. Алар җырлашып хушлашалар.

Сүзе ахырында Таһир үзенең никахлы кәләше булган Маһымга сәламнәрен юллый һәм аңа бәкләрдән үзенең язмышы хакында сөйләүләрен үтенә. Үлемендә сөеклесе Зөһрәнең гаепле булуын белдерә. Аңа каршы Зөһрә, елап, үзенең дә Таһир артыннан үләчәген әйтә.

Һәмма халык аһ-зар итә. Таһирның башын чабалар.

Кылып (күп сүз) бичара бер-берегә,
Ки рөхсәт бирделәр җәлладларыга.
Кисеп ул йирдә Таһирның башыны,
Бары халык күзедин түкте яшене.
Рәкыйпләр хәер, шәрне белмәделәр,
Боларга зәррә рәхим кылмадылар...

(*Сүзлекчә:* Җәлладларыга — баш чабучыларына, палачларына; рәкыйпләр — дошманнар; хәер — яхшылык; шәрне — явызлыкны; зәррә рәхим — бөртек тә миһербанлык.)

Таһирны күмдергәч, Зөһрә үз хәсрәтендә яна башлый, сарайны ташлап китә, сөеклесенең каберенә килә һәм, күкрәгенә хәнҗәр кадап, үзен-үзе үтерә.

Дус-хезмәтче кызлары һәм ата-анасы бу хәлдән канлы яшьләр түгәләр. Каберләре янына Карабаһадур килә, ул да Зөһрәне яраткан икән, ул да үзен-үзе чәнчеп үтерә.

Таһир белән Зөһрә уртасына Карабаһадурны күмәләр, тагын ике гашыйкны аералар.

Ки бер кичәдә, күрең, ике гашыйк,
Аның дик булса хуптыр ике лаек.
Бере гөл булды, бере нуниһали,
Икесе чормашыптыр торфә хали.
Вә ли Карабаһадиу һәм күгәреп —
Чыкыптыр икесене аера ярып.
Күгәрептер гаҗәп торфә тикәни,
Ки мәгълүм булды ул әгъйар икәни.

(*Сүзлекчә:* Нуниһали — яшь үсенте; торфә хали — гаҗәп матур булып; вә ли — әмма ләкин, һәм дә; күгәрептер гаҗәп торфә тикәни — каралып, янына килмәслек тигәнәк булып күтәрелеп; әгъйар — дошман.)

Әсәр моның белән генә бетми, автор Маһымның хәлләрен язуга күчә. Кыз Таһирдан аерылышуны бик авыр кичерә, сагыш утында көя, аның хакында хәбәрләр ишетәсе килә, әмма бер нәрсә дә белә алмый. Шулай да сабыр итәргә була. Бу хәсрәте белән утырган вакытында Багдадка кәрван килгәнен күрә һәм кызларыннан, алар янына барып, барсы хакында да белешергә куша. Ул сәүдәгәрләр Татар шәһәреннән булып чыгалар. Таһир һәм Зөһрә хакында хәбәрләрне сөйлиләр. Ике гашыйк һәлак ителгәннән соң, илнең яме китеп, Татар шәһәренең халкы төрле якка күченеп беткән икән, ә болар монда килгәннәр.

Кызлары Маһымга бу сүзләрне җиткерәләр. Хәбәрне ул авыр күтәрә, аһ ора, шул аһы белән җаны чыга. Шуннан Маһым да үлә. Бу хәл-

дән сарай эчендәге кызлар да сагышка биреләләр һәм шул хәсрәттән алар да үлә. Каберләрен бер гөлбакча эченә куялар. Ул каберлек гөлестанга әверелә.

Ачылып, гөл булыптыр өстехваннар,
Кылыр җан былбылы анда фөганнар.
Аларның бәгъзесе былбыл булыптыр,
Янә бәгъзесе анда гөл булыптыр.
Гәһи Багдад шәһәрендә йөрерләр,
Гәһи Татар дәвәранын сөрерләр...

(*Сүзлекчә:* Өстехваннар — сөякләр; фөганнар — аһ-зарлар; гәһи — кайвакытта, әле; дәвәранын — җирләрен, урыннарын.)

«Дастаны Бабахан» әсәре шушы рәвешле тәмамлана. Таһир-Зөһрә хәлләрен бөтен җиһан белә, ди автор. Моңа кадәр шушындый дастан булмаганлыгын, китапны җомга көн тәгәлләвен күрсәтә, әмма елын, үзенең кайдан булуын, тарихи әһәмияте булган хәбәрләрне искәртми.

Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәт трагедиясе татар халкының җырларына-бәетләренә үтеп кергән һәм гасырлар буена яшәп килгән, андагы вакыйгалар бүген дә күңелләрне тетрәндерә. Ә XIX гасырда Әхмәт Кормаши аларның мәхәббәт вакыйгаларына нигезләнеп «Таһир илә Зөһрә кыйссасы»н иҗат иткән. 1874 елда бу әсәрен аерым китап итеп бастырып та чыгарган. Кыйсса шулай ук тиз арада халыкның күңелен яулап алган. 1917 елда исә Фәтхи Бурнаш «Таһир-Зөһрә» шигъри драмасын иҗат итә һәм әсәр күп еллар буена татар сәхнәсеннән төшми уйналып киләнә. Беренчеләрдән буларак Сайади тарафыннан татар әдәбиятына кертелгән Таһир-Зөһрә вакыйгаларына шагыйрьләр бүген дә еш игътибар итәләр. Әмма беренчелек таҗы вә шигърилек мәртәбәсе Кылыс Сайадидә.

Йомгак: 1. Кылыч Сайадиның яшәгән еллары әлегә фәнгә төгәл мәгълүм түгел, әмма аның Мәҗлиси белән бер иҗади мәктәп вәкиле булуыннан чыгып, шагыйрьнең XV гасырның икенче яртысында һәм XVI йөзнең беренче чирегендә яшәгәнлеге фаразын кабул итәргә тиешбез.

2. Кылыч Сайади язган «Дастаны Бабахан» әсәре сокландыргыч иҗат җимеше булып тора. Ул Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәт трагедиясенә багышланган гуманистик дастан. Сайади бу әсәрендә шәхес трагедиясе аша халык язмышын чагылдыра алган.

МӨХӘММӘДЬЯР БИНЕ МӘХМҮД

(XVI йөзнең беренче яртысы)

Борынгы татар әдәбиятында иң мәртәбәле урыннарның берсен тоткан шагыйрь — Казан шагыйре Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд-хаҗи. Аның тарихта «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» әсәрләре сакланып калган, алар татар халкының горурлыгы булып саналалар.

Тормышы. Мөхәммәдьяр бине Хәхмүд Казан ханлыгының башкаласы Казан шәһәрендә гомерен кичергән. Аның тәрҗемәи хәленә караган мәгъләматлар фәнгә җитәрлек кадәр билгеле түгел. Булганы да бары тик үз әсәрләреннән генә алынган. Кайчан, кайда туганлыгы, кай вакытта үлгәнлеге һәм кайсы урынга күмелгәнлеге дә билгесез. Аның үзе хакында белдерүләреннән күренгәнчә, Мөхәммәдьяр халык арасында «Фәкыйри» исеме белән танылган дип уйларга кирәк. Ул әсәрләрендә күпвакыт үзен шулай ук «Фәкыйрь Мөхәммәдьяр» исемендә атый. Моннан чыгып кына шагыйрьне фәкыйрь яшәгән икән дип уйларга ярамый, билгеле. Бу аның диндарлыгы, суфилыгы белән бәйле тәхәллүс-сөямәте, шигъри имзасы.

Атымны кем тип сорсаң, и шәһрийар,
Мәхмүд-хаҗи углы — Фәкыйрь Мөхәммәдьяр,—

ди ул, кемлеген белдереп «Төхфәи мәрдан» поэмасында.

Димәк, Мөхәммәдьярның имзасы — «Фәкыйрь», яки «Фәкыйри», ә этисе Мәхмүд-хаҗи икән. «Хаҗи» дип ул вакытларда теләсә кемгә әйтмәгәннәр һәм туган вакытында да балага андый исем бирмәгәннәр. Ул бары тик хаҗ кылган кешеләргә генә әйтелә торган атама. Моннан чыгып без Мөхәммәдьярның атасы Мәхмүднең хаҗ кылырлык байлыгы булганлыгын һәм дини руханилардан икәнлеген фараз итә алабыз. Шулай итеп, Мөхәммәдьяр мулла гаиләсендә, кимендә, урта хәлле йортта туып үскән, үз вакытына күрә камил дәрәҗәдә белем алган, шагыйрь булып җитлеккән.

Ошбу «Төхфә» тарихын гәр сорасалар,
Тукыз йөз кырык алтыдыр, белсәләр.
Башладык Газан шәһәрендә моны,
Шәгъбан аеның унынчы көне.

Һәм шәгъбан ахырында булды тәмам
Әйләдек моны, белең сез, вәссәлам.

(*Сүзлекчә:* «Төхфә» — «Бүләк», монда автор «Төхфи мәрдан» исемле әсәрен күздә тота; гәр сорсалар — әгәр сорасалар; Газан — Казан.)

Бу юллардан билгеле булганча, Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд «Төхфәи мәрдан» әсәрен Казан шәһәрендә 946 елның шәгъбән ае 10 нчы көнендә башлап, шушы ук айның ахырында тәмамлаган. Димәк, иң күбе 14-20 көн эчендә язган. Милади ел исәбе белән бу дата 1539 елның 21 декабреннән 1540 елның 9 январенә кадәрге көннәргә туры килә.

Моннан чыгып без шагыйрьнең XVI йөзнең беренче чирегендә туганлыгын һәм Казан шәһәрендә яшәп иҗат иткәнлеген белә алабыз. Димәк, Фәкыйри Мөхәммәдьяр бине Мәхмүт-хаҗи исемле шагыйрь — Казан шагыйре. Бу мәсьәләдә фәндә бәхәсләр юк.

Тәңре фазлы берлә җәмгъ-иттем китап,
Хан Сафа вактында, и шәйхү-шибап, —

(*Сүзлекчә:* Тәңре фазлы — Аллаһы тәгалә ярдәме; җәмгъ-иттем — тупладым, төпләдем; шәйхү-шибап — шәех һәм дәрвиш-диндар, карт һәм яшь.)

дип яза ул шушы әсәрендә.

Ә бу юллардан күренгәнчә, Мөхәммәдьяр асылда хан Сафа дәверендә яшәгән һәм иҗат иткән. Хан Сафа — Казан ханлыгы тәхетендә 1549 елга кадәр утырган Сафагәрәй хан икәнлеге фәнгә яхшы мәгълүм.

Сафагәрәй беренче тапкыр Казан тәхетенә 13 яшендә утыра, әмма ул ханлыктан куылып, урынына Мәскәү сәясәтен яклаучы Җангали 1532 елның 29 июнендә китертелә. Моның да сәясәте Казан халкы өчен Кулай булмыйча, килүенә өч ел узуга, аны тәхеттән сөреп, 1535 елның 25 сентябрендә үтертәләр. Казанга Сафагәрәй кайтартыла. Аңа ул вакытта 24 яшьләр чамасы була. Сөембикәгә өйләнә, Мәскәүгә каршы туктаусыз сугыш сәясәте алып бара, Түбән Новгород, Кострома, Муром якларына яу чаба. Аның 30-40 менлек сугышчан гаскәре урыс җирләрен талап тора, тетрәтә. 1536-1540 еллар арасы — Сафагәрәйнең иң көчле вакытлары, дан-шөһрәт казанган еллары. Әмма Казан әмир-

ләре арасындагы башбаштаклык гаять тә көчле булу сәбәпле, аңа һәрдаим куркыныч янап торган. 1545 елның 29 июлендә ул икенче тапкыр Казан тәхетеннән сөрелә, Сөембикәнең атасы, нугай мирзаларыннан иң олугларыннан саналган Йосыф йортында бераз вакыт яшәп, аннан гаскәр алып, 1547 елда ханлыкны кабат үзенә кайтарып ала, шушы елда хатыны Сөембикәдән улы Үтәмешгәрәй туа. Әмма алар гомерләрен бәхетле тормышта уздыра алмыйлар. Сафагәрәйне, кырык яшенә якынлашып килгәндә, 1549 елда мәкер белән үтерәләр. Ә тарих китаплары аны үз үлеме белән вафат итте дип тә белдерәләр.

Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд иҗатының иң актив чоры Казан тәхетнең көчле вә күкрәп торган вакытларына туры килә. Сафагәрәй ханның сәясәте күпчелек тарафыннан яклау тапкан еллар бу. Мөхәммәдьяр да аның тарафдарларыннан берсе булган дип әйтергә тулы җирлек бар. Әмма шагыйрь тәхет каршында нинди урын тотты икән, әллә дәрвиш-суфи сыйфатында бар нәрсәдән читтә яшәгәнме? Бу сорауга җавапны авторның «Нуры содур» / «Күңелләр нуры»/ поэмасыннан табарга мөмкин:

Тарих тукыз йөз кырык сикездә,
Мөбарәк мөхәррәм уникесендә,
Болгар — шәһри Казан дәрвазәсендә,
Кеше күптер хәйре авазәсендә,
Мөхәммәд Әмин кабрендә, и шәһрийар,
Мөҗәвир ирермен бәси булып зар.

(*Сүзлекчә:* Мөбарәк мөхәррәм — изге мөхәррәм ае; дәрвазәсендә — капкасында; мөҗәвир — мәсҗидтә төн кунып намаз укучы, догачы; бәси — һәм дә.)

Димәк, бу поэмасын шагыйрь 948 елның уникенче мөхәррам көнедә тәмамган. Милади белән ул 1541 елның 8 маена туры килә. «Болгар — шәһри Казан дәрвазәсендә» дип белдерүе фәндә аңлашылмаучы, катлаулы тезмә булып, мәгънәсе ачыкланмаган рәвештә искә алына. Югыйсә монда сүз Болгар иленең Казан шәһәре хакында гына бара, мәмләкәтнең ул вакытта да Болгар иле буларак аталып йөртелгәнлеген төшендерә. Автор үзе дә шәһри Болгар хәрабәләрендә түгел, бәлки Казанда яшәп иҗат иткән. Алга таба шигъри юлларны укып, аның Мө-

хәммәд Әмин хан (1487-1495, 1502-1518 елларда Казан ханы) кабере янында мөҗәвир-догачы икәнлеген беләбез.

Аның «Нуры содур» әсәре Кырым ханы Сәхипгәрәйгә багышлап язылган. Ул махсус үтнеч белән эшләнелгән һәм сәяси максатларда файдаланылган дип фикер йөртергә тулы нигез бар. Бу исә Мөхәммәдьярның шагыйрьләр арасында мәртәбәле саналуы һәм данлыклы булуы хакында сөйли. Шушы фикерне куәтләндерерлек тагын да бер фактка игътибар итәргә мөмкин, ул да булса — «Бакырган китабы». Монда «Фәкыйри» имзасы белән Мөхәммәдьярның бер шигыре урнаштырылган; Әхмәт Яссәви, Сөләйман Бакыргани, Нәсими, Колшәриф һ.б. әдипләр рәтендә күрәбез без аны.

Әлегә фәнгә билгеле шушы фактлардан чыгып кына да Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд-хаҗи хакында күп нәрсәләрне белергә була. Аны 1497 елда Ык буендагы бер-бер торакта-авылда туган дип раслаучы галимнәр дә бар. Әмма мондый дәлилсез бәяннәргә ышанып җитеп булмый.

Иҗаты. Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмалары, шартлы рәвештә «Нәсыйхәт» дип аталган шигыре бүгенге көннәргә кадәр татар кульязмаларында килеп җиткән. «И яраннар, яд итеңнәр...» шигыре «Бакырган китабы»нда XIX гасырдан ук басылып чыккан.

«Төхфәи мәрдан» (1539-1540) Аллаһы тәгаләгә һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә дан җырлау белән башланып китә. Аннан соң «Фәкыйрьнең хәтере шикәстәлекенә ***(борчылуына)*** күңел тәсәлли ***(юаныч)*** биреп, дилжуилык ***(тынычландыру)*** кылып, Күңелемгә күңел биргәне» мөнәҗәте килә.

Көннәрнең берендә шагыйрь үз йортында «гамь бадәсен», ягъни сагыш шәрабын эчеп, аннан исереп, һушсыз утыра икән. Күңел уты кабынып китә дә, лирик геройны харап итеп ташлый. Шуннан ул җанын тәненнән аерылырга үтенә. Әмма шагыйрьнең күңеле-җаны бу эштән баш тарта, аны ташлап китмәсен, чөнки Аллаһы тәгалә иркендә шушы тән өчен яратылганлыган белдерә һәм нәсыйхат кыла башлый:

Ярмөхәммәд, сиңа бирмеш Хак теле,
Бу фәләк багыстанының былбылы.
Зәхмәт тәкый ничә кыйтга сүзләсәң,
Ирме улырсән гарзе-хәлең гизләсәң?

Ничәләр сүзләп җиһандин кичтеләр,
Сүзләмәкдин парча-дорлар сачтылар.
Ничәләр сүзләмәен сүз гөлене кистеләр,
Сүләгәнне күрә белмәй, тән тишеп, кан эчтеләр.
Гакыл ирсәң, куй җиһанда сүз дигәр,
Укыганнар дога рузы-гәр.

(*Сүзлекчә:* Теле — телне; фәләк багыстанының былбылы — күкләр бакчасының былбылы Аллаһы тәгалә; тәкый — тагын; кыйтга — өлеш, кат; сүзләсәң — сөйләсәң; улырсән — булырсың, гарз-хәлең гизләсәң — үтенеч хәлеңне әйтсәң; парча дорлар — энҗе-мәрҗәннәр; гакыл ирсәң — акыллы булсаң; сүз дигәр — кыйммәтле сүз; кылгай — кылыр; рузы-гәр — иртә-кич).

Бу шигъри юлларның әһәмияте зур. Алар шагыйрьнең эчке уй-кичерешләрен ачык күрсәтеп бирәләр. Шагыйрьнең хис-тойгылары, ягъни күңеле сөйләргә тел бирелгәнлеген акылга аңлата, аһ-зар кылып, зарланып утыру белән ир булу мөмкин түгел, аның энҗе-гәүһәр чәчеп сүз сөйләвен тели. Шушы юллардан соң шигъри вәзен-үлчәм үзгәреп китә, ике иҗек арта, моны автор махсус рәвештә эшли булса кирәк, укучыга белдерәсе фикерен шул рәвешле гуяки ассызлыклап куя. Күңеле аңа хәбәр итә: күпләр, татлы телле булып та, матур сүз гөлләрен кискәннәр һәм, башкаларның акыллы киңәшләрен тотмыйча, тән тишеп, кан агызганнар-эчкәннәр икән.

Моннан шул аңлашыла, шагыйрь сугыш теләми, имин-тыныч тормышта яшәү кирәклеген тәкрарлый. Димәк, Казан ханлыгы, аның халкы Мәскәү ягыннан туктаусыз алып барылган сугышлардан тәмам арыган һәм тыныч тормыш хакында уйланган вә хыялланган вакытлар, кешелек идеаллары тасвир ителгән монда.

Шагыйрьнең күңеле хәбәр итә: әгәр дә җиһанда кыйммәтле сүз калдырсаң, исемең иртә-кич догада телгә алыныр. Әмма шарты бар: акыллы булу кирәк.

Күңелнең бу таләпләреннән соң шагыйрь үзен тыныч калдыруны үтенә, Казан шәһәренең эче болай да кече һәм олы шагыйрьләр белән тулы, алар язсыннар дигәндәй әйтә ул.

Мән ирермән бу шәһәрдә бер Фәкыйрь,
Ил күзеңдә гиҗизи хур вә хакыйрь.

Миңа тикмәс, кем, гөстахлык кылмага,
Олуглар риштәсенә катылмага.
Йөрермен бу сәбәпдин хәлем белеп,
Юк исә гаклым кошы бәси кылып,
Кылмас ирсә телеңә эндер хөкем,
Яхшырактыр булмакы соммем-бөкем.
Бер гаҗәп бу, кем, шәһәр эче тулуг —
Шагыйрь улмыш барча көчек һәм олуг.
Куй мәне, үз хәлем илә булаен,
Мөддәгыйләр сүзедин кортылаен.

(*Сүзлекчә:* Хакыйрь — түбән дәрәҗәле, мескен; тикмәс — тиеш эш түгел, тимәс; гөстахлык — әдәпсезлек, әрсезлек; риштәсегә — итгенә, сафына; катылмага — тагылырга; бәси кылып — нәтиҗә ясап, җыеп; эндәр хөкем — күңел кушуы; соммем-бөкем — чукрак-телсез; кечек — кече; олуг — олы; булаен — булыйм; мөддәгыйләр — дәгъвәче-тәнкыйтьчеләр, гаепләүчеләр; кортылаен — котылам.)

Шагыйрь үзен гаепләүчеләрнең дәгъваларын ишетергә теләми, Күңел кушуы юк икән, чукрак-телсез булуы яхшырак дип белдерә ул. Мөнәҗәттә Күңел исеменнән сөйләүче зат Җәбраил фәрештә буларак аңлашылып тора. Димәк, монда Күңел — Җәбраил фәрештәнең аталышы, гарәпләр аны Рухыл-Әмин дә диләр.

Мөхәммәдьярның «киреләнүе» белән Күңел риза түгел. Ул аны ахмак дип атый һәм нәсыйхәтен кабул итәргә, шагыйрьгә табигате хакында бәхәс кылмаска боера:

Сүзләгел син берничә шәкәр сачып,
Бу табигать милкенең агзын ачып,
Бу эшедә йөрәкеңе даглагыл,
Мәрданәләр дик биленне баглагыл!

(*Сүзлекчә:* Сүзләгел — сөйлә; шәкәр сачып — шикәр чәчеп, ягъни татлы тел белән; агзын — авызын; даглагыл — сагышка сал; мәрданәләр — чын ирләр, суфи-дәрвишләр; дик — кебек; баглагыл — путала.)

Күңел шунда шагыйрьгә «намәс аслыннан качар» («кеше булмаган зат үз асылыннан качар») дип белдерә. Шуннан соң гына автор Алла-

һы тәгаләгә таянып сүз башлаган икән, фикерен саф, күңелен йомшак кылуын үтенә, укучылардан мөддәгыйлек, ягъни дәгъва-хурлау кылмауны сорый һәм «Мөддәгыйлек кайрә килер» («Дәгъва-хурлау кире кайтыр») дигән мәкаләне искә төшереп уза да:

Сүзләю уш сүзгә кердем мән Фәкыйрь,
Бер хикәят кылаем моңа нәзыйрь, —

(*Сүзлекчә:* Сүзләю — сөйләү өчен; уш — шушы; нәзыйрь — ияреп.)

дип белдерә.

Шушының белән әсәрнең мөнәҗәт өлеше тәмамлана һәм «Шаһ Һарун хикәяте»ннән әсәрнең төп өлеше башланып китә.

Дәүләт иясе Һарун яшәгән, аңа күп кенә ханнар, хаканнар буйсынган. Җеннәр һәм адәмнәр аның коллары. Таң җиле кебек җитез аты һәм җәннәттән дә гүзәлрәк сарае бар икән. Ул — гадел падишаһ.

Шаһ Һарунның Хушнавә исемле сүзгә оста, якты ай кебек матур йөзле бер вәзире булган. Ул падишаһ катында хезмәт итә һәм Һарунның мәрхәмәтен яулый.

Хушнавә хакында шагыйрь болай болай яза:

Эртер нәгъмәсе гашыйклар дәмагын,
Эртер чәһрәсе ханнары чырагын.

(*Сүзлекчә:* Нәгъмәсе — җыры-моңы; дәмагын — акылын, күңелен; чәһрәсе — кыяфәте-йөзе; чырагын — шәмен.)

Әмма калган вәзирләр Хушнавадән көнләшә, аңа көнчелек кыла башлыйлар һәм яманлык өстенә яманлык күрсәтергә ниятлиләр. Шаһка килеп егетне төрлечә хурлыйлар, аны хәрам иясе, эчкече, бәдбәхет, фетнәче дип сөйлиләр. Һарун падишаһ аларга ышана, Хушнәвадән шикләнә башлый.

Көнчелекле вәзирләр дүртәү икән. Берсенең исеме — Тойгысын, «аның эче тулы фетнә, хәйләкәрлек»; икенчесенең исеме — Гөлруй, көнче, әмма матур сүздә тиңдәшсез кеше. Өченчесе — Чынбел, гашыйк һәм мәхәббәт эчендә яшәүче. Дүртенчесе — Безбаз, бер үзбәк, ялган сүздә эт кебек.

Хушнавә нинди генә сүз сөйләмәсен, матурлык хакында әйтә калса, бу яктан Гөлруй өстен чыгарга, әгәр гыйшык турында белдерсә, Чынбелдән арттыра алмаска, акыл ягыннан Тойгысын аңа юл бирмәскә, уйлап эш йөртүдә Безбаз мәкеренә тап булырга тиеш. Болар бергәләшеп Хушнавәне түбән чыгарырга ниятлиләр.

«*Беренче мәҗлес*». Бу бүлектә шаһ катына килгән Тойгысынның Хушнавәне хурлавы сурәтләнелә. Әмма егет бирешми. Тойгысын дензлектә, бозыклыкта, имансызлыкта Хушнавәне Һарун падишаһ алдында гаепли һәм ачулана башлый. Син үзеңне шаһ хатынының сөяркә-уйнашчысы дип сөйлисең, падишаһны, сакалыннан тотып селкермен, үтерермен дип әйтәсең икән, ди ул һәм аны үтертергә кирәк дип ханга киңәш бирә.

Хушнавә куркып калмый, аңа каршы сүз башлый. Аның үз-үзен олыларча бик тәкәббер һәм галим рәвешендә тотып та, асылда күңелендә бозыклык, көнчелек тулганлыгын ачып сала, әмма, акыллы икәнсең, миңа юл күрсәтүче бул, ди. Шунда Тойгысын егетнең зирәклеген күреп, сүзне артык озайтмыйча, оятлы хәлендә кала, аңа башка чара юк.

«*Икенче мәҗлес*». Бу юлысы Гөлруй килеп, падишаһка Хушнавәне (автор монда героена икенче төрле исем бирә, аны Хушхун дип атый, моның сәбәбе кульязма күчерүченең хатасыннан булырга кирәк) яманлый. Әмма егет аны да җиңел чыга.

Тойгысынның җиңелүгә Гөлруйның төсе кача, Хушнәвага, үзенне бел дип, аны әдәпсезлектә, наданлыкта, үзен акыллы итеп күрсәтергә тырышуда гаепли һәм, минем кебек татлы телле, һәрдаим киңәш өчен әзер торучы кеше башка табылмас, ди.

Җавабында Хушнәва аның инсафсыз, кулыннан эш килмәүче, галим түгел, бәлки дәгъвәче булуын йөзенә бәреп әйтә. Моннан Гөлруй кайгыга кала, Чынбелгә карап, аны үзенә ярдәмгә чакыра.

Әйтте: «И Чынбел дана-сөхәндан,
Кәрәк сән үчемезне алсаң аннан.
Ирерсән гакыл вә данаи фазыл,
Һәр эштә пор һөнәри сән, и камил.
Сән әйтгыл ул шомга, хәддене белсен,
Нәкыйс улып теле, сүзе киселсен!»

(*Сүзлекчә:* Дана-сөхәндан — галим вә шагыйрь; данаи фазыл — зур галим; пор һөнәри — һөнәр белгече, һөнәрле; сән әйтгыл — син әйт; хәддене — чиген; нәкыйс улып — кыскарып.)

«Өченче мәҗлес». Чынбел шунда Тойгысын белән Гөлруйны яклап сөйли башлый, әмма Хушнәваны да олылый, сүз көрәштерүнең урынсыз икәнлеген, аны дошман итеп түгел, дус урынына күрергә теләгәнең белдерә. Егет аның хәйләсен аңламый кала һәм Чынбелне мактый башлый, Тойгысын белән Гөлруйны эт дип атап, Чынбелне дус урынына күрә.

«Дүртенче мәҗлес». Безбаз алар артыннан сүзгә кушыла, Хушнәване хурларга тырыша. Җавабында Хушнавә үзе Безбазны Аллаһының барлыгын вә динне белмәгән татар дип атый, аны эт белән тиңли. Монда татар атамасы динсез дигән мәгънәне ала.

Әйтер Хушхун: «И нәхес-зиште татар,
Асрама эт баласын — аслына тартар.
Биманы шом, бәдбәхет нәкбәти сән.
Йөзең кара, җәһәннәмнең эте сән.
Атаң — Шайтан, үзең — тәзвири, колмаҗ,
Яланчы яр йыймасән, пүлгә мохтаҗ!»

(*Сүзлекчә:* Нәхес-зиште — бәхетсез-яман; биманы шом — имансыз шомлы; нәкбәти — бала китерүче; сән — син; тәзвири — мәкер иясе; колмаҗ (кулмаш) — гайбәт сөйләүче; яланчы — ялганчы; йыйма — җыйма; пүлгә — алтын акчага.)

Бу сүзләрдән соң Безбаз авызын ачмас була. Һарун падишаһ Хушнавәне азат итә, Чынбелгә хазинәдән һәм байлыктан өлеш бирә, ә тегеләрнең өчесен хезмәттән куа. Шагыйрь аларны кешегә кое казып та үзләре шунда егылып төшүчеләр белән тиңли һәм «Кешегә кое казыма, үзең төшәрсен» дигән мәкальне искәртеп уза.

Шушы хикәятне сөйләгәннән соң, Мөхәммәдьяр үгет һәм нәсихәтләргә керешә. Һарун падишаһка бәйле бу вакыйга тарихта булганмыюкмы, билгеле түгел. Аны автор махсус рәвештә үзе уйлап чыгарган диярге дә була, әмма шагыйрьнең үз башыннан шушы хәлләр узгандыр дип уйларга да тулы нигез бар. Мөхәммәдьяр кебек укымышлы

кеше диндар-суфи гына түгел, бәлки тәхет каршында мәртәбә тотарлык кеше дә шул.

Үгет-нәсыйхәтләрендә Мөхәммәдьяр үзенә дә изгелек тели, Ахирәт газабы куркынычыннан җинеллек үтенә.

Алга таба гомернең заяга узуы хакында сөйләнгән аерым шигъри кисәк килә, моңа кушылып бер хикәят сөйләнелә.

Искәндәр кебек бер олуг падишаһ булган. Яхшы-яманнарны күзәтеп, өйләрне карап-тыңланып йөргәндә бер ут күреп, шунда бара. Анда хатыннар тулган. Арада ике кеше кулларына кара, каләм, кәгазь алып утырган. Болар Аллаһы тәгаләнең тәкъдирен белдерүче фалчылар икән.

Бу өйдә бер кыз бала туган, ул гаҗәеп тә чибәр булачак, ди. Әмма ундүрт яшендә аны бүре ашаячак. Фалчылар шуны белдерәләр дә юкка чыгалар.

Көн җитә. Яңа туган бу кызны падишаһ үзенә алдыра. Ата-анасына акча бирә, баланы сарайда тәрбия иттерә. Ундүрт яше тулгач, аерым сарай салдырып, аны шунда бикләтә һәм кызның үзенә дә ни сәбәптән болай эшләвен аңлата. Әгәр ундүрт яшендә бүре ашамаса, исән калырсың, ди. Иптәшкә дип янына тагын бер кызны китертә. Ул да серне белеп ала һәм Тәңредән үзең бүрегә әверелдерүен үтенә. Догасы кабул булып, бүрегә әйләнә һәм падишаһ саклаткан гүзәлне тотып ашый.

Бер ел узуга сарайның ишеген килеп ачалар, шунда эчтән атылып бүре чыга. Бу хәлне күреп торган падишаһ хәйранга кала һәм Аллаһы тәгаләдән гафу үтенә. Моннан шул аңлашыла, тәкъдирдән узмыш юк икән.

Шушы хикәяттән соң шагыйрь язмыш хакында мөнәҗәт урнаштыра, анда ул үзенең авыр тормышы хакында сөйли, башкаларның бәхетле икәнлеген әйтә. Моңа каршы шигыйрьгә нәсыйхәт килә, сабыр булып, Аллаһы тәгаләгә таяну кирәлеген белдерелә, гаделлектә бәхет икәнлеге аңлатыла.

Кем, кулыңдин килгәнчә кыл яхшылык,
Сиңа беркөн тәкый килгәй яхшылык.
Богдайдыр тип илгә сатмагыл салам,
Яманлыкка яманлык килер һаман...

Шушы нәсыйхәттән соң бер заһид-диндар хакында шигъри хикәят урнаштырылган.

Су эчәсе килгән пакь дин иясе заһид бер коены эзләп таба. Күрә, кое төбендә бер кеше һәм өч жанвар утыралар. Ул боларны тартып чыгарырга уйлый һәм, Аллаһы тәгалә бу эшем өчен рәхмәтле булыр, ди.

Коега Заһид беренче мәртәбә бау ташлый, аңа маймыл-бичин тотынып күтәрелә. Икенчесендә бауга елан чолганып чыга. Өченчесендә — каплан. Дүртенче тапкырында бауны төшермәкче, әмма бу котылган хайваннар, ул кешене чыгарма, дип үтенәләр, аның сүздә тормаучы вафасыз икәнлеген тәкрарлыйлар.

Заһид, алар сүзенә карамастан, тегене, кеше җенесеннән булганы өчен, коедан күтәрә. Ул зәргәр-алтынчы икән. Болар барчасы да рәхмәтләрен белдерәләр һәм, яшәгән урыннарының кайда икәнлеген әйтеп, аңа ярдәм итәргә һәрдаим әзер булачакларын аңлатып, үз юлларына китәләр.

Менә бервакыт Заһид маймыл-бичингә килә. Анда төрле җимешләр белән сыйлана. Моннан киткәч, юлында каплан очрый. Заһид курка кала, әмма каплан өрекмәскә өнди һәм, бер бәкнең кызын үтереп, муеныннан алтын-көмешләрен йолкып, бүләк рәвешендә диндарга китерә. Әлбәттә Заһид бу байлыкның талап алынганлыгын белми, бүләккә сөенә. Шәһәргә килә. Алтынчы-зәргәрне исенә төшереп, аңа бара. Бөтен вакыйгаларны сөйли, каплан бүләк иткән алтын-көмешләрне күрсәтә.

Зәргәр күреп һәм танып белде аны,
Биккә әйтергә ашыкты, кем, җаны.
Диде: «Сатып, кыйммәтен килтерәен,
Синең эшең бу заман бетерәен.

(*Сүзлекчә:* Зәргәр — алтынчы; биккә — бәккә; китерәен — китерермен; бетерәен — бетерермен.)

Алтынчы-зәргәр, капланның бүләген Заһидтан алып, бәккә килә һәм, кызыңны үтерүчене таптым, дип белдерә. Диндарны тотып китерәләләр, йөзенә мыскыллап кара сөртеп, аны илгә күрсәтегез, ди бәк, әмер итеп.

Ил каршында хурлыклы рәвештә йөртелгән чагында Заһидны елан күреп кала. Кыйнап, зинданга салгач, аның янына үтеп керә. Хәлен со-

раша һәм, зәргәрне коедан чыгармаган булсаң, бу хәлгә калмас идең, ди.

Бәкнең улы агуланган икән. Елан чаккан. Аңа табиблар дәва таба алмыйча аптырыйлар. Заһид янына зинданга елан керә дә, аңа бәкнең улын терелтү өчен дару бирә, үзеңне табиб дип белдер, ди. Җитмәсә, сарайга менеп, зиндандагы Заһитта савыктыру чарасы барлыгын белдерә.

Заһидны бәккә китерәләр. Малаен савыктыргач, аны сыйлыйлар, төрле хөрмәт күрсәтәләр. Шунда Заһид үз хәленнән бәккә хәбәрләр бирә. Боларны ишеткәч, зәргәрне яманлыклары өчен асып үтерәләр, диндар газаптан котыла.

Яхшылыкка яхшылык булыр мәза,
Яманлыкка яманлык булыр җәза, —

дигән нәтиҗә чыгара Мөхәммәдьяр бу хикмәттән.

Шуннан соң ике нәсыйхәт килә. Шагыйрь аларда һәрдаим яхшылыкта һәм дөреслек юлында булырга чакыра. Мин-минлек, хәсәт-көнчелекне хурлый, изгелекне мактап чыга. Болардан соң Мөхәммәдьяр нәсыйхәт бирүнең яхшылыгын белдерә, үгет-нәсыйхәтләргә колак салырга чакыра, нәсыйхәт тыңламаган кешене Аллаһы тәгалә дә сөйми, гомере дә наданлыкта уза, ди ул.

Шушы фикерләренә ияртеп шагыйрь бер шигъри хикәят сөйләп уза. Игелекле кыз һәм явыз ата хакында ул.

Бәни-исраил халкында каты ачлык бара. Бер бозык-гасый адәмнең ялгыз кызы бар икән. Көннәрдән беркөнне аларга теләнче килә һәм садака итеп бер телем икмәк сорый. Кыз өйдәге пешкән ипидән берсен аңа бирә. Дәрвиш, икмәне алып, сөенә-сөенә үз юлы белән китә. Урам башына җиткән вакытында аңа кызның саран атасы очрый. Теләнче кулындагы икмәкнең үзләренеке икәнлеген таный һәм: «Моны сиңа кем бирде?» — дип сорый. Дәрвиш дөресен әйтә. Саран ата икмәкне аның кулыннан тартып ала, өенә кайтып, кызын ачулана, тирәккә бәйләп куеп, уң кулын кисә, камчы белән кыйнап, урамга куып чыгара. Шуннан кыз үкси-үкси Аллаһыдан ярдәм сорый, догасы кабул ителеп, атасының карыны ярылып үлә. Әмма кыз өйдән-өйгә икмәк теләнеп йөрергә мәҗбүр була.

Менә ул бер йортка килә, анда диндар егет яши икән. Кызны күрүгә, аны күңеленә якын итә. Никахлап-туйлап үзенә ала һәм моңа бик сөенә.

Ашарга утыргач, кыз сул кулын суза. Егет исә, уңың белән аша, ди. Кыз үз хәленнән ояла, елап дога укый. Аллаһы тәгалә аның уң кулын яңадан кайтара. Хикәят шуның белән тәмамлана, шагыйрь аннары сабырлык турында берничә бәет язып уза һәм:

> Шөкер кыл, кем, шөкер — нигъмәт арттырыр,
> Көннән-көн ханиманыңны арттырыр, —

(*Сүзлекчә:* Ханиманыңны — гаиләңне.)

дип белдерә.

Мөхәммәдьяр поэманың форма-композициясен ахырынача үзгәрешсез саклап килә һәм җеп эрләп сатучы ир белән хатын хакындагы хикәяткә күчә.

Фәрхар щәһәрендә дәрвиш гаилә бар икән. «Тапканда — ашап, тапмаганда — ач» хәлләрендә яшиләр, ди. Аларның бер шөгыльләре булып, йон алалар да, аны эрләп, базарда җеп итеп саталар икән.

Менә беркөнне бу гаилә башы ир базардан кайтканда ике талашкан адәмгә очрый. Бакса, болар бер тәңкә акча өчен тарткалашалар икән. Дәрвиш аларга җеп саткан акчасын биреп китә. Кайтып, бу хакта хатынына сөйли. Ул да иренең бу фигыле белән риза икәнлеген белдерә. Әмма алар ул көнне ризыктан мәхрүм калалар, җеп эрләргә мамык та сатып ала алмыйлар. Шулай да үз ишләреннән иске йон юнәтеп, төне буе аны эрлиләр. Иртән йомгакларны ире базарга илтә. Әмма, җебең черек дип, аларны һичкем алмый. Шуннан ул аларны балыкка алыштырып кайта. Өендә хатыны, ул балык чистартканда, аның карыннан энҗе таба, җәүһәр ташлар белән эш йөртүче кеше бу энҗене йөз илле мең ярмак-сумга сатып ала. Дәрвиш һәм хатыны моңа бик нык сөенәләр.

Менә аларга хәер сорашып теләнче керә. Ач булуын белдерә, икмәк һәм су үтенә. Болар аны үз яннарына чакырып алалар һәм бергә ашыйлар-эчәләр, шулай изгелек табалар.

Шушы хикәяттән соң «Төхфәи мардан» әсәренең язылу вакытлары хакында автор мәгълүматлар бирә. Аны укыгач, традицион рәвештә поэма тәмамлана икән дигән фикер туа. Шагыйрь монда әсәрнең Са-

фагәрәй хан вакытында Казанда язылуын белдерә, төгәл даталарын күрсәтә. Шулай да поэмасын тагын да дәвам итә. Традициягә хилаф рәвештә Мөхәммәдьяр ахырда юлбасарлар хакында бер хикәят өстәп куйган. Ул, мөгаен, соңыннан, әсәр язылып беткәч кенә урнаштырылгандыр дигән фикер туа.

«Баш кисеп, кан эчүче» бер таифә бар икән. Тау арасында бер мәгарәдә яшиләр ди болар. Кәрваннарны талап торалар. Алар аркасында шәһәргә сәүдәгәрләр килми башлый. Шуннан соң гаҗиз калган халык, бәккә барып, юлбасарлардан үч алывын аннан үтенәләр. Бәк үз тәхете өчен дә курка кала һәм гаскәрен күтәрә. Ә юлбасарлар кәрван таларга киткән икән, малларын алып, гаскәр аларның кайтуын көтә.

Юлбасарлар кичкә генә күренәләр. Кайтуга бәйрәм итә башлыйлар, йокларга ятуларына, бәк гаскәре аларны бәйли, кулга ала. Аларга хөкемдә үлем җазасы чыгаралар. Ә юлбасарлар араларында бер яшь егеттә бар икән. Ул йөзгә-биткә дә чибәр генә.

Бәкнең вәзире бу егетне үзеңә сорый, канын миңа бир дип үтенә. Әмма бәк бирергә теләми: «Елан үтерсәң, баласын куймагыл!» — дип белдерә. Вәзир генә бу сүзгә карамый, егетне яклый, караклар белән йөргәнгә шулай бозылган ул, «изгеләр белән йөрсә, яхшы булыр», ди. Бу сүзләреннән соң егетне бәк шушы вәзиргә тапшыра, әмма тагын да мәслихәт эш түгеллеген аңлатуны кирәк таба.

Юлбасар егетне вәзир үз өенә алып кайта, яхшы киемнәргә киендерә, укырга бер остазга бирә. Бу хәлләрдән сөенеп, җитмәсә бәккә аны мактый торган булып китә. Әмма бәк һаман үз сүзендә тора, гафил чагында бу егет башыңа җитәчәк әле, дип аңлаткалап та карый, файдасы гына тими. Ахырда сүзе дөрескә чыга. Егет, явыз кешеләрне җыеп, вәзирне һәм аның ике улын үтертә. Ә барлык мал-байлыгын талап китәләр. Бәк бу хәбәрне ишетә һәм:

«Буйлә булыр, кем, нәсыйхәт алмаса,
Олуглар сүзен колакка салмаса!...» —

дип белдерә.

Алга таба шушы ук фикерен дәвам итеп, Мөхәммәдьяр:

Һәркем ит тисә нәсыйхәт, сал колак,
Нәсыйхәт алмаганның эше харап, —

ди. Шулай хикәят тәмамлана. «Төхфәи мардан» әсәре дә төгәлләнә.

Ни өчен шагыйрьнең бу хикәятне поэманың эченә кертмәгәнлеге аңлаөылып җитми. Әгәр дә аның ахырдан гына өстәлеп куелуын фараз кылсак, димәк, бу хикәят аерым әсәр буларак та карала ала.

«Нуры содур» («Күңелләр нуры»). Бу әсәр дә фәнни әдәбиятта поэма буларак күрсәтелә. Ул да традиция нигезендә Аллаһы тәгаләне вә Мөхәммәд пәйгамбәрне олылау-зурлау белән башланып китә. «Төхфәи мәрдан»дә автор үзен Ярмөхәммәд дип белдерелсә, бу әсәрендә Мөхәммәдьяр дип бара.

Поэманың «Мөнәҗәт» өлешендә шагыйрь Кырым ханы Сәхипгәрәйгә атап мактау-мәдхия яза, аны күкләргә чөя, галәм шаһы, дөньяда ханнар ханы дип атый. Гадел шаһ буларак даны таралганлыгын белдерә:

Дадыңыздан куркып, и шаһы җиһан,
Көчлек көчсезегә тикермәс зыян.
Бүре берлә куе бергә су эчәр,
Үрдәк берлә карчыга бергә очар.

(*Сүзлекчә:* Дадыңыздан — тугыры хөкемегездән; шаһы җиһан — җиһан шаһы; көчсезегә — көчсезенә; тикермәс — тидермәс; куе — сарыгы; берлә — белән.)

Бу шигъри юллардан аңлашылганча, Казан ханлыгының Сәхипгәрәйдән сыену эзләвен дә аңларга була. Димәк, әсәрдә алгы планга сәясәт чыгарылган. Автор шушында ук әсәренең язылу сәбәбен, ничек аталышын, үзенең исемен һәм нәселен, Казан шәһәрендә тоткан хезмәтен бер-бер артлы белдереп уза. Моннан соң гаделлек кылу хакында аерым бүлек килә («Гадел кылмак сүзләрен бәян кылыр»). Анда шагыйрь гаделлекнең рәхмәт булып кайтачагын, ханнар гадел булса, халык бәхетле яшәячәк, дип яза.

Көфер берлә мәмләкәт булмас харап,
Золым берлә екылыр улус йөдәп,
Көфрү-кяфер нәфсенә кылыр зыян,
Золым берлә булыр ил хәле яман, —

(*Сүзлекчә:* Екылыр — егылыр, җимерелер; улус — ил, мәмләкәт өлкәсе.)

ди шагыйрь, үз иленең иминлеге хакында уйланып.

Шушы нәсыйхәттән соң әсәрдә гадел Нәүширван падишаһ (Сасанидлар шаһы, 531-579 елларда яшәгән) хакында хикәят китерелә.

Нәүширван падишаһның җитмеш вәзире бар икән, барчасы галим. Араларыннан җидесен үзенә дәшеп, ул алардан бер-бер киңәш таләп итә, ил белән ничек идарә итәргә дип сорый. Аңа киңәшендә бер вәзире кулына байлык һәм мал тупларга өнди, шуның белән күңелен тынычлыкка ирешер, ди. Аны тыңлап торгач, Нәүширван уйга калып утыра да икенчесеннән ни әйтерен беләсе килә. Бу вәзире исә гаделлек белән эш йөртсәң, байлыкка күмелерсең, ди, яхшы сүз белән исеме телләрдә буласын аңлата. Падишаһ шушы киңәшне кабул итә, гаделлек белән идарәне кулда тота. Аңа яз вә кошын алтын-көмеш, мал-туар агыла башлый, һәркем аны хөрмәт итеп сөйли һәм гаделлек иясе буларак таный.

Шушы кыска гына гыйбрәтле хикәяттән соң Мөхәммәдьяр үгет-нәсыйхәт белән рәхим-шәфкатьлелек кылуын бәян итә. Бу сүзләр, әлбәттә, Сәгипгәрәйгә атап язылганнар. Автор ярлы илгә, халыкка, гомумән мохтаҗларга карата рәхим-шәфкатьле булуын аннан үтенә, мондый кешеләргә Аллаһы тәгалә дә ярдәмчел икәнлеген сөйли.

Шуннан соң Муса пәйгамбәр хакында бер хикәят бирелә. Анда, аның Аллаһы тәгаләдән үтенеп, ни өчен үзең рәсүл ителүе турында белешүе сөйләнә. Шунда пәйгамбәренә Хак тәгалә серләрне белдерә һәм Мусага Шөгаип пәйгамбәрнең кызын алуын, сарык көтүен каравын исенә төшерә. Ул көтү көткән вакытта арадан бер сарык кача башлаган. Муса аны арыганчы куып барган. Сер бирмәгән. Менә сарык хәлсезләнгән. Шул чакта гына Муса аны тота алган, кочагында күтәреп алып кайткан, шуның белән рәхим-шәфкатьлелек күрсәткән. Мусаның бу эше Хак тәгаләгә хуш килгән, шунлыктан аны пәйгамбәре иткән.

Хикәят шулай тәмамлана һәм аңа ияреп юмартлык вә шәфкатьлелек хакында үгет-нәсыйхәттән торган шигъри юллар килә:

Барча гаибләрне сәхавәт ябар,
Һәркем иксә, даим гыйвазын табар.

Хак зийадә кылыр аның малыны,
Ахирәттә хуш кылыр әхвәлене, —

(*Сүзлекчә:* Сәхавәт — юмартлык; гыйвазын — бүләген, нәтиҗәсен; зийадә кылыр — күбәйтер.)

дип белдерә Мөхәммәдьяр «Сәхавәт сүзләрен бәян кылыр» дигән бүлектә һәм үгет-нәсыйхәтенә тасвир рәвешендә бер хикәят сөйләп уза. Ул хәммал-йөкче хакында.

Утын ташучы берәү бар икән. Ул көн дә тауга агач эзләп бара һәм, утын җыеп алып, аны базарга китереп сата, шуның акчасына балаларын һәм гаиләсен тәрбияләп яши. Ә бервакыт ул якалашкан кешеләрне юлында очрата. Берсенең икенчесенә бурычы бар икән — ике тәңкә. Йөкче аңа үз акчасын биреп китә.

Икенче көнендә ул базарда балыкчыны очрата. Аның балыгыннан, изелгән дип, башкалар көлә, рәнжетәләр икән. Утынчы аңа үз товарын бирә, балыгын алыштырып ала да өйенә кайта, балаларына ашатыр өчен аларны чистарта, ә эченнән энҗе килеп чыга. Йөкче шул рәвешле баеп китә. Шагыйрь, бу хикәятне сөйләп, укучыга юмартлык вә яхшылыклы булуның рәхмәтле фигыль икәнлеген җиткерергә тели. Ахырда ул болай ди:

Аз нәмәрсә берлә кылды ул сәха,
Хак гыйваз бирде үкеш гата.

(*Сүзлекчә:* Сәха — юмартлык; гыйваз — бүләк, насыйп; үкеш гата — бик күп бүләк.)

Алга таба поэмада оялчанлыкның олы мәртәбә булуы хакында фәлсәфи бүлек урнаштырылган. Анда Мөхәммәдьяр Аллаһы тәгалә алдында оялчанлык тоту мәсьәләләреннән башлап, ил, халык каршында да оят белергә өнди, оятсыз кеше — яманлык кылучы, дип белдерә. Моңа мисал буларак хәлиф белән бер гарәп арасында булган хәл хакында хикәят урнаштырылган.

Гарәп чүлендә бик зур, озакка сузылган эсселек башланып, үләннәр көя, көтүлекләр бетә, су калмый.

Шулай да бер кеше кое таба, суы болганган икән. Моңа да карамастан, сусавын басар өчен коедан су алып эчә һәм ул аңа җәннәт чишмәсенекедәй татлы тоела. Үзе тәмам сугарылгач, башына бер уй килә һәм бу коедан суны хәлифкә китерергә карар итә. Дөясенә утырып, теләгән тормышка ашырыр өчен юлга төшә. Хәлифне табып, аңа суны бирә.

Шактый күп көннәр килә-килә суы исләнеп беткән икән инде. Әмма хәлиф сер бирми, рәхмәт йөзеннән аңа йөз алтын бирдерә. Соңыннан вәзирләре нигә алай эшләгәнен сорыйлар, моңа каршы хәлиф, әгәр дә ул Диҗлә (Ефрат) елгасының суын күрсә һәм эчеп караса, үз эшенә оялыр иде, ди, әмма чүл гарәбенең мул һәм саф су күргәне юк шул.

Җавабын бәкләр ишетеп, хәйран калалар һәм хәлифнең нинди олуг зат икәнлеген аңлап алалар.

Моннан соң газавәт(изге сугыш) хакында бер бүлек килә һәм автор халыкка зыян китерүчеләрне, яман кешеләрне елан белән тиңли, андыйлар җир йөзендә яшәмәскә тиеш, андыйны үтерелүләре яхшырак дигән фикер уздыра, моңа бәйле рәвештә Хәсән Басридан (Әбу Сәгыйть бине Җәгъфәр, 641-728 елларда яшәгән суфи, гарәп язучысы) бер хәбәрне сөйләп уза, шуннан соң сабырлык турында язуга күчә, эштә, дуслыкта, дошманга — бар урында сабыр булырга чакыра, сабырлыкта Ягъкуб пәйгамбәрне өлге итеп куя, улы Йосыфны югалтудан хәсрәтләнсә дә, сабыр итеп, шатлыкка иреште, дип белдерә.

Сабыр кылмак ирер әүвәлге ачыг,
Һичнәмә юк дөньяда андин катыг.
Соңы балдин сөчүк ирер, и җәван,
Сабыр берлә көчай эш булыр асан.

(*Сүзлекчә:* Ачыг — ачы; нәмә — нәрсә; андин — аннан; катыг — каты; балдин сөчүк ирер — балдан татлы булыр ; җәван — егет; көчай эш — авыр эш; асан — җиңел.)

Сабырлык хакында бирелгән шушы фәлсәфи шигырьдән соң Мөхәммәдьяр бу фикерләренә мисал рәвешендә бер хикәят китерә: Харасан мәмләкәтендә Әбу-Мозаффар вәзир бар икән. Көннәрнең берендә шаһ аны үз каршына чакырып әмер бирә. Әмма, бәхетсезлеккә каршы, вәзирнең итегенә бер чаян кергән икән. Мәлик сөйләгән вакытта ул ча-

ян Әбу-Мозаффарны тешли. Вәзир һич сер бирми, Мәликнең бар боерыгын ахырына кадәр тыңлап тора. Шаһның катыннан киткәч, өенә кайтып, чаянны итектән чыгара, аның тешләвеннән азат була.

Бу вакыйганы Мәлик белеп ала һәм, ни өчен чаянны шаһ катында ук итегеңнән чыгармадың, дип сорый. Аңа җавабында вәзир, әгәр дә сабырсызлык күрсәтеп, боерыгыгызны тыңламыйча чыгып киткән булсам, ул вакытта сез мине аңламас, башымны чабарга әмер итәр идегез, шуның өчен сабырлык кылдым, ди, барсын да аңлатып бирә. Аның җавабы Мәликкә ошый һәм ул, шушы вәзиренә мәмләкәтнең авыр эшләрен алып барырга ышаныч куеп, аны төп киңәшчесе итә. Хикәят ахырында шагыйрь, сабыр кеше һәрвакыт максатына ирешә, дигән нәтиҗә чыгара, аннары ышанычлылык, сүздә торучанлык хакында фикерләрен бәян итеп, яңа бүлек ача, аны «Вафа сүзләрен бәян кылыр» дигән исем белән атый.

Мөхәммәдьярның фикеренчә, вафа, ягъни ышанычлылык, өч төрле булганда гына дөрес икән. Аларның беренчесе — гәһд эше, ягъни вәгъдәдә тору. Вәгъдә иткән кеше Аллаһы тәгалә каршында ант итүче белән бер, әгәр дә биргән сүзен боза икән, ул вакытта Кыямәт көнендә ул җәза күрәчәк. Вафаның икенче хасияте — вәгъдәне үтәү һәм шуның белән сүз биргән, ышаныч тапкан кешене сөендерү. Әгәр дә кем дә кем вәгъдәсен үти икән, ул бәндә олуг затлардан саналачак дип белдерә шагыйрь. Вафаның өченче шартын Мөхәммәдьяр үзеннән чыгып тасвирлый. Әгәр дә мине падишаһ, бәкләр-вәзирләр, хуш күрсәгез, мин дә сезнең капка төбегездә үлгәнче хезмәтче булырмын, ди.

Монда сүз үзеңне тәрбия иткән һәм ышанычлы күргән кешеләргә һәрдаим хезмәттә булу кирәклеге хакында бара. Димәк, вафаның өченче шарты — ышаныч тоткан затларга тугыры хезмәт итү. Моңа тасвир рәвешендә шагыйрь әсхабе кәһәф (мәгарәдә белем алган җиде егет) хакында кыйссаны искә төшереп үтә һәм аларга ияреп барган Кытмыр исемле эт турында яза. Кайчан җиде егет тау тишегенә, мәгарәгә белем алырга юнәләләр, алар артыннан бер эт килә. Болар аны куалап та карыйлар, әмма ул артларыннан калмый. Аягы аксый, ә утырып ял да итми, шул рәвешле тугыры хезмәт күрсәтеп, мәгарәдә алар белән бергә яши, изге хайваннарның берсе булып риваятьләргә кереп кала. Монда да нәтиҗә ясап, шагыйрь вәгъдәдә торуны һәм тугыры хезмәтне олуг затлар өчен генә хас сыйфатлардан дип күрсәтә, аннары дуслык ха-

кында бәяннар бүлегенә күчә, монда күни сүз, ягъни күндәм, дөрес сөйләү турында бәяннар бирә.

Әгәр дә кешеләр бер берсенә күндәмлек күрсәтеп эш йөртсәләр, аңлашып яшәсәләр, алар үзара дус булалар. Шушы фикердән чыгып, Мөхәммәдьяр дуслык хакында яза, дәүләт-байлык күндәмлек белән эш йөртү аркасында арта дип бара ул. Күндәм кешеләр олуг заттан хисапланалар, аларны олус-ил дә сөя икән. Болардан соң автор күндәм тел хакында яза, «кәкре», бозык тел аркасында бәндәләр төрле җәбер-җәфалар күргәнлеген белдерә.

Кеше ялган сүз белә тапмас нәҗат,
Тугры сүз берлә табар даим хәят, —

(*Сүзлекчә:* Нәҗат — котылу; хәят — тормыш.)

ди ул һәм тагын шуңа мисал буларак бер хикәятне сөйләп уза.

Бер солтанның улы көннәрнең берендә сөйләшми башлый. Бу хәлдән аптыраган хан нәрсә эшләргә дә белми, бәк-вәзирләренә шул хакта аңлата. Алар киңәш итәләр, иртән ауга чыксын, бәлки шунда сөйли башлар, диләр.

Менә алар ауга китә. Сәхрага җитүгә, киек казлар тавыш биреп очалар. Шаһзадәнең тәрбиячәсе аларны ауларга лачын очыра. Шунда егет:

«Һәркем тоты телене — котылды ул,
Телене тотмаган уш тотылды ул!» —

(*Сүзлекчә:* Уш — шулай.)

дип әйтеп куя.

Алар сунардан кайталар. Тәрбияче тиз генә шатлыклы хәбәрен солтанга җиткерергә ашыга, малаеның сөйләшкәнен әйтә. Шаһзадәне чакыртып алалар, әмма ул бер сүз дә сөйләми. Тәрбияче алдады дип белеп, солтан аның башын чабарга әмер бирә. Шунда Шаһзадә казлар аулагандагы сүзен кабатлап куя:

«Һәркем тотты телене — котылды ул,
Телене тотмаган уш тотылды ул!»

Солтан, улының сүзләрен ишетеп, гаҗәпкә кала, тәрбиячесен хөкемнән азат итә һәм шаһзадәдән ни сәбәпле сөйләшмәвен гозерләнеп сорый. Егет барсын да аңлатып бирә, остазы аңа бер хадис өйрәткән икән:

«Һәркем тотты телене — котылды ул,
телене тотмаган уш тотылды ул!»

Шаһзадә бу сүзнең хакыйкатьме-түгелме икәнлеген тәҗрибә итмәкче булган да, шунлыктан сөйләшмәгән. Әгәр дә казлар тавыш чыгармаган булсалар, аларны аулар идекме, мәгәре тәрбияче хәбәр бирмәгән булса, аңа үлем хөкеме чыгарыр идегезме, ди ул, тагын бер тапкыр шул хадисне кабатлап.

Автор аның бу сүзләрен кат-кат биреп, мәкаль-хәдиснең мәгънәсен тагын да тирәнәйтүгә ирешә, шаһзадә укучы күз алдына акыллы кеше буларак баса.

Моннан соң гафу кылучанлык турында бүлек килә.

Шагыйрь башкаларны гафу итүнең Аллаһы тәгаләдән килгән боерык булуын, андый кешеләрнең ир икәнлеген язып үтә һәм бу сүзләренә кушып бер хикәят китерә.

Мәсгуд һәм Ибне Әсгад исемле ике шаһ бар икән, алар үзара талашып, сугышып торалар. Менә Мәсгуд шаһ, зур гаскәр җыеп, Ибне Әсгадкә һөҗүм итә, әмма җиңелә. Күп кенә сугышчылары әсир төшә. Аларны Ибне Әсгад карап уза, шунда бер егеткә күзе төшә. Ул егет, бер сүзем бар иде дип шаһка мөрәҗәгать һәм үзләрен гафу кылуын үтенә, башкаларны ярлыкау Аллаһы тәгаләдән төшкән боерык икәнлекне сөйли. Шаһка аның сүзләре хуш килә һәм, әсирләрне гафу итеп, аларга азатлык бирә, шуның белән яхшылыклы даны тарала, макталып сөйләнә башлый.

Шушы хикәятеннән соң Мөхәммәдьяр үзе хакында язуга күчә, бу «Нуры содур»ны төпләүгә Күңел әмер итте, ди. Әсәрендәге хикәятләрнең фарсы теленнән алып язганнын белдерә, ханга моннан гайре лаеклы бүләгем юк, ди, кабул итеп алса иде, дип аңлата, шушы мөнаҗатына бәйле рәвештә тагын бер хикәят урнаштыра.

Сөләйман пәйгамбәр, вәзирләрен җыеп, аларга туй булачагы хакында хәбәр бирә. Барысы да төрле-төрле бүләкләр белән мәҗлескә җые-

лалар. Менә бервакыт тургай килә һәм матур тавышы белән барсын да сәламли, Сөләйман пәйгамбәрне тәбрикли, томшыгында алып килгән саранчаны аңа бирә, аның иң зур бүләк булуын әйтә. Сөләйман пәйгамбәр аны аңлап ала: чыннан да ул үзенә иң кадерле нәрсәне алып килгән! Тургайны пәйгамбәр шушы хөрмәте өчен бүләкли.

Боларны сөйләгәч, шагыйрьнең иң зур бүләге шигырь икәнлегенә ишарә итеп, Мөхәммәдьяр:

Мән тәкый имде уш, и шаһи җиһан,
Булдым ул тургай мәнгизлек бу заман, —

(*Сүзлекчә:* Мән — мин; уш — шулай; мәнгизлек — рәвешле, кебек.)

Шуның белән поэма тәмамлана.

«Нуры содур» поэмасының ахырын Мөхәммәдьяр Урта Азия шагыйре Лотфиның «Гөл вә Нәүрүз» әсәреннән алган дип белдерәләр галимнәр.

Бу поэманың эчтәлегеннән аңлашылганча, Мөхәммәдьяр, үз чорының укымышлы кешеләреннән берсе буларак, Кырым ханлыгына Казаннан җибәрелгән илчелек составында йөрмәдеме икән дигән сорау туа. Чынлыкта ул шулай булырга да мөмкин. Казан һәм Кырым арасында Сафагәрәй белән Сәхипгәрәй ханнар заманында үзара тыгыз бәйләнеш тотрыклы сакланган, ике арада илчеләр еш килеп-китеп йөргән.

Мөхәммәдьярның иҗаты татар әдәбияты тарихында әһәмиятле урын алып тора, аның әсәрләре белән танышудан ул чорның мәдәни һәм әдәби тормышы күз алдына килеп баса, шагыйрь вә әдипләрне нинди мәсьәләләр борчыган, Казанны көткән һәлакәтне алар сизенгәннәрме, котылу юлларын күргәннәрме һ.б. күп санлы сорауларга «Нуры содур» һәм «Төхфәи мәрдан» әсәрләреннән җавап таба алабыз.

Мөхәммәдьяр гаҗәп авыр вә катлаулы чорда иҗат иткән, иминлек һәм тыныч тормышта яшәүне ул үрнәк итеп шигъриятендә күтәреп чыккан, әмма аның хыяллары тормышка ашмый калган, Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд иҗаты — буыннардан буыннарга мирас булып калдырылган һәм бүгенге көндә әһәмиятен югалтмаган милли байрагыбыз ул, шунлыктан аны кат-кат өйрәнергә, төрле яклап тикшерергә, халык арасында пропагандаларга кирәк.

Йомгак. 1. Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд-хаҗи — Казан ханлыгы чоры шагыйрьләребезнең иң мәртәбәлеләреннән берсе, ул XVI гасыр башларында туган, шушы ук йөзнең урталарында Казан шәһәрендә әдәби иҗат беән шөгыльләнгән дәрвиш-суфи буларак күз алдына килеп баса. Фәкыйри имзасы белән дә шагыйрьләр язган, дәүләт эшләрендә катнашкан, иҗаты сәяси максатларда файдаланылган. Мөхәммәд-Әмин хан кабере янында догачы булган.

2. «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларын Мөхәммәдьяр үгет-нәсыйхәт һәм аларга тасвир рәвешендә язылган хикәятләрдән төзегән, гуманизм идеяләрен яклап чыккан.

ЙОМГАК

1552 елда Казан ханлыгы Мәскәү кенәзлеге тарафыннан җиңелә, татар халкы күп кенә җәберләүләргә вә кимлек-хурлыкларга дучар була. Шагыйрьләр, язучылар, гомумән әдипләр күбесе һәлак ителәләр, мәктәп-мәдрәсәләр, китапханәләр яндырыла. Халыкның бай һәм зур рухи мирасы юкка чыгарыла. Исән калган галим-голамә Кырым, Төркия, Урта Азия якларына мөһаҗирлек кылырга мәҗбүр булалар. Олы һәм данлыклы халык шул рәвешле мескенлеккә калдырыла. Яңадан тернәкләнер һәм элеккеге куәтен кире кайтарыр өчен аңа еллар гынамы, гасырлар кирәк була.

Урта гасырлар татар әдәбиятын гомумтөрки әдәбиятлардан аерып карарга ярамый, ул аерым милли эчтәлек һәм формалар җирлегендә түгел, бәлки Шәрык тәэсирендә үсеш алган. Бу дәвердә туган әсәрләр башка төрки шагыйрьләрнең иҗатлары белән аваздаш. Моның сәбәбе әдипләрнең туктаусыз эзләнүләре, төрле җирләрдә белем алулары, уртак мәдәни тормыш белән яшәүләренә дә бәйле. Аларның кайсылары Идел-Урал, Себер якларында үсеп, Урта Азия, Төрек һәм гарәп илләренә юл тотканнар, икенче ватаннарын шунда тапканнар, ә башкалары, киресенчә, Урта Азия һәм башка яклардан Идел-Урал буйларына төрле сәбәпләр аркасында килеп чыкканнар һәм үзләренә шушы яңа ватаннарына бәйле рәвештә имзалар кабул иткәннәр. Димәк, бу чор әдәбияты шартлы рәвештә генә аерым милли әдәбият тарихы кысаларында карала ала, фактта исә ул әсәрләр гомумтөрки әсәрләр буларак барлыкка килгәннәр һәм таралыш тапканнар. Һәрбер нигезләмәдән чыгарма бар. Бу очракта да ул юк түгел. Әгәр дә әдәби әсәрләр нинди дә булса сәяси максатлардан чыгып иҗат ителсәләр, ул вакытта алар билгеле бер ханлыкка кирәкле саналган сәясәтне алга сөргәннәр, шунлыктан миллилек төсмере белән дә тикшерелә алалар.

Урта гасырлар татар әдәбиятының икенче үзенчәлеге аның дидактик рухта булуында. Әдипләр үзләренең фәлсәфи һәм сәяси карашларын әхлакый мәсьәләләр аша яктыртырга омтылганнар. Бу аларның галим, дин эшлеклесе, суфи булуларыннан килә. Алар, үгет-нәсыйхәткә нигезләнеп, үзләренең дөньяга карашларын төрле яклап тасвирларга омтылганнар, хакыйкатьне таныргa өйрәткәннәр, ул гына да түгел, тормыш ничек төзелгәндә дөрес һәм яхшы икәнлеген белдерергә тырышканнар. Бу яктан алар утопик модельләр тәкъдим итүчеләр рәве-

шендә күзаллаңалар. Моның сәбәбе ул дәвер әдипләрнең Исламга, Коръәнгә, хадисләргә таянып эш йөртүләре белән дә аңлатыла ала. Әгәр дә шагыйрь халыкның дөньяны күзаллавы традицияләре нигезендә иҗат итмәсә, аның әсәре буш булып чыга, алдан ук онытылуга дучар ителә.

Бу чор татар әдәбияты тулысы белән суфичылык юнәлешендә язылганлыгын ассызыклап үтәргә кирәк. Язма тел буларак уртак төрки тел файдаланылган.

Урта гасырлар татар әдәбиятының өченче бер әһәмияте ягы шигърияттьнең гөрләп чәчәк атуы белән бәйле. Калын-калын дастаннар, кыйссалар, шигъри романнар барлыкка килгән дәвер бу, поэмалар тасвир рәвештә язылган шигъри хикәятләр белән баетылган. Моның сәбәбе шигъри сүзнең үтемле булуы белән генә аңлатыла ала.

Татар әдәбиятының әүвәлге дәверен менә шушы үзенчәлекләре белән характерларга мөмкин. Билгеле, йомгакны тагын да киңәйтеп, башка, артык әһәмияте күренмәгән якларны да санап үтәргә була. Әмма аның белән төп мәсьәлә вакланып кына китәчәк. Алда билгеләнгән үзенчәлекләре аерым татар әдәбияты өчен генә түгел, башка төрки әдәбиятлар өчен дә хас күренешләр. Шунлыктан без аларны төрки әдәбиятларының үсеш процессының төп сыйфатлары итеп тә карый алабыз.

Э Ч Т Ә Л Е К

Кереш. Дәверләргә бүленеш 3

Төрки әдәбиятларының
Ислам мәдәниятенә тартылуы..6
Йосыф Хас Хаҗип Баласагуни 6
Әхмәт Югнәки 16
Әхмәт Яссәви 22
Әхмәт Яссәвинең шәкертләре 35
Сөләйман Бакыргани 36

Болгар дәүләтендә
төрки әдәбият һәм мәдәни мөхит мәсьәләләре 49
Кол Гали 51
Угыз-кыпчак дәверенә йомгак 60

Алтын Урда дәүләте
оешу һәм татар әдәбияты 62
Борһанетдин улы Насретдин Рабгузый 64
Котб 68
Хәрәзми 77
Хисам Кәтип 83
Сәйф Сараи 90
Мәхмүд бине Гали 107
«Кисекбаш» поэмасы 112

Алтын Урда таркалган чор әдәбияты 120

Ханлыкларга бүленеш,
таркаулык чоры, яки Казан ханлыгы оешу 127
Мәҗлиси 129
Сайади..149
Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд 163

Йомгак 186